Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

01

гыйнвар 2022

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

зөлфәт

Идел кичми ил булмас яки Тәтешлеләр һиҗрәте

8 бит

«Кызлар арасында күмелеп утырдым»

27 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

01
(337)
гыйнвар 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)**

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Зөлфәт

ТАРИХИ МИРАС

4 Татар – дәүләти халык. *И.Таһиров*
8 Идел кичми ил булмас яки Тәтешлеләр һиҗрәте. *Э.Сәлахова*
14 Тәтештәге татар тормышыннан кайбер фактлар. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
18 Химикка Гомер кирәкме? *Г.Камай*
24 «Безгә дә яңача булырга кушалар». *Л.Мортазина*
27 «Кызлар арасында күмелеп утырдым». *М.Фәйзи*
32 Коточкыч ачлык. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
36 «Кайт, и нәфсе мотмәиннәм!» *Н.Таиров, И.Таиров*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ТАТАР ГАМЕ

38 Авыл малае. Ил башы. Ил агасы
47 «Безнең мирас» котлый!
48 Рәмис Сафиуллов: «Музей ул – матурлык! Аны тоя белергә кирәк...»
53 Милләт сагында. *Ф.Харисов*

ДИНИ МИРАС

58 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
64 2022 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. *А.Дубин*
66 Тәтешнең вәкарьле ишаны. *И.Җиһаншин*
69 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*
70 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ӘДӘБИ МИРАС

72 Совет Русиясендә кунакта. *Х.Хәмидулла*
78 Арба гына димә... *Т.Галиуллин*
84 Тарихтан ишарәләр. *Р.Зәйдулла*
90 Юл өзеге. *Зөлфәт*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

92 Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889). *Р.Мөхәммәтшин*



ХӘТЕР САНДЫГЫ

98 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
100 Колач киңлеге, ният ихласлыгы. *М.Госманов*
106 Ике хатирә. *А.Хәлим*
108 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

110 «Кара карлыгач микән?» җыры

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Гыйнвар*

Заказ №О-0071. Тираж – 2800 данә. Формат 70х100 $^1/_{16}$
Басарга кул куелды: 13.01.2022. Чыгу көне: 17.01.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Зөлфәт. 1970 нче еллар

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

Шигырь – ярала, туу. Шигърият – дога. Шигърият – турыдан-туры Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать.

Зөлфәт

Зөлфәт каләмдәш дусты Мөдәррис Әгъләм белән. ***1980 нче еллар***

ЗӨЛФӘТ

(3.01.1947-15.05.2007)

***

Изсәләр дә, кылыч чапсалар да,
Юлыкса да юлда мең үткел,
Шигырьле тел фанилыкка бәйсез,
Үлемгә баш бирми андый тел.

***

Дөньялыкта яман сүзләр булмый,
Яман әйтүчеләр булмаса.

***

Без ракета күк, тик бер аерма:
Ракетаның тыш катлавы яна,
Безнең исә – йөрәк, тойгыларның
Атмосфера катлауларында.

***

Яшәү – очыш, кеше – таң кошы.
Кеше күңеле – Сак-Сок тавышыдыр,
Кеше җаны – Сак-Сок сагышы...

***

Күреп, аңлап, тоеп яшәдем мин –
Ялган белән тулды һәр төбәк –
Алдаучысы булган яшәештә
Алданучы булган – мин кирәк.

***

Без – күкертсез шырпы.
Без – кешесез учак.
Без – яшәми торган адәм балалары.
Без – сурәтсез сурәт.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

Татар – дәүләти халык

Индус Таһиров, академик

Татарстан Югары Советында Республиканың яңа Конституциясе кабул ителгәннән соң. Казан, 1992 елның 6 ноябре

Татар халкы – бер шагыйребез язганча, кайгыны да, үлемне дә җыр белән җиңгән халык. Чыннан да, яшәү көченә ия, куәтле, башкаларга үрнәк булырдай халык кына теләсә нинди шартларда, һичкем йогынтысына бирелмичә, хәтта, киресенчә, башкаларга йогынты ясап, яшәргә һәм шуның белән бөеклек яуларга мөмкин.

Әйе, татар – дәүләтен югалтканнан соң да, кайгы белән үлем арасында калса да, бөеклеген саклый белгән халык. Бер рус авторы 1912 елда болай дип язган: *«Татарлар, өч йөз ел буе руслар белән бергә яшәвенә дә карамастан, руслашмыйлар, киресенчә, башкаларны татарлаштыралар».* Бу сүзләрдә дөреслек юк түгел. Чыннан да, безнең бабайлар, коллык шартларында да, башкорт тарихчысы Б.Х.Юлдашбаев язганча, башкалар өчен өлге милләт була алды. Миссионер Николай Ильминский юкка гына: *«Татарлар үзләрен һәрвакыт патшачыл халык итеп тоя»,* – дип әйтмәгәндер. Икенче бер миссионер Евфимий Маловның көндәлегендә (1904 елның 30 сентябрь-14 октябрь аралыгы) мондый юллар бар: *«Без, руслар, ун гына түгел, йөзләгән еллар дәверендә татарлар өстеннән хаким сыйныф рәвешендә яшибез. Инде Казан алынганнан соң да өч йөз елдан артык вакыт үтте, әмма без аларны күпме дәрәҗә генә руслаштыра алдык икән соң? Тагын да өч-дүрт йөз ел көтәрбезме икән?»*

1870 елда Сембер шәһәрендә чыккан бер китапта: *«Татарлар – Россиядәге иң нык халык»,* – дип язылган. Анда шулай ук: *«Алар, үзләренең азчылык булуына карамастан, рус йогынтысына бирелмәде, аларга рухи яктан түгел, сәяси рәвештә генә буйсынды»,* – диелгән.

Шушы рәвештә язучылар аз түгел. Аларның кайберләре татарларга карата нәфрәт, икенчеләре, киресенчә, соклану хисләре белән сугарылган. Ничек кенә булмасын, аларда чын хакыйкать ярылып ята – татар һәрвакыт татар булып кала алган. Юкка гына халык дастаннарында: *«Сөт калыр, Ватан китәр»,* – дип язылмагандыр. Әлеге юллар Дәрдемәндтә дә бар. Татарлар, дәүләтсез калуга да карамастан, дәүләти халык булып саклана алды. Аларның тарихи хәтерләренә, каннарына һәм хәтта яшәү

рәвешләренә дә дәүләтчелек сеңгән. Нәкъ менә шул дәүләти куәт – татарның сөте, аңа көч-дәрт, дәрман бирә торган каймагы.

Чыннан да, һун бабаларыбыздан ук башланган, Төрки каһанлыкта тернәкләнгән, Алтын Урда һәм аннан соңгы татар дәүләтләрендә, бигрәк тә Казан ханлыгында дөрләп янган татар учагы беркайчан да сүнмәгән. XX гасырда төрле җирләрдә барлыкка килгән татар оешмаларының шактые юкка гына «учак» дип йөртелмәгәндер. 1915 елда Петербург университетында Галимҗан Шәрәф, Ильяс Алкин һәм башкалар «Татар учагы» исемле яшерен түгәрәк оештыра, дәүләтчелегебезне торгызу юлларын эзли. Вятка губернасының Иж-Буби мәдрәсәсе шәкертләре: *«Кайчандыр безнең үз ханнарыбыз булган, моны онытырга ярамый»,* – дип иман ныгытканнар. Алар Сөембикә манарасында элгәре хан гаскәрләре яшәве, Казанның төрек-татар йорты булуы турында җырлар язган. Ул җырларда: *«Син үзең сүзсез булсаң да, һәрбер ташың безгә шул турыда сөйли, болар турында уйлаганда күздән кайнар яшьләр ага»,* – дигән фикер бар.

Әйе, XX гасыр башында татарларның күзләре Казанга текәлгән була. Бер жандарм мәгълүматында: *«Казан – милли идея символы, татарларның рухи терәге»,* – диелгән. Анда бу идеянең төп максаты – барлык мөселманнарны бер дәүләт тирәсенә туплау һәм гомумтөрки республика булдыру дигән сүзләр бар. 1911 елгы жандарм белешмәсендә: *«Татар идарәсен булдыру максаты тирән тамыр җибәрде һәм барлык зыялыларның игътибарын җәлеп итте»,* – дип язылган. Анда Казанның кайчандыр куәтле ханлык үзәге булуына һәм шунлыктан әле дә татарларның үзбилгеләнүгә омтылуына басым ясалган. Моңа охшаш язмалар күп. Аларга әле тулы бәя бирәсебез бар. Әмма хәзер миңа бу документлар татарларның дәүләти халык икәнлеген раслау өчен генә кирәк иде.

Әгәр дә татарлар дәүләти халык булмаса, Татарстанның 1990 елның 30 августында кабул ителгән, дәүләтчелек рухы белән сугарылган суверенлык декларациясе дә барлыкка килмәс иде. Бу декларация – Татарстанның Югары Советы кабул иткән документ кына түгел, ә татарның нәкъ шул сыйфатын туплаган, халык таләбе буенча кабул ителгән документ.

Төрле җирләргә сибелеп яшәгән татарлар һәрдаим үз дәүләтчелеген торгызу фикерен белдермәсә, хакимияткә, шул исәптән Татарстан Югары Советына басым ясамаса, мөстәкыйльлек рухындагы мондый декларация тумас та иде. Мин моны ассызыклап әйтәм. Чөнки кайберәүләр бу эштә халыкның ролен танымаска, барлык эшләрне җитәкчеләргә яки Югары Советка гына кайтарып калдырырга тырыша. Алар бу вакыйгаларга кадәр Югары Совет исеменә 685 документ ирешкәнлеген, шуларның 612се – илнең 137 төбәгеннән килгән һәм бәйсезлек таләп иткән хатлар, мөрәҗәгатьләр икәнлеген оныталар, ахры. Халык йогынтысы булмаса, безнең декларация дә башка республикаларда кабул ителгән, игезәктәй бер-берсенә охшаш төссез документлардан аерылып тормас иде. Бу хакыйкатьне танымаучылар Югары Совет Президиумы тарафыннан декларациянең үзгә проекты басылып чыгуын да хәтердән җуйган, күрәсең. Анда югыйсә Татарстанның Россия составындагы суверен дәүләт булуы күрсәтелгән иде... Ул проект, нигездә, «Вечерняя Казань» газетасында басылган Александр Штанин проектыннан берни белән дә аерылмады. Һәм шуңа охшаш декларацияләрне башкортлар да, чуашлар да, якутлар да кабул итте.

Әмма безнең халык декларациянең андый булуын теләмәде. Ул республиканың тулы суверенлыкка ия икәнлеген раслаган документ даулады. 1990 елның августында Казанга Татарстанның һәм, гомумән, илнең төрле почмакларыннан дистәлгән мең татар җыелды. Ирек мәйданы гөрләп торды. Бертуктаусыз митинглар дәвам итте. Юга-

ры Советка, аның депутатларына басым ясауның төрле ысуллары барланды. Берничә милләтпәрвәр, шул исәптән халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова да ачлык игълан итте. Кайбер депутатлар, моңа ризасызлык белдереп, халыкны мәйданнан куып таратырга өндәде: имеш, эшләргә комачаулык тудыралар... Дөреслек исә шунда иде: халык аларны шул рәвешле контрольдә тотты, аларга дөрес юнәлештән тайпылырга мөмкинлек бирмәде.

Милиция кордоннары куелуга карамастан, халык барыбер таралмады. Күпчелек кешеләр төннәрен дә шунда үткәрде. Казан татарлары аларны азык-төлектән өзмәде. Җир шарының төрле почмакларында яшәгән милләттәшләр гел-гел Казан белән аралашып, мондагы хәлләр белән кызыксынып, дәрт-дәрман биреп торды. Ул көннәрдә бөтен татар дөньясы бер йодрыкка йомарланды.

Югары Совет рәисе М.Ш.Шәймиев Башкортстан Югары Советы рәисе М.Г.Рәхимов белән һәрдаим аралашып торды. Берсендә, ул Ирек мәйданы тулы халык икәнлеген, ачлык тотучылар да булуын хәбәр иткәч, Мортаза Рәхимов: *«Эх, бездә дә шулай булса иде!»* – дип уфтанган. Һәм, шуңа өстәп, Шәймиевкә: *«Бу – синең файдага»,* – дигән. Әйе, бу көннәрдә халык һәм хакимият бер фикердә иде. Нәкъ менә шушы бердәмлек тиешле эчтәлектәге декларация кабул итүнең төп сәбәбе булды да. Мондый егетлекне дәүләти халык кына булдыра ала!

Чыннан да, Уфа мәйданнарын да халык каплап алган булса, анда да зуррак хокукларга ия декларация кабул ителер иде, бәлки. Чөнки андый мөмкинлек бар иде. Бу урында Башкортстанның Россия составында икәнлеге күрсәтелмәгән, тулы суверенлык даулаган декларация проектының кулыбызга килеп керүен искәртергә кирәк. 1919 елда Башкортстан һәм Совет хөкүмәтләре арасында төзелгән Килешүне күз уңында тотып эшләнгән бу декларациянең эчтәлеге хәтта безнең проектныкыннан да куәтлерәк иде! Ләкин, ни кызганыч, аларның бу эше барып чыкмады. Башкортстан Татарстанныкына тиң декларация кабул итә алмады. Чөнки бу эштә халык катнашмады, мәйданнар кайнамады, Югары Совет исеменә тулы бәйсезлек таләп иткән мөраҗәгатьләр һәм хатлар яумады. Ачлык тотучылар да булмады...

Шуларны уйлап, бервакыт Минтимер Шәрипович: *«Эх, союзникларсыз калдык бит»,* – дип уфтанды. Мин аңа: *«Башкортлар моның белән берни дә югалтмады»,* – дидем. Ул: *«Ничек югалтмасыннар?!»* – дип гаҗәпләнде. Мин Башкортстанның һәм башка республикаларның Россия составына «ирекле рәвештә» керүләренең 400 еллыгын тантаналы рәвештә билгеләп үтүе турында исебезгә төшердем. Алар шул көннәрдә орден-медальләр һәм тагын әллә нинди өстенлекләр алдылар, дидем. *«Ә без?»* – диде ул. *«Без, татарлар, Россиягә ирекле рәвештә керүебезне беркайчан да танымадык. Татарстанның Россия эчендә булуын күрсәткән декларация кабул итсәк, ул мондый рухтагы беренче документ булачак иде,* – дип тә өстәдем. – *Сез бәхетле кеше, Минтимер Шәрипович! Сез имзалаган документ – чын-чынлап халык теләгән документ».*

М.Ш.Шәймиев сискәнеп киткәндәй булды һәм: *«Татарстанның Россиягә керүе турында бер генә документ та юкмыни?* – дип сорады. – *Бәлки, 1922 елгы берәр документ булгандыр?»* Юк. Андый документ юк иде...

1922 елдан башлап Татарстан берничә мәртәбә үзен СССРга суверен дәүләт буларак кабул итүне сорап ялвара. Ләкин ул СССР төзелү турындагы шартнамәне мөстәкыйль рәвештә имзалау хокукыннан мәхрүм ителә. Монда Мирсәет Солтангалиевне искә төшерми булмый. Бу кеше РСФСРның Милләтләр эшләре буенча Халык Комиссариатының кече коллегиясе әгъзасы, Федераль җир комитетының рәисе, кыскасы, Совет хөкүмәтенең җаваплы хезмәткәре була. Төньяк Кавказ республикала-

рын төзү комиссияләренең дә башында ул тора. Солтангалиев Совет җитәкчеләре алдында СССРда барлык республикаларның бертигез хокукта булырга тиешлеген исбатларга тырыша. Ләкин җитәкчелектә фикердәшләр тапмый. Бу вакытта Ленин зәгыйфьләнгән, үлем түшәгендә ята, ә Сталинның исә, киресенчә, көчәеп, ныгып килүе була. Ул, Ленин сүзләре белән әйткәндә, үз кулында иксез-чиксез власть туплый. Сталин хакимият дилбегәсенә ныклап ябыша. Аның өчен беркем дә авторитет булмый. Ул хәтта Ленинның үзен дә, аның «К вопросу о национальностях или об автономизации» исемле хатындагы Солтангалиев фикерләренә аваздаш тәкъдимнәрен дә РКП(б)ның XII съезды делегатлары алдында мыскыллап тәнкыйтьли. Әлбәттә, Солтангалиевнең карашларына да катгый рәвештә каршы чыга. Алай гына да түгел, шушы гаделлек сакчысын эзәрлекләү юлына баса, аны үзенең иң беренче сәяси корбаны итә.

Инде 1936 елның декабрендә, СССРның яңа Конституциясе проекты буенча ясаган докладында Сталин: *«Татарстан һәм Башкортстан союздашлык статусын үз колакларын күрә алмагандай күрмәячәк»,* – дип көлә. Шулай итеп, моңарчы ике халык, ике республика арасына чөй кагып килгән Сталин, аларны бер җепкә тезеп, икесен дә союздаш республика статусыннан мәхрүм итә.

Югыйсә Татарстан бу статуска тулысы белән өлгергән-җитлеккән республика иде. Шушы уңайдан РСФСР Халык Комиссарлары Советы рәисенең урынбасары, казакъ Тырар Рыскуловның 1926 елгы бер киңәшмәдә: *«Россия составында ике төрле республика бар...»* – дигән сүзләрен искә төшерәсем килә. Ул аларның беренче төренә бары тик Татарстанны гына кертә. Чөнки Татарстан, аныңча, тулысы белән үз мөмкинлекләренә таянып яши. Республиканың алга киткән язма культурасы, дәүләт теле дәрәҗәсендәге теле, тиешле дәрәҗәдәге кадрлары бар, ди. Икенче төр республикалар бары тик Совет хөкүмәтенең мәрхәмәте аркасында гына яшиләр, ди. Тырар Рыскулов бу чыгышында, татарларны бик үк өнәми торган кеше булуына карамастан, аларның дәүләти халык икәнлегенә басым ясый.

Әмма 1936 ел Конституциясе кабул ителгәч тә, «өлгергән» Татарстан элекке хәлендә калды, «өлгермәгән» республикалар исә СССР составына яңа статуста кабул ителде. Нәтиҗәдә, Татарстан автономиясенең исеме генә сакланды диярлек. Җисеме юкка чыгарылды. Ул дәрәҗәсе ягыннан өлкә һәм крайлар белән тигезләштерелде. Дөрес, алга таба союздаш республикаларның хокуклары да көннән-көн кими торды. Алар да өлкәләр белән тигезләшүдән ерак түгел иде. СССР таркалу сәбәпләреннән берсе – шул. Ләкин монысы аерым тема.

Үзгәртеп кору сәясәте Татарстан һәм Башкортстан өчен суверен республикага әверелү мөмкинлеге тудырды. Шул ук вакытта бу мөмкинлектән ялгыз рәвештә файдаланып булмаячагы көн кебек ачык иде. Россиядәй алагаем зур империяне унитар рельслардан тартып төшереп, демократик, федератив рельсларга бастыру Татарстанның гына көченнән килерлек эш түгел иде. Максатка ирешүнең шарты – республикаларның бердәмлеге. Шушы бердәмлекнең нигезе Татарстан булса, аның иң якын аркадашы Башкортстан булырга тиеш иде. Бу республикаларга тарихның иң җаваплы көннәрендә кулга-кул тотынышып эш алып бару зарур иде.

М.Ш.Шәймиев, шуны аңлап, ил буенча көрәштәшләр эзләде. Һәм, иң беренче чиратта, тугандаш башкорт халкына, башкорт республикасына өмет баглады.

Өмете акландымы соң? Көрәштәшләр таптымы? Бу сорауларга берьяклы гына җавап биреп булмый. Әйткәнемчә, декларацияләр кабул ителгән көннәрдә мондый бергәлеккә ирешү язмады. Ләкин бу әле җиңелү түгел, берләшү, туплану мөмкинлекләре бар иде.

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

Идел кичми ил булмас яки Тәтешлеләр һиҗрәте

Эльмира Сәлахова

Тәтешлеләр болгарлар белән «кыз алышкан»

Тәтеш ягы Болгар дәүләтенең мөһим өлеше булган. Иделнең ике як ярында урнашкан бер илнең халкы, әлбәттә, даими аралашкан. Тарихчы Гайнетдин Әхмәрев, Тәтеш тарафындагы Шонгаты халкы Болгар шәһәре белән «кыз алышкан, кыз бирешкән», дип яза. Галим бу хакта үзенең замандашлары сөйләгәннәргә нигезләнеп әйтә. Болгар шәһәре туздырылганнан соң, дәүләтнең икенче өлеше – Тәтеш ягы күпмедер дәрәҗәдә тыныч-имин булуы белән үзенчәлекле. Шул сәбәпле йорт-җиреннән аерылырга мәҗбүр булган халыкны ул үзенә сыендырган.

1552 елда Казан ханлыгы яулап алынгач, көчләп чукындыру сәясәте башлана. Бу вакытта да халык үз-үзен саклап калу өчен ата-бабалары яшәгән җирдән күчеп китәргә мәҗбүр ителә. Күчешнең сәбәпләре алга таба бу гына булмый, аңа башкалары да өстәлә. Укымышлы, зыялы Тәтеш ягы татарлары гыйлем нуры тарату максаты белән дә башка төбәкләргә барып чыга, авыллар нигезли. Җир азлыгы, ачлык та чит якларга күчеп китәргә сәбәп булган. Сезонлы эшкә барып, соңрак якташларын үз яннарына чакырып авыл коручылар да бар.

Тәтеш мәчете

Абдулла Алишның бабасы «Мең өйле Шонгаты»дан!

Ара ерак булса да, Тәтеш төбәге кешеләренең Самара губернасының Бөгелмә өязендәге, Уфа губернасының Уфа һәм Минзәлә өязләрендәге кайбер авыллар белән мөнәсәбәте барлыгы күренә. Мәсәлән, Ш.Мәрҗани Алиш бәк нәселенең борынгы «Мең өйле Шонгаты» җиреннән китеп, Иске Әлмәт авылына нигез салуы хакында яза. Марсель Әхмәтҗанов, Иске Әлмәт җирлегенә Алиш бәкнең кече улы Әлмөхәммәд (Әлмәт) 1650 елдан соң килеп төпләнгән, дип әйтә. Кызганыч, энциклопедик сүзлектә хәзерге Норлат районына кергән Иске Әлмәткә нигез салыну вакыты итеп 1730 нчы еллар күрсәтелә. Алиш бәк нәселеннән булган Гобәйдулла бине Җәгъфәр 1822 елга кадәр Иске Әлмәттә имамлык итә. Аның вафатыннан соң Гобәйдулла хәзрәтнең уллары һәм оныклары Әлмәтнең рухи яшәешендә, халкының аң-белем үсешендә зур роль уйный.

Әлбәттә, таза тормышлы морза гаиләләре бирегә үз биләмәләрен арттыру максаты белән килә. Әлмөхәммәд 1670 нче елларда ук Әлмәт төбәгенең бай морзасы була. Тәтеш ягыннан килгән Алиш бәкнең Багдан исемле улы һәм оныклары Чирмешән елгасы буйларында, хәзерге Апас районының көньягында урнашкан авылларда утарлар тоткан.

Шушы ук нәсел хәзерге Спас районына карый торган авыллар тарихы белән дә бәйле. Алдарак әйтелгән Гобәйдулла хәзрәтнең нәсел дәвамчысы Нигъмәтулла улы Нурулла Иске Әлмәттән Спас өязенең Көек авылына килеп гомер итә башлый. Ул Алишбәк нәселенең сигезенче буыны булса, шушы нәселдән чыккан балалар язучысы Абдулла Алиш (1908-1944) – бу нәселнең унынчы буын вәкиле.

Баллы Күлем, син кайдан? Тәтештән!

Әлбәттә, иң якын бәйләнеш Болгар дәүләтенең икенче як ярында яшәүче халыклар белән була. Шуңа мисал итеп, хәзерге Иске Баллы Күл авылын китерергә мөмкин. Археограф Сәед Вахиди үзенең фәнни экспедициясе вакытында картлар сөйләменнән Иске Баллы Күл авылының борынгы Болгар шәһәре янындагы авыл икәнен язып алган. Авыл кешеләре әйтүенчә, Казан ханлыгы җимерелеп, авыр чорлар башлангач, шушы авылга Тәтеш өязенең Күккүз авылыннан Бәйкә баба, Боерган баба һәм тагын бер нәсел күчеп утырган. Шулай итеп, Баллы Күлләләр белән Күккүз нәселләре туганнарча аралашып яшәп китәләр. Бирегә күченүнең сәбәбен халык үзе менә болай аңлаткан: *«Чукынмаган мөселманнарны авыллардан сөреп, икенче җирләргә таратканнар. Шулай итеп, бик күп мөселман авыллары әрәм булып беткән. Менә мондый авыр заманнар безнең әби-бабайлар өчен дә караңгы вә кайгы чоры булып, озак еллар шулай дәвам иткән. Дингә кыстау чакларында безнең бабайлар Тәтеш өязеннән күчеп килеп, Ыспас өязенең кап-кара куе урман белән чорналган бер почмагына, шәһре Болгар заманасыннан бирле дин исламны тотып килә торган бер авылга, әлеге Баллы Күл авылына килеп утырганнар»*. Археограф Сәед Вахиди экспедиция вакытында әлеге авыл кешеләренең тышкы кыяфәтләренә игътибар итеп: *«Баллы Күлдә минем белән мосахабәдә булган (аралашкан) бабалар, гомумән, ул авылда мин күргән кешеләр, ире һәм хатыны озын буйлы, мәһабәт кыяфәтле, үткен кара күзле, төреклек канын, төреклекнең җисмани җәһәттән булган бик күп хосусиятләрен саклап килгән кешеләр иде.*

Әгәр боларга яхшы мәктәп тәрбиясе бирелгән булса, боларның эченнән уйламаган эшлекле адәмнәр чыккан булыр иде дигән фикер килде», – дип яза. Тәтеш нәселләре килгәнче үк бу Баллы Күл кешеләре куркусыз, горур, баш бирми торган халык булып, шәригать кануннары белән яшәгән.

Баллы Күл авылы тарихы борынгы Болгар чорыннан ук килә, әмма белешмә сүзлектә аның нигезләнү датасы итеп XVII гасырның икенче яртысы күрсәтелә. Ә аннан аерылып чыккан Яңа Баллы Күлнең тарихы XVIII гасырдан башланганы әйтелә.

Ишем җәвере – Тәтештән

Тарихы борынгы Болгар чорыннан ук килгән Ташбилге авылында да Тәтеш өязеннән чыккан нәсел кешеләре булган. Авылда аларны Ишем җәвере (нәселе) дип йөрткәннәр. Ташбилге халкы үзенең шәҗәрәсен Болгардан килгән Мөслим бабага нисбәт иткән, ә Ишемнекеләрне, килеп кушылучылар буларак, бик яратып бетермәгәннәр. Алар монда сөргенгә җибәрелгән кешеләр булса кирәк. Сәед Вахиди авыл кешеләре авызыннан: *«Авылдагы җыртлач, усал куштаннар әнә шул Ишем җәверләреннән чыгып килгән, югыйсә Ташбилгенең үз халкы юаш, мәрхәмәтле, кешегә ярдәмче халыклар»,* – дигән юлларны язып алган.

Энциклопедиядә авылга нигез салыну вакыты итеп XVII-XVIII гасырлар күрсәтелгән.

Рәҗәп баба, син бит Олы Тарханнан!

Спас районындагы Иске Рәҗәп һәм Чәчәкле авыллары тарихының башы Тау ягындагы Бигеш дигән кеше белән бәйле. Тау ягы мирзасы Бигеш 17 нче йөздә рус хөкүмәтендә яллы хезмәттә була. Билгеле булганча, йомышлы хезмәттәге мирзалар башка төбәкләргә дә күчерелгән. Бигеш исә Кама аръягына төпләнә. Спас районындагы Рәҗәп авылына Бигеш нәселеннән булган Рәҗәп баба нигез сала. Рәҗәп баба үзе Тәтеш янындагы Олы Тархан кешесе. Аның нәсел шәҗәрәсе Ризаэддин Фәхреддиннең Санкт-Петербургтагы «Шәҗәрәләр мәҗмугасы»нда сакланган. Бу нәсел Болгардан алып хәзерге Әлмәт шәһәренә кадәр булган җирләрне биләгән. Нәсел дәвамчылары бүген дә ата-бабалары туфрагында яшәвен дәвам итә.

Типтәр, «башкортлар» да Тәтештән!

XVII-XVIII гасырларда Уфа губернасының Минзәлә, Самара губернасының Бөгелмә өязләренә караган җирләргә татарлар килеп төпләнә башлый. Алар, нигездә, Казанга якын булган авыллардан киткәннәр. Араларында, татарлардан кала, мари, чуаш һәм удмуртлар да була. Килеп җир алган, шунда яшәп калган татарлар «типтәр», «яңа башкорт», «башкорт» дигән сословиене тәшкил итә. Хәзерге Башкортстанда типтәрләр тарафыннан нигезләнгән авылларның исемнәренә игътибар итсәк, халкының кайдан күчеп килүе турында һич ялгышмый әйтергә мөмкин. Тарихчы Г.Әхмәрев тә «Тептяри и их происхождение» дигән хезмәтендә исемнәре ягыннан охшаш 28 авылны атый. Шулар арасында Тәтеш өязендә очрый торган Апас, Бәйрәш, Балтач, Бик, Дәүеш, Ишеево, Ишем, Ишле, Карабай, Кормыш, Келәнче, Келәш, Тинкәш, Турай һәм Чаллы топонимнары Минзәлә, Бәләбәй,

Бөре, Уфа һәм Эстәрлетамак өязләрендә дә бар. Галим фикеренчә, бу авылларның тарихында Тәтеш ягы халкының да роле зур. Борынгы шәҗәрәләр дә, халык хатирәләре дә әлеге бәйләнешне раслый. Мондый күчеш XX гасыр башында да дәвам иткән. Мисалга Тәтеш өязенә кергән Бикмораз авылыннан Әлмәт ягына киткән нәселләрне атарга була.

Тәтешлеләр Әстерханга нигә барган?

Аралар бик ерак булса да, Тәтеш ягы татарларының Әстерхан белән тарихи бәйләнеше бар. Тәтеш өязенә кергән авыл кешеләреннән хәзерге көнгә кадәр: «Безнең Әстерхан ягында туганнарыбыз бар» яисә «Балачагымда Әстерханнан туганнар кайтып йөри иде», – дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Хәтта: «Әти безне Әстерханга алып китмәде, ачлыктан монда да исән калдык», – диючеләр дә очрый.

Әстерхан якларына барып чыгуның берничә дулкыны һәм сәбәбе бар. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, рус дәүләтенә керергә өлгермәгән татарлар Әстерхан ханлыгына йорт-җир эзләп күчеп киткән, соңрак руслаштыру, чукындырудан качып китүләр дә булган. Әлбәттә, татарлар әлеге якларга сәүдә итү өчен дә күпләп агылган. Белүебезчә, Әстерхан – сәүдә өчен бик уңайлы урын. Аның аша Кытай, Һиндстан, Иран кебек шәрык илләре белән тауар әйләнеше барган. Моннан кала, кышын сезонлы эшкә китүчеләр, балык тоту, яисә төрле авыр хезмәтләргә ялланып тамак туйдыручылар да табигать шартлары күпкә уңайлырак булган Әстерханда төпләнеп калган.

Бу якка китүнең тагын бер сәбәбе – ачлык, аннан репрессия, мал-мөлкәтне тартып алу. 1930 нчы елларда Әстерхан тарафына Казан тирәсендәге бик күп татарлар гаиләләре белән күчеп китә. Хәзерге Әстерхан өлкәсенә килеп төпләнгән Урта Идел татарлары, нигездә, шәһәрнең татар бистәсе Тиярктә яшәп калганнар. Килүчеләр арасында Пенза, Түбән Новгород һәм Самара губерналары татарлары да күп була. Казан губернасыннан, ягъни хәзерге Татарстаннан да Әстерхан якларына күчеп килүчеләр шактый. Әмма алар арасында Тау ягы кешеләре күпчелекне тәшкил иткән. Моны Әстерхан шәһәренең метрика кенәгәләрендәге язмалар да раслый. Мисал өчен, Әстерхан шәһәре метрика кенәгәләрендә Тәтеш районындагы Коллар авылы (Кызыл Тау), Коштау, Табар Черкене, Бакырчы, Урта һәм Түбән Балтай, Колгана, Буа районының Бәбки, Әхмәт, Ташкичү, Кабалан, Күзби һәм башка авыл кешеләренең исемнәрен күрергә була. Аларның күбесе туганнары белән Әстерханга китеп төпләнгән. Татар бистәсендә яшәүчеләрне теркәгән 1744 елгы документта да килүчеләрнең зур өлеше Тау ягыннан булганлыгы күренә. Мисал өчен, аларның Бәке Йомралысы, Яңа Сала, Әхмәт, Балтай, Аллабирде, Келәш, Зөябаш кешеләре икәнлеге теркәлгән. Күчеп килүнең сәбәбе хезмәт урынына бәйләп аңлатыла.

Урта Идел төбәгеннән Әстерханга килгән кешеләрне җирле татарлар ничек кабул иткән соң? Биредә озак еллар яшәүче татарлар Югары һәм Урта Иделдән килгән милләттәшләрен бик җиңел, гадәти туганнары кебек кабул иткән. Әмма Казан татарлары әүвәл җирле татарлар белән гаилә кормаган. Никахлары күбрәк үзара булган яисә Тәтеш кешеләре, матди файда өмет итеп, сөекле кызларын җирле байларга, сәүдәгәрләргә генә кияүгә бирергә тырышкан. Соңрак җирле халык белән дә никахлар ешайган. Моны Әстерхан шәһәренең метрика язмалары раслый. Килүчеләр, әйткәнемчә, Әстерхан шәһәренең Татар бистәсендә төпләнгән.



Урта Иделдән Әстерхан шәһәренә күчеп килүчеләр исемлеге. Әстерхан өлкәсенең Дәүләт архивы. 394 ф., 1 тасв., 1021 эш, 1 кгз., 1744 ел

Ә менә сату-алу яисә һөнәрчелек белән кәсеп итмәгәннәре, җиргә якынрак булу өчен, нигез кору урыны итеп авылларны сайлаган.

Болгар иленнән – Яңа Болгарга

XIX гасырның 70-90 нчы елларында, ачлыктан һәм эпидемиядән качып, атаклы рухани, Коръәнне яттан белүче, үләннәр белән дәвалаучы Исмәгыйль Искәндәрев гаиләсе белән Яңа Болгар җирләренә килеп төпләнә. Әстерхандагы Болгар авылын нигезләүчеләрнең күбесе Казан ягыннан чыккан кешеләр була. Әмма ара-

ларында Тәтеш ягы кешеләре дә бар. Мәсәлән, Шәмәк авылыннан Габделхак Нәҗметдинов, Хәлиулла Мәҗитов; Тәтешнең үзеннән Мөхәммәдьяр Хөсәенев (1905 елда туган); Сираҗетдин Әмиров тә чыгышы белән Тәтеш өязе авылыннан; Шәйдулла Фәхреддинев, Мәрфуга Мөгарипова, Гайнулла Бакиевлар – Тау ягыннан килеп төпләнгән кешеләр. Араларында Спас өязе кешеләре дә бар.

Тирә-яктагы казан татарларын бергә туплап, 1918 елда оешкан Яңа Болгар авылына ни өчен шундый исем сайланганы аңлашыла. Идел буенда яшәгән халыкларның йорт-җирләре туздырылган. Әмма алар үз дәүләтләрен сагынган, яңа яшәү урыннарына борынгы дәүләт исемен кушып, тарихи дәвамлылыкны, бергәлекне сакларга тырышкан.

Әстерхан төбәгенә күчеш даими барган. Мәсәлән, Габделхак Мәҗитов Комаровка авылында кибет тота; Сәлимҗан Хәбибуллин Малявка авылында төпләнә (хәзер Волгоград өлкәсенә керә), аннан Әстерхан губернасының Тишково авылына күченә, соңрак якташлары нигезләгән Яңа Болгар авылына килеп гомер кичерә. Сираҗетдин Әмиров та 1918 елда Тишково авылыннан Яңа Болгарга күченә. Казан һәм Тәтеш якларыннан килүчеләр Майлы Күл, Каргалык, Кызан һ.б авылларда да яши.

Тәтешлеләр – Татар Илендә!

XIX гасыр азагы мәгълүматларына караганда, Тәтеш ягыннан Оренбург губернасына китеп урнашучылар да бар. Шулай ук Уфа, Томск һәм Тубыл губерналарына, Петербург шәһәренә күчеп китүчеләр дә байтак.

Әлбәттә, тәтешлеләр күченгән җирләр татар халкы өчен чит-ят төбәк түгел, ягъни бу якларга килеп төпләнү һич кенә дә очраклы күренеш булмаган. Тәтеш ягы белән Спас төбәгенең элемтәләре – Иделнең ике як ярында булган бердәм дәүләт халкының гасырлар дәвамында өзелмәгән тарихи бәйләнеше. Әйткәнемчә, Әстерхан белән элемтәнең дә тарихи нигезе бар. Казан ханлыгы чорыннан ук (ә бәлки, аннан да иртәрәктер) Хаҗитарханнан, Әстерхан төбәгеннән Тау ягына килеп нигез кору очраклары булган. Оренбург, Уфа һәм Себер җирләре дә – Алтын Урда заманыннан калган татар биләмәләре. Кыскасы, кайда борынгы татар җире һәм Татар Иле – тәтешлеләр шунда күченгән, гаилә корган, ил-йортка тугры балалар тәрбияләп, затлы нәсел калдырган. ■

«

Кыскасы, кайда борынгы татар җире һәм Татар Иле – тәтешлеләр шунда күченгән, гаилә корган, ил-йортка тугры балалар тәрбияләп, затлы нәсел калдырган.

Редакциядән: Журналыбызның 2021 елгы август санында тарихчы-этнограф, Салехард шәһәрендәге Арктиканы фәнни өйрәнү үзәге фәнни хезмәткәре Наилә Галиеваның «Себернең югалган Казаны» исемле мәкаләсе басылып чыккан иде. Әлеге мәкаләдә Тәтеш өязендәге Куккуз һәм Аллабирде авыллары кешеләренең хәзерге Омск өлкәсендәге Казан исемле авылга нигез салулары бәян ителә.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

Тәтештәге татар тормышыннан кайбер фактлар

Тәтеш шәкертләре. XX гасыр башы

1

Тәтештә беренче татарча спектакль. 1917 елның 9 июле

«Народный дом» бинасында «Тәтеш өязе укытучыларының оешмасы» файдасына яшьләр тарафыннан спектакль һәм концерт бирелде. Кичәнең мәсьүл *(җаваплы)* мөдире – С.Бакый, режиссеры М.Вәлишин әфәнделәр булып, «Кызлар шулай кызык итәләр» берлән «Көчләп кияүгә бирмиләр» комедияләре куелды. Концерт кыйсемендә туташ вә егетләремездән укмаштырылган хор тарафыннан төрле милли көйләремез җырланды, декламацияләр вә шигырьләр укылды.

Кичәгә халык көтелгәннән артык килеп, «Народный дом» бинасы шыгрым халык берлән тулы иде. Уеннар бик тәртипле һәм матур үтеп, халыкның күңеленә бик ошады. Уен беткәч, халык уйнаучыларга һәм кичәне ясарга хезмәте тигән әфәнделәргә чын күңелдән рәхмәтләр укып, киләчәктә дә шундый матур кичәләрне ясауларын кат-кат үтенде. Хәтта авылдан килгән берничә карт хәзрәтләремез дә яшьләрнең бу күрекле *(матур)* эшләренә тәхсиннәр *(мактау сүзләре)* әйтеп киттеләр.

Тәтешнең тарихында беренче мәртәбә булган, «Тәтеш» бабайның Тәтеш нигезен салудан алып бу көнгә чаклы булган мөддәттә *(арада)* беренче мәртәбә уйналган бу театр халыкның күңеленә бик ятты. Һәркайда булып узган «Беренче театр» вакыйгалары безнең Тәтештә булмады.

Чыганак: «Тәтеш оешмасы». – 1917. – 19 июль.

Тәтеш шәһәрендә мөселман укытучылары съездлары

Беренче съезд 1917 елның 25 июнендә була. Аны Мозаффар Мөштәриев, Кариб Вәли, Фәйрүзә Маликова һәм Маһруй ханым Мозаффариянләр оештыра. Җыелышта Тәтеш өязе укытучыларының оешмасын төзү мәсьәләсе карала. *(«Тәтеш оешмасы». – 1917. – 7 июль.)*

26 августта «Народный дом»да икенче җыен уза. Җыенда 10лап укытучы, 25ләп мулла катнаша. Иң күп тавыш алган Мозаффар Мөштәриев Тәтеш өязе мөселман мәктәпләре өчен инструктор булып сайлана. Эш барышында мөгаллимнәр белән имамнар арасында укыту мәсьәләсендә каршылык туа, «Бу съездның өчтән ике өлеше Мөштәриевләр» дигән дәгъва да белдерелә. *(«Тәтеш оешмасы». – 1917. – 26 сентябрь.)*

Өченче съезд 27 сентябрьдә Гариф әфәнде Халиди рәислегендә, Исхак Казаков, Кариб Вәли, Шәһит Гадельшин, Кадир Халидовлар катнашында уза. Җыенда: «Муллаларны рәсми мөгаллим итеп таныргамы, юкмы?» – дигән мәсьәлә күтәрелә һәм мондый карарлар кабул ителә: 1) рәсми укытучы булып мөгаллим-мөгаллимәләрдән башка кешеләрнең укытуга катнашырга һич хаклары юк; 2) әүвәлдән яңа тәртип белән укыткан бер мулла, моннан соң да рәсми мөгаллим булып калырга теләсә, ул мулла үзенең муллалык лөзүмен ташларга тиешле; 3) әгәр бер мулла моңар кадәр кимчелексез яңа тәртип белән укытып килгән булса, рәсми рәвештә ачылачак мәктәпләргә аңлы укытучылар җитешкәнчегә кадәр аңа шул авылда мөгаллимлек итеп торырга мөмкинлек бирелер; 4) һәр мулла үз мәхәлләсендәге рәсми мәктәпкә дин мөгаллиме сыйфаты белән керергә хаклы булып, земство тарафыннан үзенә билгеләнгән хезмәт хакын алыр, укытучы вазыйфасына катнашмас. *(«Тәтеш оешмасы». – 1917. – 1 ноябрь.)*

Тәтеш мәчете. XX гасыр башы

Тәтештә мөгаллимәләр курсы. 1917 ел

Курсларны миңа байтак эзләп йөрергә туры килде. Ул әллә кайда, шәһәрнең тышындагы бер рус мәктәбендә икән. Йөри торгач, барып таптым. Мәктәп үзе тышыннан бик матур. Киң бер урында зур агач йорт. Мин барып кергәндә инде кызлар торып дәресләрен хәзерләп яталар иде. Дәресләр башланмаган иде әле. Курсның мөгаллимәләреннән Маһруй Мозаффария белән таныштым.

Тәтештә булган өяз мөселман комитеты, алдагы уку елы өчен мөгаллимәләр кирәк булачагын игътибарга алып, Тәтеш каласында ай ярымлык мөгаллимәләр курсы ачарга карар биргән һәм өяздәге әһалиягә *(хатын-кызларга)* кызларын укыту тиешлеген аңгарту юлларына керешкән. Курсларның матди җәһәтен тәэмин итәр өчен, Тәтеш земский управасына акча сорап мөрәҗәгать иткән. Шул ният белән Маһруй Мозаффария ханым үзе, өяздәге авылларга чыгып, хатын-кызны укырга әйтеп йөргән. Билгеле, аны бик күп авылларда кара чырай белән каршы алганнар. Күп авылларның имамнары, халыклары аны ачуланып та җибәргәннәр. Шуның белән бергә, бик күп авыллардагы хатын-кызлар Мозаффария ханымны рәхмәтләр укып озатканнар һәм мөмкин кадәр укырга тырышырга вәгъдә биргәннәр. Озак та үтмәгән, управа мәзкүр курсларга биш йөз рублә тәгаен иткән һәм шул сумма белән июльнең 15ендә курслар ачылып, уку да башланган. Укыту эшләрен алып барыр өчен мөгаллим Вәлиуллин, учитель Халиков әфәнделәр белән мөгаллимә Маһруй Мозаффария тәгаен ителгәннәр.

Маһруй Мозаффария балалары Габбаса һәм Мансур белән. Казан, 1910 нчы еллар

Өяздән барысы 75ләп укучы туташ һәм ханым-әфәнделәр килгәннәр. Аларның арасында күбесе – мулла, сәүдәгәр кызлары. Байтак кына остазбикә-абыстайлар да бар. Илле яшендәге бер остазбикә абыстай үзенең буйга җиткән кызы белән килгән. Укучылар арасында бишләп Тәтеш гимназиясендә укучы кызлар да бар. Укыла торган дәресләр: ана теле (сарыф, имля һәм инша дәресләре шулар эчендә), милли тарих, җәгърафия (кыскача сураттә Яуропа, Азия, Африка, Америка, Австралия, Яуропаи рус аеручa мөфассәл *(җентекле)* сураттә укыла), голүм диния, Коръән тәҗвид белән, ысул тәгълим *(укыту методикасы)* вә тәрбия. Туташлар да,

абыстайлар да гаять дәрәҗәдә тырышып укыйлар. Укуга чын мәгънәсе белән сусаганнар. Үзләрен шушы курсларга эләгү белән бәхетле саныйлар һәм мөмкин кадәр күп файда алып калырга тырышалар. Дәресләр иртә белән сәгать тугызда гына башланса да, инде сәгать бишләрдә үк уянып эшкә керешкән булалар. Курсларны өстән генә бер карап чыкканда да Тәтеш өязе туташларының укуга никадәр сусаганлыкларын аңгарып була.

Туташларның күбесе шул курсларда ук пансионатта торып укыйлар. Уку хакы итеп һәрберсеннән 15 рублә алына.

Мин берничә дәрестә булдым. Укыту лекция тәртибе беләнрәк бара икән. Мөгаллимә туташларны укытуга өйрәтү өчен ун баладан гыйбарәт нәмүнә шөгъбәсе *(педпрактика өчен төркем)* дә бар икән. Шунда мөгаллимәләр укытырга өйрәнәләр.

Чыганак: «Сөембикә» – 1917. – №3. – Б.242-244.

Тәтеш типографиясе. 1918 ел

4 Олы Тарханда һөнәрчелек мәктәбе. 1908 ел

Безнең мөселманнарда сәнәгать эшләре башланды: Олуг Тархан карьясендә Сембер өязе җәмгыяте тарафыннан алты балалык бер һөнәр мәктәбе ачылмыштыр. Бу мәктәптә балаларга рам ясамак һөнәрен вә, гомумән, столяр эшләрен үгрәтәчәкләр. Бик мәкбуль эш. Бу һөнәр мөселманнарга ике көннең берендә лязим булган һөнәрләрдәндер.

Волга буйлары гүзәл урманнары илә мәшһүрдер. Урман эчендә утырган бу карьядә сәнәгать тәрәккъый итәчәге *(үсәчәге)* шөбһәсездер. Бер, ике, өч елдан соң милләт боларның файдаларын күрә башлаячактыр. Алты бала һәркаюсы алтышар балага остаз булачактыр. Җәнап Тәгалә күп гасырлар дәвамын мийәссәр әйләсен!

Чыганак: «Икътисад». – 1908. – №4. – Б.109.

Рәйсә Шәрәфиева *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Гыйлем Камай – Казан университеты ректоры

Химикка Гомер кирәкме?[1]

Гыйлем Камай

[1]Мәкалә «Правда» газетасының 42 нче (1968 ел, 11 февраль) санында басылган.

Бер очрак хәтергә килә. Томск университетында химиядән имтихан биргәндә, олы яшьтәге бер профессор студентның буяулар турындагы җавабын бүлеп, аның Монега мөнәсәбәте турында сораган иде.

Егерменче еллар башында булды ул. Дөресен генә әйткәндә, университетка солдат шинеленнән килгәннәр арасыннан беребез дә бу сорауга анык кына җавап бирә алмас идек. Безнең берниндди Моне хакында ишеткәнебез юк иде. Бичара студент та дәшми калуны хуп күрде.

– Химикка рәсем сәнгате белән кызыксыну мәслихәт, – диде профессор, – әйе, әйе, кадерле хезмәттәшем!

Һәм студентның буяулар турындагы җавабы шактый тулы булуына карамастан, аңа бик югары булмаган билге куйды. Без әлеге очракны, шаяртып, «Монега төзәтмә» дип йөртә башладык. Әмма башта коридорда «пар чыгарып» алдык әле.

– Тәртипсезлек! – диде кемдер. – Болай булса, Гомерга да күп калмас әле.

Шактый вакытлар узгач, мин моны Александр Ерменингельдович Арбузовка сөйләдем. Галим бичара студенттан кычкырып көлде.

– Профессор Гомерга да барып җитәргә мөмкин иде, дисезме? Әйбәт-әйбәт. Химик Зинин «Одиссея»ны оригиналда укый, хәтта яттан сөйли иде. Ул, мәсәлән, Лермонтовның «Демоны» поэмасын бүлекләп-бүлекләп, «Мцыри»ны юлын-юлга сөйләп бирә ала иде. Бәлки, башын юк-бар белән тутыргандыр? Химикка Гомерның яки... Моненың ниемә кирәге бар?!

Соңрак Ван Гог, Гоген, Моне картиналарын күргәнем булды. Буяуларның тыгызлыгы, авторларның дөньяга үзгә карашлары таң калдырды мине. Константин Паустовский «Алтын гөлчәчәк» әсәрендә Моне тормышыннан бер кызыклы эпизод китерә. Рәссам, Лондонга килгәч, Вестминстер аббатлыгын рәсемгә төшерә. Лондонның гадәттәгечә томанлы бер көнендә эшли ул. Картина әйбәт килеп чыга. Әмма Лондон халкы, аны күргәч, канәгатьсезлек белдерә: Моне томанны куе кызыл төстә итеп сурәтләгән. Гәрчә томанның соры төстә булуы һәркемгә мәгълүм ләбаса! Бары тик ныклабрак күзәткәч кенә, тәнкыйтьләүчеләр чыннан да шәһәр өстендәге томанның куе кызыл төстә булуын күреп ала.

Шишкин, Репин, Айвазовский, Куинджи картиналарына күз салыгыз һәм сез аларда тормышның элек игътибар итмәгән бик күп якларын күрерсез. Боларның барысы да галим кешене дә уйландырмыймыни?

Академик Арбузов еш кына болай дип кабатлый иде: *«Шигърият үрләре, рәсем сәнгате осталарының картиналары, яхшы музыка белән таныш булмаган химикны күз алдына да китерә алмыйм. Болар белән кызыксынмый торган химик үз өлкәсендә дә әллә ни зур эшләр башкара алыр дип уйламыйм... »*

Мөгаен, болай уйлау артыгы белән катгыйдыр да. Әмма асылда дөрес. Беренче тапкыр Арбузовларга килгәч, мин хәтта югалып калган идем. Гүя биредә химик түгел, ә берәр музыкант яши дигән тәэсир калган иде: кунак бүлмәсендә ике рояль, скрипкалар... Кичләрен биредә Бетховен, Гайдн, Бах көйләре яңгырый иде. Арбузов үзе дә скрипкада виртуозларча уйный, һәвәскәр оркестрларда бик теләп чыгышлар ясый.

Бородинны искә алу кичәсен яхшы хәтерлим. Александр Ерменингельдович, илһамланып, бөек химиклар – Бутлеров, Менделеев турында сөйләде. Аннан соң кафедра хезмәткәрләре белән Бородин музыкасын башкарды.

Яшь чагында Арбузов рәсем сәнгате белән дә мавыккан. Кайбер сынлы сәнгать осталары аңа рәссамлык иләчәге дә юраган булганнар. Өметләре акланмаган.

Арбузов, латин, немец һәм француз телләрен камил дәрәҗәдә белсә дә, лингвист булып та китмәгән. Химияне өстен күргән. Сәнгать аңа безнең заманның күренекле химигы булырга ярдәм иткән дип курыкмыйча әйтә алам.

Кайберәүләрнең каршы әйткән сүзләрен алдан күрәм: «Ну, музыка яки, әйтик, рәсем сәнгате химикка нәрсә бирә ала?!»

Тарихта сәнгатьнең табигать кануннарын ачкан очраклары билгеле түгел. Һәрнәрсәнең үз урыны: табигать кануннарын галимнәр ачканнар һәм моннан соң да ул шулай булачак. Сәнгатьнең бурычы башка. Ул матурлык һәм ямьсезлек, бөек һәм түбән, трагик һәм комик категорияләр турында белем бирә, иҗади күзаллауны үстерә һәм фикерләргә өйрәтә.

Оппонентымның: «Шуннан ни?» – дип төпченүен ишетәм.

Шуннан менә нәрсә. Табигатьнең төгәл, шуның белән төрле гармониясе эстетик яктан үсешкә ирешкән кешегә аңлаешлырак була.

Фән турында гомуми итеп сөйләп тормыйм. Миңа химия якынрак. Химик реакцияләрнең, формулаларның, нечкә экспериментларның эчке бер гүзәллеге һәм шигърияте бар.

Гыйлем Камай кызы Светлана Камай белән

«

Сәнгатьнең бурычы башка. Ул матурлык һәм ямьсезлек, бөек һәм түбән, трагик һәм комик категорияләр турында белем бирә, иҗади күзаллауны үстерә һәм фикерләргә өйрәтә.

Арбузов, мәсәлән, матдәнең үзеннән бигрәк, аны алу процессына күбрәк шатлана иде. Ул, сәгатьләр буена ретортларга, колбаларга карап, реакцияләрнең матурлыгына һәм нәфислегенә сокланып утыра иде. Ә аларда «и жар холодных числ, и дар божественных видений»[2].

Бутлеровның фәнгә юлы нәкъ шуннан башланган да. Ул, үзе әйтүенчә, әүвәл химик күренешләрнең тышкы ягы белән мавыккан, азобензолның кызыл пластиналарын, азоксибензолның сары төстәге энәле кристаллашуын һәм бензидинның көмешсыман тәңкәләрен аерым бер кызыксыну белән сокланып күзәтә торган булган.

«Хәзерге заманның һәрбер химия дәреслеге урта гасырлардагы алхимиклардан, фәлсәфә ташын эзләүчеләрдән каһкаһә белән көлеп башланса да, лаборатория бусагасын беренче тапкыр атлап кергән һәрбер яшь егет, эченнән бераз гына алхимик була һәм заманча фәнни ысуллар, ул вакыттагы эзләнүләрнең башында то-

[2]Александр Блокның «Скифы» шигыреннән.

ручылар дәвере белән чагыштырганда, бары тик яңа көч, яңа дәрт бирә». Михаил Пришвин үзенең «Кащей чылбыры» дигән автобиографик романында әнә шулай дип яза.

Химизмның тышкы ягы, тикшеренүләр алып барганда, һәрвакытта да соңгы урында тормый. Классик архитектураның камиллеген яраткан химик үзенең тикшеренүләрендә тупас иҗатка юл куймый. Ул матдәләрнең эчке тәртибендә һәм формасында, молекулаларның структурасында гүзәллек эзләячәк. Структуралы теорияне иҗат итүчеләрнең берсе, күренекле немец химигы Кекуле архитектураны очраклы рәвештә генә өйрәнмәгән. Архитектура формаларын белү, бәхәссез, аңа молекулалар структурасын эзләүдә ярдәм иткән. Структура гүзәллегенә, аның симметрияле камиллегенә омтылу химикның тикшеренүләрендә еш кына этәргеч була, яңа матдәләр табу максатына әверелә. Формалар камиллегенә омтылу тикшеренүчегә менә дигән ачышлар ясарга мөмкинлек бирә.

Органик химия торган саен романтик характерга ия була бара. Ул табигать белән тылсым буенча ярыша. Һәм, әйтергә кирәк, уңышсыз да түгел. Элек алхимикларның хыялында гына булган әйберләр бүген инде чынбарлык. Химик матурлык тудыра. Якын араларда югары уку йортларында, мисал өчен «Химия һәм эстетика» дигән дәрес укытыла башласа, мөгаен, бер дә гаҗәп булмас. Чөнки күп кенә эстетик категорияләр хәзер үк инде химиклар өчен «үз» булып китте, синтетик химия буенча кайбер фәнни китапларда сәнгати башлангычларга махсус бүлекләр багышлана.

«

Органик химия торган саен романтик характерга ия була бара. Ул табигать белән тылсым буенча ярыша.

«

Фән белән шигъриятне күп нәрсә бәйли.

«

Аспирантурада укыган елларымда мин талантлы татар шагыйре Һади Такташ белән дуслашып киттем.

Фән белән шигъриятне күп нәрсә бәйли. Берничә ел элек «Фән» нәшриятында «Лермонтов дәфтәрләрендә» дигән китап дөнья күрде. Аның авторы әдәбият белгече дә, хәтта шагыйрь дә түгел. Әлеге үзенчәлекле хезмәт танылган сәяхәтче Сергей Владимирович Обручевныкы (академик Обручевның улы).

Геологны аның өйрәнә торган проблемаларыннан ерак торган серне ачу өчен вакыт сарыф итәргә нәрсә мәҗбүр итте икән соң? Кызыксынучанлык кынамы? Юктыр дип уйлыйм. *«Яшь шагыйрьнең шигырьләрендә тикшеренүчеләр өчен шактый катлаулы эзләнүләр һәм бәхетле табышлар яшеренгән!»* Бу – авторның үз сүзләре. «Катлаулы эзләнүләр» һәм «бәхетле табышлар» – мөгаен, геологны эзләнүләргә шушылар этәргәндер.

Аспирантурада укыган елларымда мин талантлы татар шагыйре Һади Такташ белән дуслашып киттем. Аның «Гасырлар һәм минутлар» дигән әсәре В.И.Ленинга багышланган. Такташ – бик популяр, иң укыла торган шагыйрь. Кызганыч, аның гомере бик иртә – утыз яшендә өзелде.

Такташ белән без Кави Нәҗминең фатирында очраштык. Тиз ярсучан, җилсенгән күзле Такташ һәлакәткә дучар ителгән кешене хәтерләтә иде. Ул миңа игътибар итмәде. Химик икәнемне белгәч, шунда ук үзгәрде. Ул миннән аерым бер кызыксыну белән төсләр турында сорашты. Аны салават күпере аеруча кызыксындыра иде, химик буларак, миңа төсләрнең «уены» ничек күренә, дип кызыксынды. Такташ лабораториягә килеп йөри башлады, матдәләрнең үзгәрешләрен сокланып күзәтә иде. Төсләрнең күчеш процессын – төссездән сарыга, сары-кызылга, кызылга, шәмәхәгә, зәңгәргә, яшелгә, карага үзгәрүен хәтеренә йотлыгып сеңдерә иде ул.

Такташ шигърияткә Пушкин, Лермонтов, Маяковскийлардан өйрәнеп килгән. Соңрак, мин Германиядә булып кайтканнан соң, ул, Һейнены тәрҗемә иткәндә, миңа ярдәм сорап мөрәҗәгать итә иде. Һәрвакыт оригиналны тәрҗемәләре белән чагыштыра иде.

Һейне, Лермонтов һәм Тютчевның иҗатындагы кыргый, төньякта үскән нарат-лар аңа тынгы бирми иде. Бер караганда, бер үк мотив, авторлар бер үк фикерне җиткерергә теләгәннәр кебек, сүзләре дә шул ук, әмма бөтенләй башка төсмер, шигырьнең яңгырашы да башка. Такташны нәкъ менә шулары кызыксындыра да иде инде.

Такташ белән дуслык минем өчен дә эзсез үтмәде. Мавыгучанлык, предмет-ка төрле яклап карарга омтылыш – шагыйрьгә генә кирәкле сыйфатлар түгел бу. Аның белән дуслык миндә тикшеренүче холкына хас сыйфатлар булдырырга ярдәм итте.

Фән елдан-ел катлаулана бара, абстракцияләр дөньясына таба китә. Кайсыдыр бер галим хәзер инде физиканы шигырь белән язып булмый, дип, очраклы гына әйтмәгән. Минемчә, алай кирәкми дә. Шигърият тә үзгәрде, фәнгә үтеп керде һәм тикшеренүчеләр белән янәшә бара, кайчак хәтта алга китеп, сораулар да куя.

Владимир Солоухинның «В узел связаны нити» шигырен укыгыз да уйланыгыз әле:

«Вы проходите мимо цветка?
Наклонитесь,
Поглядите на чудо,
Которое видеть Вы раньше
нигде не могли.
Он умеет такое, что никто
на земле не умеет.
Например... Он берет
крупинку
мягкой черной земли,
Затем он берет дождя дождинку.
И воздуха голубой лоскуток,
И лучик, солнышком пролитой.
Все смешает потом
(но где?!
Где пробирок, и колб,
и спиртовок ряды?!),

И вот из одной и той же
черного цвета земли
Он то красный, то синий,
То сиреневый, то золотой!»

Биредә табигатькә, аның гүзәллегенә соклану гына түгел. Шагыйрь гүя чәчәкнең иҗат лабораториясенә үтеп керергә, физиология могҗизасын аңларга тырыша кебек. Бу шигырь – мәһабәт табигать турында фәлсәфи трактат.

Шушы ук сүзләрне Эдуардас Межелайтисның «Кеше» циклыннан теләсә кайсы шигыре турында әйтергә була.

Шигъриятнең мондый катламнарын күтәрү җиңел түгел. Саллы тырышлыклар, үз өстеңдә даими эшләү, гыйлем кирәк моның өчен. Биредә инде фән шигъриятькә дуслык кулы суза. Асылда, тормышта да, табигатьтә дә барысы да үзара менә шушылай бәйләнгән.

«

Әдәбият, сәнгать кешене затлы итә, аның зәвыгын формалаштыра, фикерләү сәләтен үстерә, кызыксыну даирәсен киңәйтә.

Берара матбугатта физиклар белән лириклар арасында бәхәс булып алды. Миңа шул вакытта ук уйлап чыгарылган кебек тоелды ул. Кеше үзен тар кысаларга гына кертә алмый. «Мин – физик, мине башка бернәрсә дә кызыксындырмый». Мондый тарлык өчен тормышның җәзасы каты булачак!

Бу галимнәргә генә кагылмый. Теләсә кайсы һөнәр кызыксыну даирәсенең киңлеген, кайчак мавыгу да таләп итә. Беренче карашка, синең шөгылеңә кагылышлы булмаган кебек тоелса да. Мин әйткәннәр агрономга да, табибка да, токарьга да, тегүчегә дә бердәй тигез кагыла. Әдәбият, сәнгать кешене затлы итә, аның зәвыгын формалаштыра, фикерләү сәләтен үстерә, кызыксыну даирәсен киңәйтә.

Ерак Себернең бер шәһәрендә яшәүче эшче турында бер хикәят ишеткәнем бар. Аның фатиры сынлы сәнгать музееи хәтерләтә икән. Ул бөек рәссамнарның картиналарының репродукцияләрен коллекциягә туплап кына калмый, ә төрле шәһәрләрдә күргәзмәләр дә оештыра. Аның бай коллекциясен Себер шәһәрләрендә яшәүчеләр дә, Мәскәүдә дә, хәтта чит илдә дә сокланып караганнар. Дөресен әйткәндә, андый кешегә ак көнләшү белән карыйм. Ул аягында нык басып тора.

Гүзәллек белән мавыгу – кызыксыну гына түгел. Ул – шәхеснең кабул итү формасы. Кызганыч ки, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында яшь буынны тәрбияләүчеләр һәрвакытта да әдәбиятны һәм сәнгатьне болай аңлап кабул итми. Бу алган белемнәрнең суммасын хәбәр итү генә түгел бит. Иң мөһиме – гүзәллеккә мәхәббәт тәрбияләү, осталарның иҗат җимешләрен аңларга, бәяләргә өйрәтү.

Еракка киткән саен, бу проблема безнең өчен әһәмиятлерәк була бара. Без коммунизм төзибез. Ә югары җәмгыятькә рухи яктан бай шәхесләр кирәк. Алар формулалар ачамы, пәлтә тегәме, күперләр саламы – нәрсә генә эшләсә дә.

Русчадан ***Ландыш Әбүдәрова*** *тәрҗемәсе* ■

«Безгә дә яңача булырга кушалар»

(110 ел элек Яңа ел котлавы)

Ләлә Мортазина

نومرو ۳

موسقوا

برنچی سنه

آبونه بهاسی

ییاروبله‌ن ییلغه ۵ صوم
» یاریم ییلغه ۳ صوم
ییارودن باشقه ییلغه
٤ صوم ٥٠ تین
» یاریم ییلغه
۲ صوم ٥٠ تین

هرنسخه‌سی ۲۵ تین.

اداره‌خانه

موسقوا شهرینده
تسوۋیتنوی بولوۋارده
بابیکف یورطینده.

اداره‌خانه‌ده بیرامدن باشقه هرکوننی
۱۰-۵ گه قدر آچقدر.

تربیهٔ اطفال

(اون‌بیش کونده برچقاطورغان سبق بالالرینه مخصوص ادبی، فنی و رسملی مجله).

۱ فیورال سنه ۱۹۰۷ | پنجشنبه | سنه ۱۳۲۵ محرم ۱

(ایسکی و یاڭا یللر)

«Тәрбияи-әтфаль» журналының тышлыгында «Иске вә Яңа еллар» рәсеме

Безнен мирас №1 гыйнвар 2022

XX гасыр башында, аеруча 1910 нчы еллардан соң, татар балалары өчен төрле бәйрәм чаралары, кичәләр оештыру гадәткә керә башлый. Мәктәпләрдә дини бәйрәмнәргә – Бәраәт кичәсенә, Мәүлид бәйрәменә багышланган кичәләр уздырыла. Мәүлид кичәләрен христианнарның Раштуа чыршысы бәйрәменә охшатып үткәрә башлыйлар. 1913 елда, мәсәлән, Казандагы «Шәрык клубы»нда үткәрелгән шундый кичәдә балалар, чыршы тирәли әйлән-бәйлән әйләнеп, җырлар җырлаганнар, шигырьләр сөйләгәннәр. Соңыннан барысына да бүләкләр өләшенгән.

1915 ел азагында исә татар балалары өчен тантаналы рәвештә Яңа елны каршылау кичәсе уздырыла башлый. Кайбер хәллерәк татарлар мондый бәйрәмне үз өйләрендә үткәргән, бизәлгән чыршы янында уйнап күңел ачарга башка балаларны да чакырганнар. Хәзерге Тукай музее бинасын – «Шамил йорты»н сатып алган сәүдәгәр, татарның конфет короле Вәлиулла Ибраһимов та өендә менә шундый Яңа ел чыршысын оештырган, балаларны үзе җитештергән төрле тәмтомнар белән сыйлаган.

Балалар бу матур, тылсымлы бәйрәмне яратып көтеп алган. Татар газета-журналлары исә, үз чиратында, аларны Яңа ел белән котлап, ихлас теләкләрен белдергән. Милләтнең киләчәге булган балаларга ышаныч та, аларның зыялы, гыйлемле затлар булып җитешәчәгенә, милләтне алга җибәрәчәкләренә өмет тә бар аларда.

Игътибарыгызга «Тәрбияи-әтфаль» журналының 1907 елгы 3 нче санында басылып чыккан Яңа ел белән котлау мәкаләсен тәкъдим итәбез.

Яңа ел мөбарәк булсын!

Милләтебезнең булачак әгъзалары – балалар!

Халкыбыз өстендәге җәһаләт *(караңгылык)* вә мәзлуманә болытларының ахырын күрсәтә башлаган иске ел үтте... Аның урынына үзе белән нәрсә китергәне мәгълүм булмаган Яңа ел килде... Тырышсак вә хәрәкәт итсәк – зыя вә гыйлем; әгәр элеккечә гафләтебездә *(ваемсызлыкта)* торсак – мәзлумият *(рәнҗетелү)* вә наданлык...

Менә бу хәрәкәт вә безгә якты истикъбаль *(киләчәк)* вәгъдә итә торган Яңа ел белән сезне тәбрик итәбез һәм бөтен күңелебез вә җаныбыз белән киләчәктәге мәгыйшәт *(тормыш, яшәеш)* юлында муаффәкыятегезне *(уңыш)* телибез! Фәкать шуны да әйтеп китмәкче булабыз: бу мәгыйшәт юлы сезнең өчен бик җиңел булмас. Сезгә бөтен мөселманнарны гасырлар буена өелеп килгән наданлыктан, очы күренмәгән караңгылыктан, мәгыйшәтнең гадәтсезлегенә булган ачудан һәм төрле-төрле җәфалар диңгезеннән чыгарырга туры киләчәктер. Халыкның күзләре хәзер сезгә юнәлгәннәр! Сездә ул үзенең киләчәктәге коткаручыларын күрә һәм сездән мәгыйшәтнең бозылган вә атылган хакканиятләрен *(чынлык, дөреслек)* яңартуны, халык хафаларының азайтылуын вә һәркемне җәфалардан котылдыруны көтәдер.

«

Сезгә бөтен мөселманнарны гасырлар буена өелеп килгән наданлыктан, очы күренмәгән караңгылыктан, мәгыйшәтнең гадәтсезлегенә булган ачудан һәм төрле-төрле җәфалар диңгезеннән чыгарырга туры киләчәктер.

Сезгә, халыкка бәхет вә сәгадәт юлы ачар өчен, бөтен көчегез белән тырышырга тиеш булачактыр. Һәм халыкны сәгадәткә ирештерер өчен, бик мөһим вә читен мәсьәләләрне хәл итәргә вә, аларны хәл итәр өчен, әллә никадәр нәрсәләр белергә вә әллә никадәр хәзерләнергә кирәк булачактыр. Гыйлем вә фәнсез һичбер адәм гаммәгә *(халыкка)* эш эшли вә файда китерә алмыйдыр, мәгыйшәттән чыккан иң мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә көче җитми гаҗиз калалар.

Фәкать фән генә кешеләргә үзләренең хәятенең серләрен ача ала, фәкать ул гына дөньяны баета, ислах итә вә сәгадәткә ирештерә аладыр. Фәкать зыялы вә галим кеше генә эш итәргә вә мәгыйшәт сугышларына кадирдер *(сәләтле)*. Менә, балалар, шулай акрынлап көннәр, айлар, еллар үтеп, безне очы күренми торган истикъбальгә *(киләчәккә)* илтәләр үткәннәрдән. Әгәр алардан истифадә итеп *(кулланып)*, гыйлем арттырып, нурланып калмаган булсак, һич әсәр дә калмый вә без ул вакытларда булмаган вә ул вакытларны үткәрмәгән дә булабыз.

«

Үз көчләреннән, үз милекләреннән файдалана белмәгән кешеләрнең дә милекләреннән вә көчләреннән, вә хәтта үзләреннән дә файдаланалар.

Заман яңара, халкы яңара, безгә дә яңача булырга кушалар...

Гакыллы адәмнәр бер минутларын да уздырмыйча, алга таба бара вә табигатьтәге бар нәрсәләрне үзләренә хезмәт иттермәкче булалар һәм иттерәләр. Үз көчләреннән, үз милекләреннән файдалана белмәгән кешеләрнең дә милекләреннән вә көчләреннән, вә хәтта үзләреннән дә файдаланалар.

Шуңар күрә халык арасында гыйлем вә мәгариф орлыклары чәчәр өчен өйрәнегез, укыгыз, зыяланыгыз, булачак милләт әгъзалары!

Исегездән чыгармагыз шуны: халкы никадәр белемлерәк булса, шулкадәр үзенең иҗтыяҗларын яхшырак аңлый һәм хөр вә зыялы мәгыйшәтнең рухы булган нәрсәләрне вөҗүдкә чыгара *(барлыкка китерә)* аладыр.

Яңа ел, яңа көннәр... Без аларны тәхсыйль *(уку)* һәм гыйлемгә ашкыну белән каршы алыйк! Вә бу көннән башлап яңа гайрәт вә яңа иҗтиһад белән укырга вә зыялыланырга тырышыйк! ■

«Кызлар арасында күмелеп утырдым»

Мирхәйдәр Фәйзи

Казан күренеше. XX гасыр башы

1923 ел, октябрь

1сендә трамвай белән Бишбалтага бардым. Фатир юк, диләр. Казанда калуны чамалап нумерлар, фатирлар караштырып йөрдем. Кайтсам, өй тулы кызлар. Наҗия, Разыя, Фатыйма, Шәфига, Җөвәирә, Рәйсә туташлар гөр килеп утыралар. Бик күңелле булды. Казан кызлары арасында күмелеп утырдым. Бик гади генә булсам да, каләмем аркасында, урынны саклыйм. Яраткан кебек күренәләр. Яратмасалар тагы, аның ни үкенече бар? Шулай да Разыя белән Фатыйма туташны өйләренә кадәр озатып куйдым бит. Тәки шулай итми булдыра алмадым! Ай, акылсыз кызлар, акылсыз кызлар!

5есендә җәяүләп Пороховойга бардым. Татар клубына барып, аның завын сорадым. Клуб тыштан бик сөйкемле. Бакча эчендә уютный гына йорт. Ишек бакчага чыга. Бик күңелле. Үземнең шунда торып кала алмавыма зур үкенеч хасил булды. Җаңгыр шыбырдавы астында моңланып, үкенеп, эшчеләрне хөрмәтләп җырлап тордым. Шул ук җирдә, фатир тапмый кайтып китүем мөнәсәбәте белән, эшчеләргә төбәп җыр-шигырь яздым. Моңлы, кадерле бер

момент булды. Эшчеләр йөргән җирләрдә, аларның клубында ниндидер бер рәхәтлек сизеп, бәхетле булып тордым.

Көтепханә назыйрәсе *(мөдире)* килеп ачкач, эчкә кердем. Урынына мине куеп, чыгарылачак бу яшь һәм ачык кына кызны кызганып куйдым. Ул әле бернәрсә белми. Эшне ачып биргәч каушады. «Хезмәт итәм дип укырга да кермәгән идем», – ди. Турыдан-туры: «Кайгырма, туган, синең урыныңны алудан ваз кичтем», – дип игълан иттем. Шул сүзне әйтеп, аны куандыру җанымны рәхәтләндерде. Үзем дә бер нык карарга килеп, тынычлап калдым. Көтепханәнең заведующие Һибәтуллина туташ та килде. Ул үземне чыгаралар дип куркып йөри икән. Хәтта Союзга жалоба да бирмәкче булган. Икесен дә тынычландырып, дусландым. Килгәләп йөрергә вәгъдә бирдем. Озатып калдылар.

Анысы шулай булды. Әмма көтепханәнең матурлыгы, клуб бүлмәләренең яңа гына матурлап буялган күңелле, мәһабәт булуы хәсрәтләндерде. Эчен-тышын яратып-сөеп, рәхәтләнеп эшләячәк бер урынны ычкындыру белән аһ итеп чыктым.

Казельскийга кереп отказ бирдем. Хәзергә Пороховой сәяхәтен шулай тәмамладым. Күңелем белән иркәләп, тагы килеп йөрүләрне теләп киттем.

Атлар җиктем яратып,
Пороховойга каратып;
Фатир тапмый кайтып киттем,
Килгән идем яратып.

Трамвайга җиткәнче яхшы ук кына күшектем. Трамвайга утыргач рәхәт булды.

13ендә «Мәркәз Шәрык көтепханәсе» янындагы мәркәз балалар көтепханәсе «Тукай»ның назыйры булып эшли башладым. Көтепханә матур, рухлы. Балалар белән дә килешермен дип уйлыйм. Хәерле, дәвамлы эш булсын!

Октябрь бәйрәме мөнәсәбәте белән, бер балалар кичәсе ясауга тәклиф булды. Яңа кереп, десятический системага куелган көтепханә эшләренә төшенеп тә өлгермәс, балалар белән һич танышмас борын, бу миңа җайлы түгел инде. Фатир юк, биржадан үтелмәгән, союзга кермәгән, рух төшенке. Шулай булгач, ул кичә өчен күңел нинди генә иҗатлар бирә алсын?!

Балаларның җыелышын ясадык. 27 бала булды.

16сында. Көтепханәдә көн дә репетиция ясыйбыз. Казан балалары арасында кайныйм. Исемнәрен, үзләрен белеп, дуслашып барам. Бик күңелле балалар бар.

Суфия туташ белән Главполитпросветка бардык. Семеновлар белән сөйләшеп, көтепханәгә күчеп торырга булдым. Бер кечкенә караңгы бүлмә бар. Шунда нәрсәләремне куеп, яту-торуга гарәбиләр бүлмәсенә чыгарга, ашап-эчүне ыстража бүлмәсендә эшләргә булдык. Болай булганда, фатир, утын, яктыртулар белән файда итәм була инде.

Көтепханәгә күчеп бардым. Рәхәтләнеп, тынычлап калдым. Ыстража ашлар, чәйләр хәзерләп бирергә булды. Көтепханәдә эшләүче 7 кыз арасында мин берүзем.

Кич Зәйнәп туташ Рәхимова (Гали Рәхимнең сеңлесе) белән озак сөйләшеп утырдым. Яхшылап таныштык. Ул биредә дүртьеллык эшче икән. Белемле,

акыллы, тәрбияле кыз. Бер мөхәррирнең сеңлесе булгач, күңелемә якын ук тоелып китте.

18ендә базардан ит, бәрәңге, тоз, борай ярмасы, оннар алдым. Чынлап рәхәт үк булып калды. Көтепханәнең зур-зур, матур-матур бүлмәләрендә үз өем кебек берүзем йөрим. Утырып эшләргә аулак, тыныч. Ятып йокларга йомшак диван бар. Шулай итеп, сау булынса, ким-хур булынмас әле. Көтепханәдән төшүгә, бик шәпләп аш ашадык.

19ында. Менә инде бүген минем туган көнем. 33кә аяк баса малаең. Котлы булсын туган көнем! Киләсе елгысына сау керим!

Репетиция яхшы бара. Балалар бик ихлас йөриләр.

Кадагын 175 миллионга бал алдым. Бүген 3 чәй, бер аш эләкте. Тормыш азрак рәткә төште, шөкер!

20сендә. Мәркәз көтепханә зур гына бинаны ишгаль итә *(алып тора)*. Аста һәм өстә 10 бүлмә били. Һәр җир таза, тәртипле, матур. Минем көтепханәм югары катта. Көтепханә эшчеләренең җыелышы булды. Октябрь бәйрәме көнендә выставкага кую өчен һәркемгә бер сәяси китап укып килергә бирелгән иде. Һәркем шул хакта доклад бирде. Мин «Мәгариф эшләре һәм совет хакимияте» дигән китап хакында фикеремне сөйләдем. Район көтепханәләренең дә эшчеләреннән күбесе кызлар икән. Дүрт кенә ир кеше булдык. Һәркайсы эшкә күңел куйган, тырыш кына кешеләр кебек күренде.

Көтепханә салкын. Шунысы гына кәефсезләп тора. Суык алдырып авырып китә күрмим!

25ендә Октябрь бәйрәме. Парадка бардым. Шәп булды. Ифрат матур плакатлар; аларны күтәреп артына ияргән эшче, крестьян, совраб, укытучы, укучы, гаскәри, пожарный, инвалид, рәксәм, рәкиб, кавалерия, туплар, пулеметлар, автомобиль, әллә нәрсәләр... Алары тыр-пыр итеп, дөбердәп, шатырдап үтә. Музыка өзлексез уйный. Өстән аэропланнар әйләнеп оча да оча; халык өстенә кәгазьләр чәчә. Галәмәт...

Кич, ашка кадәр, дип, Большой Проломныйга чыккан идем. Кызыл абажурлы лампалар, лампочкалар белән бөтенләй кызылга коенган урамнан төрле лозунгаларны, портретларны, бәйрәм кызыкларын карап барганда университет студенты Шаһимәрдәнов очрап, Татар дәүләт театрына билет тәкъдим итте. Барып булмас дип торганда гына Исмәгыйль Нигъмәтуллин белән Уфада башвоенком Терегуловның личный секретаре, былтыргы матур күзлеме, сүзлеме җегет – Жданов килеп чыктылар. Алар бара торган булгач, мин дә Шаһимәрдәновның билетын алып, бергәләп театрга бардык. Гел эшчеләр, түбән сыйныфлар тулган театрда. Рәхәтләнеп йөрдем, яшь рабочийлар белән сөйләштем. Уфадан килгән артистка Зөләйха Богданованы күреп сораштым. Һади Такташ белән, Байкиев белән күрештем. Сәхнәгә «Сакла, шартламасын!» куелды. Күңелле булды. Ждановлар белән бергә утырдык. Разый булып кайттым.

27сендә. Иртә белән балаларның генеральный репетициясен ясадым. Кечкенә генә сәхнә җирләштерелде. Заллар матур, карап торырлык итеп бизәүле, күңелле. Балалар бик ихлас, җимертеп йөриләр.

Сәгать 3тә башланачак иде. Балалар бөтенләй һөҗүм итте. 250 бала, 50ләп өлкән кеше белән зал тулды. РКСМнан бер докладчик алдык. Азанова фамилияле бу яшь кыз балалар теле белән бик матур доклад укыды. Аннан «Интернационал» белән концерт башланды. Номерлар матур үтәлде. Ничә көннәр тырышуымның хәерле нәтиҗәсен күреп куандым. Номерлар беткәч, сәхнәгә чыгып, беркадәр сөйләп, рәсми кыйсемне яптым. Аннан волшебный фонарь белән рәсемнәр күрсәтелде. Һәм төрле кызыклы уеннар уйнатылды. Рәхәтләнеп уйнадылар. Боларны Суфия, Мөслимә һәм Зәйнәп Таһировалар үзләре дә уйнап үтәделәр. Казан балалары арасында «Хәйдәр абый» булып бергә чуалуны зур бәхет санадым. Килеп кергән уңайга башыма чүккән бу кичә муаффәкыятьле булып, күңелләндереп узды.

30ында. Җәяүләп 7 чакрымдагы Фермага киттем. Крестовников заводына кадәр трамвай белән бардым да, аннан, пычракка бата-бата, әйдә, җәяү! Воскресенский дигән бер авылны үттем. Даланы, авылның басуларын, көлтәле эскертләрен күреп рухан бәйрәм иттем. Күптән аерылган кебек күземне тутырып-тутырып карадым; авызымны тутырып-тутырып һава иснәдем. Матур, көз белән моңланган урманнар кичеп, тагы бер авылның эченнән үтеп, «Ферма»га җиттем. Юлда бер кадак алма, бер кадак сушки ашап беттем.

«Ферма» матур җирдә. Миңа аның көзге күренеше дә әллә ниндәй күренде. Матур, агачлы юллар, һәйбәт йортлар бар. Нәсимә апайлар әллә ничә бүлмәле таш йортта торалар икән. Күрешеп, куанып калдым. Гобәйдулла әфәнде дә өйдә. Ачык каршыладылар. Аш ашадык. Чәй эчкәндә Мидхәт белән Тәүфикъ килделәр. Алар, мин, Зыя – дүртәүләп аларның укый торган җиренә, сельскохозяйственный техникумга бардык. Күңелем каршында иң кадерле булган уку йорты – сельхозтехникумның залларын, клубларын, көтепханәләрен, укучыларын бик яратып, якын күреп карап йөрдем. Былтыр Уфада танышкан Фуат Кулиев белән күрештем. Тәүфикъның караватында Буби, Әгерҗе малайлары белән бергәләп ботка ашадым. Бергә күңелле итеп утырдык.

1923 ел, ноябрь

8ендә. Матбугатка беренче кергән язуым 1907 елда «Хөсәения» мөгаллимләрен тәнкыйть итеп басылган иде. Имзаны «Мазгум» дип куйган хатым «Чүкеч»нең 37 нче санында урын алган иде. Шулай итеп, бу ел язуымның матбугатта чыга башлавына 16 ел тула. Без картаймый кем картайсын. Юк, картаймам әле. Чәчем агарса да, күңелем, рухым картаймас, ул эш миннән булмас.

13ендә. Бүген гарәп бүлмәсен ышкафлар белән бүлеп, пич ягыннан үземә бер бүлмә ясап алдым. Кечкенә генә, үземә охшаган гына бер спальный хасил булды. Мин шуңа риза инде. Һәрхәлдә, торыш уңайсыз диярлек түгел. Бер иркен, аулак бүлмә юк икән, аның урынына әллә никадәр башка уңайлыклары бар.

16сында кич «Урал суы буенда»ның репетициясенә бардым. Ару чыга икән, уйнавын уйнала, тетәрләр инде мине. Идеология, фәлән-фәсмәтән дигән булырлар.

17сендә. Кич спектакльгә бардым. Халык полный. Хәким Сәлимҗанов белән йөрдем. Гали Рәхимне күрдем. Сәхнәдә үтте күбрәк вакытым. Әхмәдемнең киемен җентекләп карап тәкъдим иттем. Маладис, матур җегет булган.

Уен шома гына барды. Уфадагыдан матур җирләре күбрәк булды. Күпчелек яратты. Әдипләр, әлбәттә, яратмаганнардыр. Җитмәсә, һәммәсе дә килгән. Фатих Сәйфи, Рәмзи, Такташ, Гали Рәхим, Шамил Усманов…

Менә ки язу рәвешемне тәнкыйть итсәләр иде алар. Каләмемдә матурлык, сүзләремдә җиңеллек, картиналарымда нәфислек, төзүемдә муаффәкыять бармы?

Соңынтын автор дип күп кенә кычкырдылар. Галиәсгар Камал исемле бер исерек мөхәррир нык бәйләнде. «Синең белән танышуыма тәәссеф итәм *(үкенәм)*», – ди. Бер дә кайгырма, туган, якыныңа да юлламам. Җилкә чокырымны күрми тордым, Галиәсгар Камалны да күрми тора алырмын әле. «Өйләнәм, ник өйләндем?», «Көндәш»ләреңне укып һәм тамаша итеп бәйрәмлә. Шәп бит алар! Аларны да «Банкрот», «Бәхетсез җегет»ләрне язган каләм язган бит!

1923 ел, декабрь

6сында. Минем таза гына тормышым кызык кына әле. Матди як белән яхшы, мәгънәви як белән ярыйсы, әлбәттә. Ләкин авылда торгандагы бәхетлелекләрем кайда инде алар? Шәһәрне авыл дәрәҗәсендә яратуым мәңге-мәңге мөмкин түгел! Казанда да, Уфадагы кебек бер дуссыз, бер якын иптәшсез яшим. Ялгыз мин, ялганырлык кешем юк. Һәммәсен күңелем чит күрә, җен күрә.

Эштәшләрем булган мөхәррир, шагыйрь һәм драматургларның берсе дә күңелем тартып, араларында буласымны китереп тормый. Эшче, игенче, укучы яшьләр, комсомолецлар, яшь дворник, кучер, фәләннәр; наборщиклар, шахтерлар, зимагурларның һәммәсен күңелем түрендә саклап, дусланырга, араларына керергә юллар эзләгән хәлдә, мөхәррир, артист дигән халык арасында ямь таба алмый интегәм.

9ында. Рифгать Таһиров белән көтепханә-кыйраәтханәләр төзүгә кулланма язабыз. Ул материал бирә, мин язам. Ләкин миңа авыргарак килә.

Казан һавасы, эшләүләр йөрәгемә җайсызлый. Язны үткәрә алсам, Казанда яхуд нинди дә булса да шәһәрдә торырга ярамый, ахры, инде миңа. Саулыкны сакларга тырышырга кирәк. Ләкин Казаннан башка матди якны нишләтергә соң?

25ендә. Көтепханәнең ябыклыгына айдан артык булу өстенә, үз торган бүлмәбезне үзебез җылытудан да гаҗиз калып, бер атна инде суыкта яшибез. Жалуния алып булмый, алачаклар да бирелми. Ашау да ачлы-туклырак. Кыен бит, җегетләр! Саулыгымны тагы бозыбрак алмасам ярар инде. Казан! Монысы ярамый!

Наркомпроска бардым. Акадцентр «Ярдәмгә мохтаҗ авыру драматург», дип, наркомсобеска язу бирде.

Наркомпроста дүрт төрле алачагым бар, берсен дә бирә алмый торалар. Тәмам акчам беткәнлектән гаҗиз калып, Хәдичә ханымнан барып акча алып тордым. Бар өстеннән хәерчеләнәсең бит. Авылда мин бу көнне күрмәдем, яшәсен авыл!

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

КОТОЧКЫЧ АЧЛЫК

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКТАН ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

Ачлыкка каршы көрәштә яңа юллар

Исхак Казаков

Исхак Мостафа улы Казаков (1876-1939) – ТАССРда ачларга ярдәм итү комиссиясе рәисе. Танылган сәясәтче һәм әдип татар халкын, татарстанлыларны 1921-1922 нче елгы ачлыктан коткару буенча зур эшләр башкара, реаль тәкъдимнәр кертә һәм аларны гамәлгә ашыра. Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган мәкаләдә сүз шул хакта бара. Материал «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1921 елгы 30 декабрь санынннан алынды.

**«Ун тук!
Көн саен өч фунт он биреп, сез бер сабанчыны ач үлүеннән коткарып калырсыз, әмма үзегезне дә киләчәктә шул ук аяныч хәлдән котылдырырсыз».
Медведев һәм Сперанскийның литографик плакаты.**

Ачларга ярдәм мәркәз комиссиясе алдында хәзерге көндә бөтен көчне җыеп ачлыкны җиңү, ач халыкны, бигрәк тә балаларны үлемнән коткарып калу вазыйфалары тора. Ләкин бу әсаси *(төп)* вазыйфага төрле яктан, төрле юллар белән якынлашырга кирәк.

Ярдәмнең формалары үзе дә бик төрлечә була. Иң башлап, билгеле инде, хөкүмәт тарафыннан ителә торган ярдәм тора, аннан соң азык, орлык материаллары, һәртөрле нәрсәләр, повестка кәгазьләре һәм кружкалар буенча акчалар җыю юллары белән хосусый кешеләрнең ярдәм итүләре, төрле спектакльләр, күңел ачу уеннары ясау, акчалата ярдәм итү һәм башкалар. Татарстанда ачлык дәһшәтләре беренче сизелгән чакларда, ачлык белән көрәшне шул югарыда күрсәтелгән рәвештә алып барырга, ачлыктан зарарланган кешегә хөкүмәт һәм хосусый кешеләрнең ярдәме рәвешендә эшләргә кирәк дип уйлана һәм шул юлда эш йөртелә дә иде.

Хәзер инде ачлык үзенең дәһшәтен арттырып, гомуми халык бәласе рәвешенә кергәч, хөкүмәтнең бөтен ачларны туйдырып тора алмаганлыгы, аерым кешеләрнең һиммәтләре *(тырышлыклары)* белән дә бер дә эш чыгарып булмаганлыгы ачык мәгълүм булды.

Ачлык гаять зур. Аның зурлыгын ачыграк күрсәтү өчен, ач зур кешеләрнең саннарын куеп торып, монда ач балаларның саннарын күрсәтеп китүне тиеш табабыз.

Соңгы көннәрдә Татарстанга яңа кушылган Буа һәм Алабуга кантоннарын кушкан чакта, балаларның саны мондый була: 1 декабрьгә 12 кантонда – 1 238 203 бала, Казан шәһәрендә – 66 017 бала, барысы бөтен Татарстанда 1 304 225 бала бар.

Кантоннардан 7806 бала Казанга күчерелгән. 1755 бала ялгыз рәвештә Казанга килгәннәр. Кантоннардан Татарстаннан читкә 790 бала күчерелеп, Казанның үзеннән күчерелгән 4856 баланы чигергән чакта да, беренче декабрьгә 70 722 бала бар.

Татарстанда 16 яшькә кадәр булган балалар барысы 1 289 819. Шулардан 20 800 бала бөтенләй хөкүмәт тәрбиясендә, 67 341 бала Ачларга ярдәм комиссиясе тәрбиясендә, 139 600 Рус-америка ярдәм комиссиясе тәрбиясендә торалар.

Бөтен балалар саны булган 1 289 819дан туенып тора торган 277 141 баланы, яртылаш туена торган 168 411 баланы чигерсәк (барысы 445 552 була), 844 267 бала бөтенләй ярдәмсез калалар. Димәк, без хәзерге көнгә кадәр Татар җөмһүриятендә яңадан сигез йөз мең балага ярдәм итү нәрсәләре табылмаганлыктан, ярдәм итә алмыйбыз әле. Хәзерге көнгә кадәр ашлык уңмаудан иң нык җәфа чигүчеләргә генә ярдәм ителеп килде. Декабрь ае җитте, гыйнвар килеп җитте. Кантоннарда хәзерге көнгә кадәр үзе генә ачлыкка каршы көрәшеп килгән крестьяннар да электән үк ач булып, хөкүмәтнең ярдәменә

«Халык соң чиктә ач булганлыктан, алар арасында төрле йогышлы авырулар көннән-көн көчәя. Тимгелле, брюшной һәм кайтма тифлар көннән-көн тамыр җәя, үлүчеләрнең хисабы хәзергә кадәр һич җирдә күрелмәгән микъдарга җитә.

мохтаҗ һәм ашлык уңмаудан нык җәфа күрүчеләр белән бер дәрәҗәгә килеп төштеләр.

Кантоннарда ач халыкның хәле гадәттән тыш куркыныч. Халык соң чиктә ач булганлыктан, алар арасында төрле йогышлы авырулар көннән-көн көчәя. Тимгелле, брюшной һәм кайтма тифлар көннән-көн тамыр җәя, үлүчеләрнең хисабы хәзергә кадәр һич җирдә күрелмәгән микъдарга җитә. Балаларның исә тагын да куркынычрак төс алып бара. Бу куркынычлы хәлдән котылу өчен, Советлар хакимиятенең яисә чит мәмләкәтләрнең ярдәме генә җитми. Бу куркыныч, күңелсез хәлгә каршы көрәшүдә Татар җөмһүриятенең һәм шулай ук Русия Федерациясенең бөтен хезмәт халкы чын күңел, зур энергия белән катышса гына, шуңа иштирак итсә генә, без бу куркыныч хәлдән котыла алачакбыз.

Хәзер без, әлбәттә, һәм һич кичектермичә, ачлыкка каршы көрәштә хәзергә кадәр кулланып килгән ысулларыбызны беркадәр башкартырга, ярдәм итү эшен яңа юлга куярга һәм яңа ысуллар белән хәрәкәт итәргә тиешлебез.

Татарстан мәркәз башкармасы хозурында Ачларга ярдәм итү мәркәз комитеты соңгы көннәрдә бу юлда кирәкле булган бөтен чараларга кереште.

Татарстан ачлыкка каршы көрәшүдә хөкүмәт ресурсларын арттыруны сорап мәркәзгә үтенеч җибәрде һәм чит мәмләкәт оешмаларының ачларга ярдәм итү эшләрен киңәйтүдә, зурайту юлында бик зур булышлыклар күрсәтә, Татарстанга ярдәм итәргә тиешле Петроград һәм Владимир губерналары белән бик нык мөнәсәбәт урнаштырды. Шулай ук кантоннарда шәрык аяк киемнәрен һәм баш киемнәре хәзерли торган төрле кустарный эшләрне оештырды. Төркестан, Себер белән кооперацияләр артеле мал алмашу эшенә кереште. Шуның белән бергә, Татарстан мәркәз башкармасы хозурында Ачларга ярдәм итү комиссиясе ачларга ярдәм итү эшләрен хезмәт халкы һәм гомуми гражданнар арасында оештырырга да бик нык әһәмият биреп һәм моннан да эшкә шактый зур файда килүгә ышана. Шуның белән бергә комиссия Совет органнарының ачларга ярдәм итү эшләрен көчәйтүгә дә бик нык әһәмият бирде.

Безнең бәгъзе бер халык комиссариатларыбыз һәм аларның урыннардагы органнары ачлыкка каршы көрәшүдә бик аз эш күрсәтәләр һәм бөтен урыннарда эш тиешенчә алып барылмый.

Менә шул күңелсез хәлләргә игътибар итеп, Татарстан мәркәз башкармасы, Ачларга ярдәм итү комиссиясе махсус положение эшләп чыгарды. Бу положение буенча һәрбер тәэмин ителгән гаилә, һәрбер учреждение, һәрбер фабрика, Кызыл Армия бүлекләре, кооперативный оешмалар һәм башка гомуми оешмалар, положение буенча билгеләнгән паек белән тиешле микъдар ачларны һәркөн туйдырып торырга тиешле булалар.

Һәрбер тук кеше бер ач кешене туйдыру өчен кирәк нәрсәләрне даими рәвештә биреп торырга тиеш. Хезмәт итәргә көче булган һәрбер гражданин һәр айда 3 кадак икмәк яисә 3 кадак икмәк бәһасен акчалата ачларга бирергә тиеш.

Шулай ук балаларга ярдәм итү эшләре дә, алар өчен гомуми ятакханәләр хәзерләү ысулы һәм ачларга ярдәм итү эшләренә керешли налоглар һәм башкалар гамәлгә куелгач, көчәячәк.

Ачларга ярдәм мәркәз комитетының билгеләнгән планнарын җиренә җиткерү өчен, безнең кантоннар белән галяка *(бәйләнеш)* аппаратларның һәммәсен мобилизовать итәргә кирәк. Ул эшләрдән киң һәм мөкәммәл

Ачлык елларында иҗат ителгән плакат

рәвештә белдереп торырга, аларны урыннарда иҗтиһад белән эшкә кузгатырга кирәк. Ирекле рәвештә азык белән ярдәм итү, хәзерге көндә булган бөтен көчләрен турыдан-туры җәмәгать туйдыруларына оештыру өчен, киң рәвештә агитацияләр ясарга кирәк. Бу мөһим эшләрнең һәммәсен дә безнең партия органнарының, яшьләр союзының, хатыннар шөгъбәләренең *(бүлекләренең)*, урыннардагы кантон комитетларының һәм башкаларның катышулары кирәк. Бу эшкә безнең матбугатыбыз да катышырга тиеш. Ул матбугат бу көннән бу тәдбирләрне халыкка киң рәвештә белдерә торырга һәм ул эшләрнең барышларын яктырта барырга, көннән-көн шул ук дәрәҗәдә фабкомнар, завкомнар, Кызыл Армия кыйсемнәрен, кооперацияләр, ширкәтләр һәм башка җәмәгать мөәссәсәләрен *(оешмаларын)*, шулай ук сәүдә һәм сәнәгать эшләре белән мәшгуль булучыларны, ягъни фабрика, завод, магазин, кәсеп һәм башка мөәссәсәләрнең хуҗаларын, ирекле кәсептә булган кешеләрне, фән ияләрен, табибларны, әдипләрне, артистларны, рәссамнарны һәм башка хәзергә кадәр бу эшкә катыштырылмаган кешеләрне хәбәрдар итә барырга һәм тәрбиягә никадәр кешеләр алынганлыкны белдерә барырга кирәк.

Менә без үзебезнең организовать ителгән хәрәкәтләребез белән ачлыкны киметүгә һәм, бәхетсез бичара халыкларны үлемнән коткару өчен, һич тайпылмыйча барырга тиеш булган яңа юл шул.

Эшчеләр һәм аларның оешмалары һәрвакыттагы шикелле алда барырга тиешлеләр. Алар үзләренең ярдәмнәре белән башкаларга барысына да мисал булырга тиешлеләр.

Иптәшләр, Автономияле Татар Социалистик Совет Җөмһүриятенең эшчеләре һәм эшче хатыннары, хәзер сүз һәм эш нәүбәте сездә кала!

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

«Кайт, и нәфсе мотмәиннәм!»

(Габдулла Тукайның Мәфтуха Галиева кабер ташына язылган шигыре)

....

Наил Таиров, Илһам Таиров

Сембер губернасына (хәзерге Ульяновск өлкәсе) кергән торак пунктлардагы татар-мөселман зиратларын барлаган, өйрәнгән чакта без еш кына кызыклы һәм тарихи-мәдәни әһәмияткә ия табышларга тарый килдек. Алар арасында үз эшенең чын осталары тарафыннан башкарылган кабер ташлары да бар. Болар, нигездә, инкыйлабка (1917 елга) кадәрге чорга карый.

Ульяновск өлкәсенең Барыш районына кергән Зөябаш (Иске Тимәш) авылының ике зираты – без җентекләп тикшергән объектлардан. Биредә, нигездә, шушы авыл халкы җирләнгән. Әмма илнең башка төбәкләрендә туып-үсеп, аннары фабрикант Акчуриннар хуҗалыгында хезмәт куеп, соңгы сыенып урынын шушында тапкан затлар да бихисап. Гомумән, әлеге җир-туфрак татар дөньясының бик күп атаклы нәселләре вәкилләрен сыендырган: Акчуриннар үзләре, Дебердеевлар, Мангушевлар... Бу һәм аңа якын темаларга багышланган кайбер язмаларыбыз фәнни һәм фәнни-популяр басмаларда моңарчы да дөнья күрде [1].

Шушы зираттагы бер кабер игътибарыбызны аеруча җәлеп итте. Текст аша (җөмләдән, мәкалә авторларына аны Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе мөгаллимнәре А.Мингалиев, Х.Койрыков, И.Ситдыйков, И.Җиһаншин укышты) гүр иясенең тормышы-булмышы турында кайбер мәгълүматлар ачыкланды: исеме – Мәфтуха Галиева; Сарытау губернасының Кузнецк өязендәге татар авылларының берсендә туган (хәзер бу тарафлар Пенза өлкәсенә карый); әмма гомерен Сембер губернасының Зөябаш авылы белән бәйләгән; җирле татар мәктәбендә балалар укыткан; 1915 елның 19 августында (һиҗри исәп буенча 1333 елның 21 шәүвәлендә) 23 яшьтә бакыйлыкка күчкән [2].

Күренгәнчә, кабер ташы империянең иң катлаулы, авыр тарихи чорында – Беренче бөтендөнья сугышы (1914-1918) дөрләгән заманда куелган. Карап торышка бик тыйнак-гади үзе. Бу аңлашыла да: таш куйдыру һәрвакыт зур чыгымнар сораган. Акчуриннар каберенә урнаштырылган сыңарларыннан кайтышрак булса да, мөгаллимәнең укучылары, якыннары, таныш-белешләре барыбер хәлдән килгәнчә тырышканнар. Зиратларда буш (ягъни ташсыз) каберләрнең шактый икәнлеген игътибарга алсаң, аларга «мәрхәбә!» диюдән башка сүз әйтү мөмкин дә түгел. «Ил төкерсә, күл булыр», – диләр. Ихтимал, бу эш тә – күмәк тырышлык, уртак максатка ирешү теләгенең күркәм нәтиҗәседер. Мондый изге эштән, бәлки, җирле эшмәкәрләр, меценатлар да читтә калмагандыр: Акчуриннар, Мозаффаровлар, Мангышевлар, Шәфиевләр, Габдерәзаковлар...

Әмма тагын бернәрсә бу ташның кыйммәтен бермә-бер арттыра. Эш шунда ки – аңарга бөек Габдулла Тукайның шигъри сүзләре уелган:

«Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! Бар, юнәл, кит Тәңреңә;
Бирдең арканңны моңарчы, инде бир бит әмренә!»

Мөгаен, бөтен Ульяновск өлкәсендә мондый кабер ташы башка юктыр. Бу хәл, һичшиксез, бөек шагыйрьнең һәм аның бибәһа иҗатының монда, Казаннан ничә чакрым ераклыкта да, гаять популяр булуын, йөзләрчә йөрәкләрдә кайтаваз сыман яңгырап торуын күрсәтә.

Кара кайгыда килеш: «Сөекле мөгаллимәбезнең кабер ташына ни язарга икән?» – дигән сораугa, безнеңчә, Мәфтуханың укучылары, авылдашлары тарафыннан гаять дөрес җавап табылган. Җан сыкравын тулырак чагылдырыр өчен, алар асыл шигъриятькә, аның да энҗегә тиң үрнәгенә мөрәҗәгать иткәннәр, меңьеллык әдәбиятны барлаганнан соң, бөек замандашларының иҗатында күңел юатырлык сүзләр тапканнар. Алар, мөгаен, Габдулла Тукайның да яшьли, дөньяның тәмен тоеп бетермичә, артык иртә китүен уйлаганнардыр. Ирексездән, икесенең язмышын чагыштырып караганнардыр. Шигырь юлларын сайлауга анысы да тәэсир итмәдеме икән әле?!

Шунысын да әйтергә кирәк: Мәфтуха Галиеваның кабер ташына төшерелгән юллар Тукайның «Васыятем» шигыреннән. Ул 1909 елда Казанда язылган, беренче тапкыр «Әлислах» газетасының 1909 елгы 10 февраль (№60) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган [3].

Һәрбер татар кешесе өчен кадерле-якын, таныш бу сүзләр шагыйрьнең үзен җирләгәндә тасмаларга язылa, «Тәбарәк» сүрәсеннән соң, Касыйм хәзрәт тарафыннан гүр өстендә укыла… Казанның Татар зиратында… 1913 елның 15 апрелендә… [4].

Сембер губернасының ерак авылында укучыларның Габдулла Тукай шәхесеннән һәм иҗатыннан хәбәрдар булуы безгә гаять кызыклы күренеш кебек тоела. Мәктәп-мәдрәсәдә сабак биргән мөгаллим-мөгаллимәләр, билгеле, ул чакта да олуг шагыйрьне уратып уза алмаганнардыр. Шул исәптән Мәфтуха да шагыйрьнең авыр тормышы, бөек иҗаты турында мәктәптә еш бәян итеп килгәндер.

Аннан тыш, өлкәнрәк яшьтәге шәкертләр Тукайның бу якларга килүен, Хәсән Акчурин чакыруы буенча Гурьевка утарында кунак булуын яхшы хәтерләгәннәрдер, әлеге вакыйга телдән-телгә күчеп сөйләнелгәндер. Ихтимал, аларның кайберсе шагыйрьнең үзен дә күреп калгандыр әле!

Тукайның бу сәфәре турында киң җәмәгатьчелек узган гасырның сиксәненче елларында, күренекле драматург Туфан Миңнуллин әсәре буенча Галиәсгар Камал театрында куелган «Без китәбез, сез каласыз» спектакле аша белде. Шагыйрь образын кабатланмас, гаҗәеп артист Илдус Әхмәтҗанов гәүдәләндерде.

Без телгә алган һәммә данлыклы затлар, иганәчеләр һәм дин әһелләренең кабер ташлары белән бергә, киләчәктә Мәфтуха Галиеваның ташы да төзекләндерелер, матурландырылыр, алар барысы да Ульяновск өлкәсендәге Барыш районының күренекле ядкярләренә әверелер дип ышанасы килә.

Әдәбият исемлеге:

1. Таиров Н.И. Эпиграфические памятники Акчуриных на Старотимошкинском кладбище Ульяновской области // Вестник КазГУКИ. – №3, 2017 г. – С.19-22.
2. Мәфтуха Галиеваның кабер ташы.
3. Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда. II т. – Казан. – 1985. – Б.6, 341.
4. Габдулла Тукай: тормыш һәм иҗат елъязмасы. – Казан. – 2003. – Б.254-255. ■

Авыл малае. Ил башы. Ил агасы

Булачак Президент Минтимер Шәймиев әти-әнисе һәм якын туганнары белән: арткы рәттә сулдан – апасы Мәрзия, сеңлесе Мәдәния, Минтимер, Гөлсем апа (Мәрзиянең каенанасы), Дөргалия (Илшат Фәрдиевнең әнисе), әтисе Шәрип ага, әнисе Нәгыймә апа, Зөлфирә, Альбина, Әлфия. 1955 ел

М.Ш.ШӘЙМИЕВ,
Татарстанның Беренче Президенты, ТРның Дәүләт Киңәшчесе:

«Мин үзем, гомумән, җылы яратам. Безнең өйдә нәкъ Гегельчә – каршылыклар бердәмлеге: миңа – җылы, хатыныма салкынча кирәк. Кайтып керү белән бөтен форточкаларны яба башлыйм. Элек өй җылыту кыйммәткә төшә иде. Безнең Актаныш ягы Оренбург далаларына чиктәш дип әйтерлек, урманнар юк. Без кизәк яга идек. Ә кизәк пыскып яна, җылысы аз. Өйдән җылы чыкмасын өчен, ишекне үз артыңнан бик тиз ябарга кирәк. ...Күбрәк әнкәйдән эләгә, чөнки әткәй гел эштә. Ишекне ачасың да, җәһәт кенә керәсең яки чыгасың. Менә шулай. Җылы безгә һәрчак тансык иде.

Институтка кергәч, Казанда керосинкалар сатыла торган лавкаларның күп икәнлеген күрдем. 50 нче елларда да лавкалар бар иде әле. Мин моны зур казаныш дип саный идем. Хәзер без республикага тоташ газ керттек! Мәскәү өлкәсендә хәзергәчә юк әле, ә бездә бар. Мин кешеләрнең ничек газап чиккәннәрен беләм. Ә хәзер авылда газ ягалар, газда ашарга пешерәләр. Бөтенләй башка тормыш!»

(Лев Овруцкийның «Беседы с Минтимером Шаймиевым» дигән китабыннан (2013) һәм «Безнең мирас» журналының 2015 елгы май санындагы язмадан алынды.)

Мәдәния ИЛЬЯСОВА, М.Ш.Шәймиевнең сеңлесе:

«Безнең Минтимер абыкай бик әйбәт укыды. Бала чагыннан ук аңа әткәй бик зур өмет белән карый иде. «Син безнең прокурор булырсың, син безнең министр булырсың, син безнең галим булырсың!» – дип әйтә торган иде. Безнең әти мәдрәсәдә өч сыйныф кына укыган кеше. Күп нәрсәне үзлегеннән өйрәнгән. Минтимер абыйның әтигә партия тарихын тулысы белән сөйләп-аңлатып чыкканын хәтерлим. Шул вакытта ук аның фикерләү дәрәҗәсе зур булган инде...

Минтимер абый мине мөстәкыйль булырга өйрәтте. Ничек итепме? Мин еш кына: «Моны ничек эшлисе?» – дип сорый идем. Ул әүвәл: «Кагыйдәсе бар аның, укы, өйрән!» – дип әйтә иде. Мин һаман аңлый алмыйча интексәм генә, әйбәтләп төшендерә. Минтимер абыйча бу шулай инде: башта үзең укы, уйлан, тырыш, эшлә. Тагын бер бик әйбәт сыйфаты бар иде Минтимер абыйның: ул вакытны дөрес бүлә белә – уйный, малларны карый... дәрескә утыра. Ә безгә, безнең ишеләргә күбрәк уйнау кирәк инде...»

Шәрип Шаһимөхәммәт улы Шәймиевнең Актаныш районы Әнәк авылындагы музей-йорты

Хәдичә ӘХМӘДУЛЛИНА,
М.Ш.Шәймиевнең беренче укытучысы:

«Мин прокурор булам!» – дигәч:

– Бик усал кеше буласыңмыни? – дим Минтимергә.

– Юк, апа, прокурорны усал дип әйтеп булмый. Закон нәрсә куша, шуны эшлисең дә – бетте-китте! – дигән була...

Бервакыт диктант яздык. Диктантның исеме «Валерий Чкалов» иде. Диктантны язгач, Минтимер:

– Менә, апа, мин дә Чкалов кебек очучы булырга уйладым әле, – дигән була.

– Ярар, – мин әйтәм, – кем булсаң да булырсың... Тик әйбәт укырга кирәк, акыллы булырга кирәк! – дим».

(М.Ш.Шәймиевнең сеңлесе М.Ильясова һәм тәүге укытучысы Х.Әхмәдуллина сөйләгәннәрне Ләбиб Лерон 2006 елның 12 декабрендә язып алды.)

Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев тәүге укытучысы Хәдичә Әхмәдуллина белән. Сентябрь, 2007 ел

Татарстан Республикасы байрагын М.Ш.Шәймиевтән Р.Н.Миңнеханов кабул итеп алган вакыт

Татарстан Президенты Р.Н.Миңнеханов үзенең остазы М.Ш.Шәймиев белән

Р.Н.МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Республикасы Президенты:

«Сез, Минтимер Шәрипович, минем укытучым, остазым. Сезнең белән озак еллар бергә эшләдем һәм Сездән мин тормышны өйрәндем. Киләчәктә дә Сезнең күркәм башлангычларыгызны лаеклы дәвам иттерергә тырышырмын. Сәламәтлек телим Сезгә!»

4 февраль, 2010 ел

Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев хатыны Сәкинә Шакир кызы һәм ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин белән Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры фойесында. 2008-2010 нчы еллар

Ф.Х.МӨХӘММӘТШИН,
Татарстан Республикасы Премьер-министры (1995):

«Кеше буларак, Президент холкындагы бер сыйфатны минем аеруча билгеләп үтәсем килә: ул даими рәвештә кешеләрне кайгырта. Ашкынулы социаль-экономик һәм сәяси тормыш өзлексез үзгәреп торса да, Минтимер Шәрипович кешеләрне беркайчан да онытмый. Аның барысына да вакыты табыла.

Президент Минтимер Шәймиев – киң күңелле кеше. Татарстан халкын ул бик ярата. Мин аңа барыннан да бигрәк сәяси һәм дәүләти озын гомер теләр идем. Минем ерак яисә якын чит ил хөкүмәт вәкилләренең: «Президент Минтимер Шәймиев – тотрыклы республика, тотрыклы сәясәт дигән сүз. Минтимер Шәймиев – ышанычлы кеше», – дигәннәрен кат-кат ишеткәнем бар. Ә бу тулысынча дөрес-хак».

(Татарстан Республикасы Премьер-министры Ф.Х.Мөхәммәтшинның Россиянең «Новости» мәгълумати агентлыгына биргән әңгәмәсеннән. 10 апрель, 1995 ел.)

Минтимер Шәймиев сөекле хатыны Сәкинә ханым белән

Сәкинә ханым яраткан оныклары белән

Урамда бәйрәм парады. Ире кайда – хатыны шунда: Сәкинә Шакир кызы Минтимер Шәрип улы белән янәшә бара

Сәкинә Шакир кызы ШӘЙМИЕВА, ТР Президенты М.Ш.Шәймиевнең хатыны:

«Минтимергә авырга туры килә, чөнки заманы авыр, болгавыр. Аңа авыр икән, миңа да авыр. Кайчак мине борчу биләп ала. Минтимергә бик көчле һөҗүмнәр башланган чакларда. Әмма мин Минтимергә – аның акылына, сабырлыгына ышанам. Аның сәясәтен, фикерләрен тулысы белән уртаклашам. Минтимергә ышанам икән, димәк, Татарстан халыкларының киләчәгенә дә ышанам.

Минем ике теләгем бар. Беренчедән, мин татар мәктәбендә ярты ел да укый алмадым. Шуңа күрә үземне ничектер кимчелекле кеше кебек хис итәм. Яшьләр, бигрәк тә шәһәр яшьләре мондый хатаны кабатламасын, татар телен өйрәнсен, балаларына да өйрәтсен иде. Зыялы кеше аз дигәндә 2-3 тел белергә тиеш. Иң әүвәл, әлбәттә, ана телен. Икенчесе – кайбер кешеләр тормышның гел начар якларын гына күрергә күнеккән. Ә бит һәр кешенең тормышында авырлыклар гына түгел, истә калырлык матур сәхифәләр дә бар. Күбрәк шуларны искә алып, күбрәк елмаеп, бер-береңә авыр сүз әйтмичә, кимсетмичә, ярдәмләшеп яшәргә иде. Дөнья бик матур бит ул һәм дөньяга кеше бик азга гына килгән. Шушы хакыйкатьне беркайчан да онытмагыз, дияр идем».

(Журналист Рәйсә Йосыпованың «Татарстан» журналының 1993 елдагы 1 нче санында басылган очеркыннан алынды.)

Сәкинә ханым

(Җыр)

Гөлшат Зәйнашева сүзләре,
Фәрит Хатыйпов көе

Син үстергән ап-ак розаларны
Шау чәчәктә диләр көзен дә.
Әллә үзең роза чәчәкме син,
Сәкинә ханым,
Чәчәк елмаюы йөзеңдә.

Моңаясың кайчак, мөмкинме соң
Гел елмаеп кына яшәргә?!
Акбүз атка менеп, сөйгән ярың,
Сәкинә ханым,
Китте мәллә ерак сәфәргә?

Юк, моңайма, кайтыр сөйгән ярың,
Газиз башкайларың сау булсын.
Ул да сине сөйсен синең кебек,
Сәкинә ханым,
Синең сагыну белән сагынсын!

Татарстанның Беренче Президенты, ТРның Дәүләт Киңәшчесе, ЮНЕСКОның мәдәниятара диалог буенча Махсус илчесе, Россия Федерациясенең Хезмәт Герое Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә 20 гыйнварда 85 яшь тула. Мөхтәрәм шәхесебезне юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм игелекле олы хезмәтендә уңышлар телибез.

М.Ш.ШӘЙМИЕВ,
Татарстан Республикасы Президенты (1995):

«Президентларга хыялланырга яраса, мин туган Республикам Татарстанны югары үсеш алган, халыклары арасында тынычлык һәм татулык хөкем сөргән, иҗади хезмәт кайнап торган, суверен, хокукый дәүләт итеп күз алдыма китерәм. Күчеш чорының барча читенлекләре, мәшәкатьләре инде арттa калган, кешеләрнең йөзендә елмаю уйный торган республика итеп күзаллыйм.

Ул көнгә еракмы әле? Ерак та, якын да.

Ерак, чөнки Татарстан халкына әлегә тынычланырга, үз-үзен юатырга урын юк. Һәр җирдәге кебек җитештерү кими, кыйммәтчелек арта, тормыш дәрәҗәсе түбәнәя, бусага төбендә эшсезлек басып тора.

Якын да, чөнки Татарстанның күпмилләтле халкы искиткеч тырыш... Халкыбызның меңьеллык матди һәм рухи мәдәнияте, әгәр шулай әйтергә мөмкин булса, ныклы әхлакый нигезе бар. Әгәр бу халык царизмның, ә соңыннан тоталитаризмның рәхимсез җәберләү елларында үзенең югары әхлакый сыйфатларын югалтмыйча исән калган икән, ул үзендә бүгенге авырлыкларны җиңеп чыгарга да көч табачак...

Башкача әйтсәк, киләчәк өчен әле армыйталмый эшләргә дә эшләргә кирәк. Нәкъ менә бүген эшләргә кирәк. Ә киләчәкнең, конкрет алганда, нинди буласын әлегә әйтүе кыен».

(Р.Ә.Мостафин һәм Ә.Х.Хәсәновның «Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев (сәяси сурәтенә шәрехләр)» китабы (1996) файдаланылды.)

(Татарстанның Беренче Президенты, ТРның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең төрле елларда төшкән кайбер фотосурәтләре – аңа багышланган китаплардан, әлеге сәхифәдәге фотоларның бер өлеше исә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Леронның шәхси архивыннан алынды.)

Хәлиткеч мизгел:
иң мөһим документка кул
куйган вакыт...
Рамил Галиев фотосы

ТР Президентының халык
алдында җавап тоткан мәле.
Альберт Биктимеров фотосы

Казан Кремлендә
Австралиянең Россиядәге
илчесен кабул иткән чак.
Наил Курамшин фотосы

Минтимер Шәймиев – Язучылар йортында

Туфан МИҢНУЛЛИН, Татарстанның халык язучысы:

«Гади татар авылында туып-үскән малайдан Ил башы дәрәҗәсенә күтәрелү өчен, гаҗәп зирәк акыллы, тырыш, тәвәккәл, көчле характерлы, белемле, мәгънәле һәм тагын бик күп асыл сыйфатларга ия булырга кирәк. Ә бит бәйләнеп куелган дәүләтнең Президенты булу бәйсез дәүләт башлыгы булудан күпкә авыррак».

Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев Мөштәри урамындагы Язучылар йортында һәм шул бинада урнашкан «Идел» журналы редакциясендә. 2006-2008 нче еллар. Фотолар беренче мәртәбә басыла. ***Ләбиб Лерон архивыннан***

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – язучылар, галимнәр, журналистлар, дин һәм сәнгать әһелләре, спортчылар гыйнвар аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

1 гыйнвар – актер, Татарстанның халык артисты (2003) **Әсхәт Әсәдулла улы Хисмәтов**ка 70 яшь (1952);

2 гыйнвар – сәнгать белгече, сәнгать фәннәре докторы (1998), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2007) **Гүзәл Фуад кызы Вәлиева-Сөләйманова**га 70 яшь (1952);

2 гыйнвар – журналист, язучы, рәссам, СССР журналистлар берлеге әгъзасы (1980), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1997), ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты **Дания Заһретдин кызы Гайнетдинова**га 70 яшь (1952);

2 гыйнвар – тел галиме, филология фәннәре докторы (1998), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2010) **Флера Сәет кызы Баязитова**га 80 яшь (1942);

3 гыйнвар – этнолог, тарих фәннәре докторы (2000), Татарстанның Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт премиясе лауреаты (2003) **Дамир Мәүләви улы Исхаков**ка 70 яшь (1952);

6 гыйнвар – рәссам, РФ һәм ТР Рәссамнар берлекләре әгъзасы (2002), ТРның М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты (2007), ТР Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исемендәге бүләге иясе (2003) **Булат Әлфир улы Гыйлванов**ка 50 яшь (1972);

8 гыйнвар – табиб-пульмонолог, язучы, төбәк тарихын өйрәнүче, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (2000) **Нәкыйп Фәсхетдин улы Каштанов**ка 80 яшь (1942);

18 гыйнвар – шахматчы, атказанган спорт мастеры, хатын-кызлар арасында халыкара гроссмейстер, күп тапкырлар Россия чемпионы **Алисә Михайл кызы Галләмова**га 50 яшь (1972).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Рәмис Сафиуллов: «Музей ул – матурлык! Аны тоя белергә кирәк...»

Рәмис Сафиуллов

Ләбиб Лерон

Журналыбызның 11 нче санында Тәтеш төбәгендә татар тарихын һәм Тәтештә Исхак һәм Хаҗиморат Казаковлар мирасын саклау мәсьәләсе күтәрелгән иде. Шул уңайдан без, редколлегия әгъзалары, дин эшлеклеләре белән бергә, Тәтештә «Безнең мирас» журналының күчмә утырышын уздырып, үзебезне борчыган сорауларны район башлыгы Рәмис Хатыйп улы Сафиулловка да бирдек.

– Рәмис Хатыйп улы, Татарстаныбыздагы районнар бер-берсеннән аерылып тора, һәрберсенең үз йөзе. Бу җәһәттән Тәтеш кайсы ягы белән үзенчәлекле дип саныйсыз?

– Районның халкы бик тырыш. Әмма иң кыйммәтлесе – район халкының, күпмилләтле булып, дус-тату яшәвендә. Шушы татулыкны саклау һәм төрле мәдәниятләрне үстерү – төп максатларыбызның берсе.

Казаковлар – безнең бай тарихыбыз. Тәтеш төбәге тарихы музее хезмәткәрләре белән әлеге шәхесне (сүз Исхак Казаков турында бара. – *Ред.*) өйрәнү юлында зур хезмәт башлап җибәрдек. Кайчакта оят та булып китә: атаклы чуаш мәгърифәтчесе Иван Яковлевны беләбез, ә үзебезнең шәхесләрне онытып җибәрәбез.

– Исхак Казаков... Шушы бер шәхес XX гасыр башында Тәтеш шәһәре һәм өязенең мәгариф тарихында зур эшләр башкара. «Казаков мәктәбе» дигән данлыклы гыйлем учагы булдыра ул. Исхак Казаков 1917 елда ук «Тәтеш оешмасы» исемле милли газетаның баш мөхәррире вазыйфасын башкарган. Соңрак, атаклы сәясәтче буларак, Ленин, Сталиннар белән аралаша. Татар балалары өчен рус теле дәреслекләре яза. Исхак Казаков – ТАССРны төзүдә катнашкан җиде шәхеснең берсе. Казандагы бик күп тарихи биналарны төзекләндерүдә дә, Мулланур Вахитовның исемен мәңгеләштерүдә дә ул башлап йөри. Исхак Казаков «Татарстанда нефть бармы?» дигән мәкалә язып, атаклы геолог Иван Михайлович Губкинны Казанга китерә. Бакчачылык белән кызыксына... Ул – 1920 нче елларда татар халкын ачлыктан коткарган кеше. Гомумән, бу шәхес хакында күп сөйләргә була. Тәтеш төбәгендә аның исеме игътибардан читтә калырга тиеш түгел!

Атаклы химик Гыйлем Камай, хәрби атташе Һади Маликов, татар халкына Мансур Мозаффаров дигән композиторны тудырган Маһруй Мозаффарияләр – Тәтеш төбәгенең йөзек кашы. Исхак Казаковның улы, танылган рәссам Хаҗиморат Казаков («Бәләкәй Апуш» картинасының авторы) та Тәтешкә еш килеп йөргән. Мулланур Вахитов та әнисенең бертуган энесе булган Исхак янына Тәтешкә кайтып, революцион хәрәкәтне җанландырган.

Шуларны искә алып, бернича тәкъдимем бар. Берсе – Тәтештә аталы-уллы Исхак һәм Хаҗиморат Казаковлар урамнарын булдыру. Алар моңа бик тә лаек...

– Иске урамнарга яңа исемнәр кушуны вәгъдә итә алмыйм. Бу – бик катлаулы процесс, халык белән килешергә, кануннарны өйрәнергә кирәк. Дөрес, районда яшәгән һәр кеше Сез искә алган шәхесләрне белергә тиеш. Тәтеш шәһәре елдан-ел үсә бара, яңа урамнар төзелә. Менә аларга Казаковлар исемен бирергә мөмкин. Беренчедән, бу тарихка кереп калачак. Икенчедән, әлеге шәхес үзенә бөтенләй тарих белән кызыксынмаган кешене дә җәлеп итәргә мөмкин. Кызганыч, икешәр югары белем алган кешеләр арасында да әби-бабайларының кайсы авылда туганлыгын белмәүчеләр бар. Ә кайда җирләнгәнлекләре, каберләре турында бөтенләй хәбәрдар түгел. Мин моны зур мәгънәсезлек дип саныйм. Әлеге хатаны, һичшиксез, төзәтергә кирәк. Мәдәният һәм мәгариф оешмалары бу юнәлештә тырышып эшләргә тиеш. Урам исеме бирә калсак, күпләрдә, һичшиксез: «Кем ул Казаков?» – дигән сорау туачак...

«Тәтеш шәһәре елдан-ел үсә бара бара, яңа урамнар төзелә. Менә аларга Казаковлар исемен бирергә мөмкин.

– Тәтеш шәһәрендә Исхак Казаков укыткан мәктәп бинасы бар. Ул – әлеге мәктәпне оештыручыларның берсе, соңрак биредә мөселман мәктәпләре бүлеге мөдире булып та эшли. Бу бинага да бер истәлек билгесе куясы иде.

– Әлбәттә, аның тарихын җентекләп өйрәнеп, әлеге йортта истәлек тактасы яки бюст булдырырга кирәк. Сезнең белән тулысынча килешәм. Тәтешкә сезонга 110 мең турист килә. Бу йорт, һәр тарихи бина – зур байлыгыбыз. Без аларны кунакларга күрсәтергә тиеш! Әлеге бина хәзер эшкуар кулында. Дөрес, ул бинаны тышлады, әмма йөзлекләрнең, кәрнизнең бер өлешен калдырды. Әгәр аңлы кеше аңа

игътибар белән карый икән: анда таң калырлык матурлык! Аны чын талантлар эшләгән. Моннан соң без һәр агач бинаны, аның һәр тактасын саклап калырга телибез.

«Казаков укыткан мәктәптә истәлек тактасы яки бюст булдырырга кирәк.

– Тәтешнең музее искиткеч бай. Ул бай тарихлы бинада урнашкан. Биредә булып, мин андагы мирасның затлылыгына таң калган идем. Әмма анда Тәтеш төбәгенә бәйле татар шәхесләренең эшчәнлеге бик аз яктыртылган. Шәһәрдә Казаковларны һәм башка күренекле тәтешлеләрне, Әтрәчне, аның бай нумизматик мирасын күрсәтә торган тагын бер музей оештырып булмасмы?

– Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов музейны капиталь төзекләндерү идеясен хуплады. Ул, бирегә килеп, музейларыбызга югары бәя бирде. Хәзерге көндә музейның өч-дүрт бинасы бар. Быел тагын ике бинаны төзекләндереп, музей карамагына тапшырырга ниятлибез. Шулай итеп, Тәтештә музейлар саны янә артачак. Ә инде татар милләтенә, аның мәшһүр шәхесләренә нисбәтле экспонатларга килгәндә, әлбәттә, алар да урын алачак. Татар музее заманча булырга тиеш. Тәтеш районында тарих һәм архитектура истәлекләре булган биналар күп. Аларның барысы да, вакытлар җитү белән, мәгънәле итеп төзекләндерелергә тиеш. Мин үзем дә музейларда булырга яратам. Һәр экспонатка карыйм да уйланам: аны ничек ясаганнар, моның белән нәрсә эшләгәннәр? Нинди югары һәм зәвыклы сәнгать үрнәге булган ул! Аны эшләү технологиясе ничек булган? Хәзерге көндә кыйммәте нидә? Музей ул – матурлык! Аны тоя белергә кирәк. Үземә боларның барысы да бик кызык. Экспонатларны, тарихи биналарны күреп, алардан шул чорның тарихын «укып» булсын иде. Әлбәттә, халкыбызның бай тарихына да тиешле дәрәҗәдә игътибар булыр дип ышанам.

«Тәтештә музейлар саны янә артачак. Ә инде татар милләтенә, аның мәшһүр шәхесләренә нисбәтле экспонатларга килгәндә, әлбәттә, алар да урын алачак. Татар музее заманча булырга тиеш.

Олы Әтрәчтәге бай мәдәнияткә дә җитди һәм зур максатлар белән якын килергә кирәк. Ул – ата-бабаларыбызның борынгы җире, изге туфрагы.

Гомумән, тарихка, милли мираска кызыксыну уятуның башка формаларын да актив файдаланырга кирәк дип уйлыйм. Кызганыч, Казаковлар, Мозаффариялләр турында бик азлар белә. Бәлки, эшне мәктәпләрдән үк башларга кирәктер. Ә нигә уку йортларына мәшһүрләребезнең исемен бирмәскә?!. Шунда ук аларга багышланган музей-почмаклар да булдыра алыр идек. Төбәкне өйрәнү буенча түгәрәкләр оештыру эшен, өстәмә дәресләр үткәрүне дә активлаштырырга кирәк.

– ИншаАллаһ, киләчәктә Тәтеш ягы Болгар дәүләтенең мөһим өлеше, татар мәгарифе һәм мәдәниятенең үзәге рәвешендә өйрәнелер һәм аңа кагылышлы махсус туристик маршрутлар булдырылыр дигән өметтә калабыз. Бу тарихта Казаковларның лаеклы урыны яктыртылыр дип уйлыйм.

Ләбиб Лерон *әңгәмәсе*

«Татарстанда Болгарларның тарихы Тәтеш районыннан башлана»

(Утырышта яңгыраган кайбер фикерләр)

Индус Таһиров,
академик:

Татарның фәкать үз-үзенә генә ышанып яшәү вакыты җитте.

«Һәр төбәктә татар яшәеше безнең өчен беренче урында торырга тиеш. Бүген татарның чит-ятларга түгел, фәкать үз-үзенә генә ышанып яшәү вакыты җитте. Безнең өчен беркем дә бернәрсә дә эшләмәячәк. Әгәр дә милләт үз-үзен саклый алам дигән фикергә килгән икән, димәк, аның киләчәге зур».

Харис Камалиев,
галим-агроном:

Тарихын белмәгән кеше – тамырсыз үсемлек.

«Тарихын белмәгән кеше – тамырсыз үсемлек. Тарихны халык тудыра, әмма халыкны лидерлар җитәкли. Казаковлар – Тәтеш төбәгенең горурлыгы. Тәтештә татар музее оешса, аның эчтәлеге дә затлы булырга тиеш. Хәзерге төбәк тарихы музеенда үзебезнең геройларны тиешле дәрәҗәдә күргәнем юк. Киләчәктә бу эш алга китәр дип уйлыйм».

Ильяс хәзрәт Җиһаншин, *Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры:*

Горурланырлык дин әһелләре болар.

«Ата-бабаларын, милләтен, олуг затларын белгән кеше беркайчан да диненнән, милләтеннән ваз кичмәячәк, чит-ятларның тәэсиренә һичкайчан бирелмәячәк, иншәАллаһ.

Тарихи вакыйгалар, олуг шәхесләрнең яшәеше – күпмедер мәгънәдә халкыбызның гомер китабы. Үзебезнең туган төбәгебезне белү бик мөһим. Халкыбызны белемле итү юлында күп тырышлыклар куйган олуг милләттәшләребезне барлау, аларны яшь буынга үрнәк-өлге итеп кую – изге бурычыбыз. Гыйлеме, изге гамәлләре белән мәшһүр кайбер шәхесләрне атап үтәм. Олы Тархан авылында данлыклы, тирә-якта дан казанган шәех, ишан Нуреддин хәзрәт Мостай имамлык иткән. Атаклы композитор Мансур Мозаффаровның тамырлары Тәтеш төбәгенә бәйле. Аның әнисе – әдәбият дөньясында беренче шагыйрә, Тәтеш төбәгеннән чыккан татар мәгърифәте йолдызы Маһруй абыстай Мозаффария. Гаҗәеп, һәрберебез горурланырлык дин әһелләре болар. 1921 елда Тәтештә яңа электр станциясе ачыла. Аның барлыкка килүенә Тәтеш өяз башкарма комитеты рәисе Кәримулла Хөснулла улы Исмаев күп көч куйды. Ул – 1928-1930 нчы елларда Татарстан АССР Халык Комиссарлары советы рәисе буларак, беренче бишьеллык планны тәкъдим итеп, аны тиешенчә үтәүне оештырган олы шәхес.

Әлбәттә, бу исемлекне тагын дәвам итеп булыр иде. Горурланып сөйләрлек якташларыбыз күп. Шанлы Тәтеш төбәгендә – ошбу татар дөньясы өчен кадерле урында татар зыялылары белән җыелып, тарихыбыз, бүгенге тормышыбыз һәм киләчәк турында фикер алышуларыбыз дәвамлы булсын иде, дип теләп, Аллаһыга догада булыйк, мөхтәрәм җәмәгать».

Айрат Фәйзрахманов, *ТР Мәдәният министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге мөдире, тарихчы:*

Тәтеш шәһәре үзе үк Болгар җире.

«Тәтеш районындагы Олы Тархан авылында болгарларның Татарстанда табылган иң борынгы каберлеге бар. Болгарлар тарихы Татарстан җирлегендә нәкъ менә Тәтеш районыннан башлана. Кызганыч, күпләр бу турыда белми. Махсус күрсәткечләр, истәлек билгеләре куелса, туристларның да игътибарын җәлеп итеп булыр иде.

Тәтеш шәһәре үзе үк Болгар җире. Аяныч, аның болгар чорында шәһәрлек булган өлеше хәзер йортлар астында калган булса да, без фәндә Тәтешне болгар тарихының үзәге дип саныйбыз.

Олы Әтрәч тарихы белән танышып, андагы байлыкны күреп таң калдым. Әлбәттә, бу тарихларны да танытып, махсус мәдәни маршрут төзеп булыр иде. Дөрес, бу юнәлешкә күп сандагы туристларны җәлеп итеп, табыш алып булмый, әмма аны дини мәгариф, мәдәни-агарту максатыннан файдаланырга бик тә мөмкин.

Казаковлар Тәтеш тарихы белән генә түгел, ә Казан һәм Әстерхан шәһәрләрендәге мөселманнар тормышы белән дә бәйле. Дөрестән дә, әлеге зур тарих аерым игътибарга лаек».

P.S.: Бу тәкъдимнәр дә хакимият башлыгы тарафыннан хуплап кабул ителде.

20 ноябрь, 2021 ел. ■

Миллəт сагында

Фираз Харисов, педагогика фəннəре докторы

Тəрбия һəм белем бирү бер-берсеннəн аерылгысыз.
Белем бирмичə, тəрбиялəп булмый.
Белем бирү үзе тəрбияли.
Л.Н.Толстой

Идел буенда яшəгəн бик күп миллəт вəкиллəренең аң-белем үсеше өчен Казан шəһəре – Татарстан Республикасының башкаласы – элек-электəн белем һəм мəгърифəт учагы булып санала. Аның үсешенə əле XIX гасыр башында ук – 1804 елда ачылган университет зур этəргеч бирə. Соңрак чорда эшли башлаган башка югары уку йортлары, аларда хезмəт куйган галимнəр, зур бер мəгърифəт учагының чаткылары кебек, ил-көнгə яктылык чəчəлəр. Алар арасында төрле миллəт вəкиллəре булуы, татарстанлыларның күптөрле халыклар белəн дустанə хезмəттəшлек итеп, аралашып яшəве нур өстенə нур өсти. Бу да республикабызда үткəрелə торган сəясəткə нигезлəнə: дəүлəт күлəмендə дə, төрле дəрəҗəдəге оешма, предприятие, уку йортлары, мəдəният учакларының гамəллəрендə чагылыш таба, бəрəкəтле нəтиҗəлəргə китерə. Аларның матур үрнəге Татарстан Фəннəр академиясе һəм чит ил академиялəре академигы, республикабызның Фəн һəм техника өлкəсендəге дəүлəт бүлəге лауреаты, төрле дəрəҗəдəге премиялəр иясе, филология фəннəре докторы, профессор Рүзəл Абдуллаҗан

улы Юсупов күп еллар буе җитәкләгән Казан дәүләт педагогика университеты тарихында да ачык күренә.

Киң җәмәгатьчелек Р.А.Юсуповны олуг галим-мөгаллим, укыту-тәрбия эшен нәтиҗәле итеп оештыручы, икетеллелек (күптеллелек), тәрҗемә һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре буенча күләмле монографияләр, фәнни-популяр хезмәтләр, дәреслек, кулланма, программа һәм мәкаләләр авторы буларак белә. Әйтергә кирәк, аның соңгы еллардагы фәнни-популяр юнәлештәге, публицистикадагы, журналистикадагы активлыгы (радио һәм телевидениедәге ялкынлы чыгышлары, ел саен басылып чыккан китаплары, мәкаләләре – барысын да санап бетерерлек түгел!) безне таң калдыра.

Язмыш Рүзәлгә җиңел тормыш әзерләп куймый, аның гомер юлында авырлыклар һәм киртәләр еш очрый. Шуңа да карамастан, ул мәгънәле, нәтиҗәле, җәмгыятькә файдалы, игелекле эш башкара, фән һәм мәгариф дөньясында бик күпләргә үрнәк булырлык итеп хезмәт куя.

Балачагы Татарстанның Арча районындагы Кышкар авылында узган Рүзәл ишле гаиләдә үсә. Бөек Ватан сугышы алдыннан туган бик күп яшьтәшләре кебек үк, аңа да тормышның ачысын-төчесен, авыр крестьян хезмәтен кечкенәдән татырга туры килә. Рүзәл биш балалы гаиләдә әнисе Лотфикамал апаның төп терәге була, өй эшләренең күбесе аның җилкәсенә төшә.

Укуга омтылышы кече яшьтән үк ифрат зур булганга, ул иптәшләреннән иртәрәк, кышкы каникулдан соң ук, беренче сыйныфка йөри башлый. «Укудан күңеле тиз сүрелер», – дип көткән олылар, аның һәрвакыт «биш»ле билгеләренә генә укуын, мәктәпкә бик дәртләнеп йөрүен күреп, башта бераз гаҗәпләнсәләр дә, Рүзәлнең, моннан тыш, өй эшләренә дә өлгерүе абыйларында аңа карата олы хөрмәт хисләре уята. Татар телендә белем алып, җиденче сыйныфны уку алдынгысы булып тәмамлаган Рүзәл, беренче тапкырдан ук имтиханнарын рус телендә уңышлы тапшырып, Казан кооперация техникумына укырга керә. Аннан соң әле унҗиде яше дә тулмаган егетне Курган өлкәсенең бер шәһәренә товаровед итеп эшкә җибәрәләр. Анда күргән кыенлыклар егетнең күңелендә бик тирән уелып кала. Озакламый хәрби хезмәткә китәр вакыты җитә. Рүзәл армиядә Памир тауларында чик сакчысы була. Бу чорда ул зур чыныгу мәктәбе уза дияргә дә мөмкин…

Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә үк Рүзәл киләчәктәге тормышы турында ныклап уйлана һәм катгый фикергә килә: ул Казанга кайтачак, югары белем алачак, илгә һәм милләткә файдалы гамәлләр кылачак!

Армиядән белемгә сусап кайткан Кышкар егете данлыклы Казан университетының тарих-филология факультетына укырга керә, гыйлем дөньясына чума, тырышып белем эсти. Алай гына да түгел, уку алдынгысы буларак, берничә ел буе Ленин исемен йөрткән дәрәҗәле стипендия ала, факультетның комсомол оешмасы секретаре итеп сайлана, профсоюз һәм партия оешмаларында күптөрле вазыйфалар башкара. Университетны кызыл дипломга тәмамлаган яшь белгечне Казан телевидениесенә мөхәррир итеп эшкә алалар. Анда ул берничә ел дәвамында телевидение журналистикасы серләренә төшенә. Әмма студент елларында ук ымсындырган галим булу теләге һаман күңелен кымтырыклый. Егет, тәвәкәлләп, Казан дәүләт педагогика институтының ул чактагы ректоры, профессор Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев җитәкчелегендә «Төрки телләр (татар теле)» белгечлеге буенча аспирантурага укырга керә. Башта кандидатлык, соңрак филология фәннәре докторы дигән

Р.А.Юсупов – студентлар төркеме җитәкчесе

гыйльми дәрәҗәләргә ирешә, диссертацияләр язып яклый. Югары уку йорты укытучысына тиешле барлык баскычларны үтә: аспирант, докторант, ассистенттан алып профессорга кадәр үсә, кафедра мөдире, декан һәм 18 ел буе шушы уку йортында ректор булып эшли.

Р.А.Юсупов җитәкчелек иткән еллар пединститут өчен зур үзгәрешләр чоры дип әйтсәк, һич тә хата булмас: бу вакытта аның матди-техник базасы ныгытыла, уку-укыту процессының сыйфаты шактый күтәрелә, кафедралар, докторлар һәм профессорлар саны бермә-бер арта, заман таләп иткән белгечлекләр ачыла, уку планнары фән-техника казанышларына җавап бирердәй итеп үзгәртелә.

Шунысы да әһәмиятле: 1996 елда, Россиядә беренчеләрдән булып, Казан педагогика институты университет статусын алуга ирешә.

Узган гасырның 80-90 нчы елларын педагогика институты тарихында яңарыш чоры дип атау дөреслеккә туры килер, мөгаен. Чөнки ул вакытта булачак белгечләрнең белемнәрен яңа дәрәҗәгә күтәрү, алдынгы халыкара тәҗрибәне үзләштерү максатыннан, АКШ, Англия, Германия, Франция, Кытай, Төркия һәм башка илләр белән тыгыз бәйләнешләр урнаштырыла башлый. Аралашып эшләү, уку һәм укыту процессы берничә юнәлештә башкарыла. Шуларның кайберләренә генә тукталып китик.

Югары уку йортының Россия Федерациясендәге башка педагогик югары уку йортлары арасында зур абруй казанган чит телләр факультетында, традицион рәвештә укытылып килгән инглиз, алман, француз телләренә өстәп, испан, төрек, гарәп, кытай, япон, һинди һәм фарсы телләре дә укытыла башлый. Аларны яхшы итеп өйрәтү өчен, чит илләрдән укытучылар чакырыла һәм, белемнәрен ныгыту

максатыннан чыгып, студентларны шул илләргә стажировкага җибәрү тәртибе кертелә.

1996 елда Рүзәл Абдуллаҗанович Кытай Халык Республикасының Гуйлин педуниверситеты (Гуанси провинциясе) җитәкчелеге чакыруы буенча анда барып, безнең өчен бик тә әһәмиятле ике яклы килешү төзеп кайта. Нәкъ шуннан соң, илебездә беренчеләрдән булып, барлык факультетларда да яшь буынга белем һәм тәрбия бирәчәк укытучыларга музыка һәм хореография фәннәре укытыла башлый. Бу вазыйфаны махсус төзелгән музыка тәрбиясе нигезләре кафедрасы башкара.

Университетның рус филологиясе факультетында махсус кафедра ачылып, әзерлек курсларында чит ил студентларын рус теленә өйрәтү эше башлана. Бу гамәл дә уңай нәтиҗәләрен бирә: ерак һәм якын илләрдән килгән студентлар рус теленнән төпле белем алу мөмкинлегенә ирешә.

Узган гасырның 90 нчы еллар уртасыннан башлап, ректор Р.А.Юсупов тырышлыгы белән, югары белемле милли кадрлар әзерләү тарихында беренче тапкыр барлык белгечлекләр буенча ике дәүләт телендә эшли алырдай укытучылар әзерләнә башлый.

Барыбызга да мәгълүм: 1992 елда республикабыз парламенты Татарстан халыклары телләре турында закон кабул итә. Югары Совет депутаты Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов, комитет рәисе буларак, аны эшләүдә һәм тормышка ашыруда катнаша, сессия утырышында депутатлар каршында төп доклад белән чыгыш ясый. Шушы вакытта Казан педагогика университетында, законны тормышка ашыру йөзеннән, чуаш халкы белән дуслык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен ныгыту, чуаш яшьләренә туган телләрен укытуда ярдәм итү максатыннан, рус филологиясе факультетында чуаш теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. Әлбәттә, педагогика университетының мондый инновацион адымнары, шулар нигезендә яңа үрләргә ирешүе һәм халыкара эшчәнлегендәге активлыгы – коллективның ректор Р.А.Юсупов җитәкчелегендә башкарылган уртак хезмәт җимеше.

Билгеле булганча, 2021 ел Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителгән иде. Дуслык төшенчәсенең мәгънәсе бик күптөрле. Республикабызда аның байтак матур үрнәкләрен табып була. Заманында Россиядә өченче булып (Санкт-Петербург белән Мәскәүдән кала) ачылган күренекле Казан педагогика университеты, илебезгә югары белемле, тәрбияле педагоглар һәм мәдәният хезмәткәрләре әзерләү белән бергә, халыклар дуслыгын ныгыту эшенә дә зур өлеш кертте. Шунысын ассызыкларга кирәк: безнең университетта студентларны тәрбияләү эше махсус программа буенча оештырылып килде. Без яшь белгечләрне «тәрбия һәм белем бирү бер-берсеннән аерылгысыз» дип санаган тулы бер система аша әзерләдек. Хәзерге яшәеш, бүгенге вазгыять күзлегеннән караганда, әлеге эшчәнлекнең никадәр әһәмиятле булуы аермачык күренә.

Профессор Р.А.Юсуповның халыкара багланышларга, дуслыкны ныгытуга караган эшчәнлеген тасвирлаганда аның чит илләр белән дә тыгыз хезмәттәшлек итүен, халыкара конференцияләрдә һәм симпозиумнарда катнашуын да истә тотарга кирәк. Ул – чит илләр академияләре академигы. Аңа, фән, мәгариф, җитәкчелек һәм җәмәгать эшләрендә күрсәткән казанышлары өчен, 1997 елда Американың халыкара биография институты һәм Англиянең Кембридж халыка-

ра биография институты тарафыннан «Ел кешесе» дигән мактаулы исем бирелде. Галим, үзе хезмәттәшлек иткән илләрдәге мәгариф системаларын өйрәнеп, республикабыздагы белем бирү системасын камилләштерүгә караган фикерләре белән вакытлы матбугатта бик теләп уртаклаша.

Академик Р.А.Юсуповның фәнни-методик эшчәнлегенә игътибар белән карасак, аның бөтен гомерен телебезне өйрәнү һәм өйрәтүгә, яклау һәм саклауга багышлавын күрербез.

Бүгенге көндә галим – фәнни, фәнни-популяр, лингводидактика, публицистика юнәлешләрендә иҗат ителгән 800гә якын (шуларның 100гә якыны – китаплар) хезмәт авторы. Ул гына да түгел, Р.А.Юсуповның үз фәнни мәктәбе бар. Аның җитәкчелегендә 40тан артык кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре якланды, ул 25 елга якын Чагыштырма грамматика буенча докторлык диссертацияләре яклау советы рәисе вазыйфаларын башкарды. Рүзәл Абдуллаҗановичның күпсанлы шәкертләре фән өлкәсендә республикабызда һәм аннан читтә уңышлы эшлиләр.

Соңгы елларда вакытлы матбугатта телдән һәм язма сөйләмдә «чәчәк аткан» җитешсезлекләрнең күплеген яклауга һәм аклауга багышланган мәкаләләр шактый күбәйде. Әмма: «Без – мәгърифәтле халык», – дип күкрәк кагабыз икән, хәзерге татар әдәби телен сакларга, аңа тел-теш тидермәскә кирәк, чөнки туган телебез бер һәм бердәнбер! Ул бүген безнең шушы өлкәдә тырышлык күрсәтүебезгә бик мохтаҗ. Төрле электрон басмалар, мәгълүмати чаралар хакимлек иткән чорда, әлбәттә, телнең сафлыгына ирешү җиңел түгел, әмма аңа (телгә) кагылышы булган һөнәр ияләре үзләренең әдәби телне саклаучы, үстерүче булуларын һәрдаим истә тотсыннар иде. Академик Р.А.Юсупов нәкъ шушы юнәлештә бихисап күп эшли, зур активлык күрсәтә: радио-телевидение аша да, дөнья күргән хезмәтләре ярдәмендә дә, тел мәсьәләсендә сак булырга өнди. Аның телне куллануга караган кимчелекләр, аларны киметү һәм бетерү өчен кирәк булган эш-гамәлләр турында ихлас күңелдән борчылып язган хезмәтләре бүгенге көндә «Горур булыйк» исемле кульязма китапка тупланган. Шунда урын алган «Әдәби телебезгә реформа кирәкме» исемле мәкаләсеннән бер өзекне тәкъдим итмичә булдыра алмыйбыз: *«Әдәби телебезгә ревизия ясыйсы юк: ул бик әйбәт. Аны яхшылап өйрәнергә, белергә һәм иркен, дөрес кулланырга гына кирәк. Татарларның яртысыннан күбесе үз телендә аралашмый, китап, газета-журналлар укымый, татар мәктәпләренең саны елдан-ел кими, калганнарында да, хәтта авыллардагы татар мәктәпләрендә дә русча укытуга күчә баралар, рус мәктәпләрендә укыган күп меңләгән татар балаларына туган телләрен өйрәтү ярым-йорты гына башкарыла. Шуның өстенә, иң хәтәре: татар халкының күбесендә милли рух, милли горурлык хисләре түбән яки юк дәрәҗәсендә. Менә шулар хакында күбрәк язарга һәм чаң сугарга кирәк»*.

Әйе, Рүзәл Абдуллаҗан улы бик хаклы рәвештә туган телебезнең «ярымйорты гына» өйрәнелүенә, кулланылуына әрни, борчыла. Билгеле, телара мөнәсәбәтләр дә һәрвакыт берьяклы гына бармый: алынма сүзләр бер-берсенә үтеп керергә мөмкин. Әмма һәр телнең үзенә генә хас булган эчке законнары бар һәм аларны истә тоту зарур. Шул турыда уйланырга, эзләнергә нәрсә этәрә соң галимне? Әлбәттә, аның тел белеме өлкәсендә киң танылу алган һәм без санап узган эшчәнлеге, зур тәҗрибәсе. ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Пекин. XX гасыр башы

Пекинның һавасы

Һаваның нинди булуына минем бик исем китми, шулай булса да, Пекин һавасының йомшак булуы игътибарымнан читтә калмады. Бередә эсселек 35-40°ка җитәргә мөмкин. Икенче карыйсың, бер-бер артлы рәхмәт яңгырлары явып үтә. Нindидер үзгә чирләр турында сөйләүләрен бер дә ишетмәдем. Сораганым да булды: берни юк дип әйтерлек иде.

Бакчалар шаулап үсә, Пекинның әйләнә-тирәсендә җиләк-җимешнең һәммә төре үсеп җитешә, хәтта дөньяның башка бер генә җирендә дә булмаган, бары тик Кытайда гына үсә торганнары да бар. Тик җиләк-җимешләрнең тәме, чагыштырмача әйткәндә, әллә ни түгел. Мәсәлән, Бохарада һәрбер җиләк-җимеш гаҗәеп тәмле була. Безнең Истанбулда да бик тәмле җиләк-җимешләр бар. Кытай Төркестанында тәме искитәрлек бер төр алма үсә. Болар да гаҗәп хәлләр. Төрләре бер үк булган җиләк-җимешләрнең тәмнәре бөтенләй башка. Кытайда исә, гомумән алганда, тәме бик тәмле дип әйтерлек җиләк-җимеш юк. Япониядә дә, мәсәлән, роза чәчәге бик күп үсә, ләкин исе бөтенләй юк. Табигатьтәге менә мондый хәлләргә аптырамый мөмкин түгел.

Пекинда су да бик тәмле түгел, хәтта, тәмлесе бөтенләй юк дип тә әйтергә була.

Шәһәр бөтен яктан яп-ялангач тигезлек белән әйләндерелеп алынган. Кызыксынып карап йөрердәй җирләр шәһәрнең эчендә дә, тышында да юк. Бердәнбер урын – Кытай диварларының өсте дип әйтер идем. Анда да, чит ил кешеләреннән башка беркемне күрмәссең. Кайчакларда, озакка сузылган яңгырлар яуганнан соң, урамнар үтеп чыкмаслыкка әйләнә. Шул вакытта дивар өстеннән йөрүчеләр күренгәли.

Кытайларның үзләренә генә хас театрлары бар. Тик анда да, театр диярлек берни дә юк. Берничә кыз, бер өстәл тирәли утыралар да, милли уен коралларында уйнап җырлыйлар. Утыра торган җирләре ару кием-салым киеп утырырлык дәрәҗәдә түгел.

Пекинда чит ил кешеләре

Чит илләрдән килгән кешеләр Пекинда әллә ни күп түгел, чагыштырмача, хәтта бөтенләй юк дип тә әйтергә мөмкин. Чит ил кешеләре яши торган бер урам булса да, монда да шул зур дәүләтләрнең илчеләре генә яши. Алардан тыш, өч банк, ике кибет, бер даруханә бар. Ике почтаханә эшли: берсе – русларныкы, икенчесе – японнарныкы. Тагын әле бер кунакханә, ике монастырь бар. Пекин урамнарында берничә чит ил сәүдәгәре күренсә дә, күзгә ташланырлык кибетләре унга йә тулыр, йә юк. Аннары тагын үткән-сүткән берничә сәүдәгәр булуы мөмкин. Театрлар да бик килми икән. Иң еш килүчеләр ат җамбазлары[1], ди. Мин анда вакытта да ике җирдә уеннарын күрсәтәләр иде.

Әйе, кабат чит ил кешеләре турында сүзебезне дәвам итсәк, японнарның бик күп булуын әйтергә кирәк. Сәүдәгәрләрнең иң күбе – шулар. Боларның берничә кунакханәсе, берничә ашханәсе һәм банклары бар.

Пекинда гына түгел, бөтен Кытай илендә дә чит ил кешеләренә эш күп түгел, чөнки кытайлар үз гадәтләренә бик нык бәйле милләт: киемнәрен баш-

[1] Ат җамбазлары – атларны өйрәтеп, цирк уеннары күрсәтүче артистлар *(тәрҗ.иск.)*.

ка милләтнекенә алыштырмыйлар, тукымаларын үзләре җитештерәләр. Кытайлар куллана торган ни бар – барысы да үз маллары, шул сәбәпле, чит малга ихтыяҗлары да чыпчык тезеннән генә. Кытайлар җитештергән малның сыйфаты белән бер генә чит ил малы да ярыша алмый, чөнки маллары бик нык, бик сыйфатлы һәм бер генә кытай кешесе дә чит ил малы белән кызыксынмый. Бу яклары белән кытайлар японнардан да ныграк милләт. Әлбәттә, читтән берни дә килми дип әйтеп булмый, алар шактый, ләкин яшәү өчен зарури нәрсәләр түгел. Бик күп исерткеч эчемлек килә, күкертле шырпы һәм кәгазь, шикәр килә. Тик болар һич кенә дә «болар булмаса, булмый» төреннән түгел.

Илдә чит ил кешеләренең аз булуы менә шул югарыда күрсәтелгән сәбәпләргә бәйледер дип уйлыйм. Алда да әйтеп үткән идем: һинд кешеләренең күплеге күзгә чалына. Тик аларның булуы да инглизләрнең сәяси мәнфәгатьләре аркасында гына. Болар башкалар бөтенләй аз булганга гына күп булып күренәләр, мөгаен. Ник дигәндә, Истанбулда, Мисырда, Сириядә мыжлап торган чит ил кешеләре белән аларны чагыштырырлык та түгел. Бу яклардан чыгып уйлаганда, Пекинда чит ил кешеләренең йогынтысы булса да, шул саннары нисбәтендә генә булыр.

Пекинда минем вазыйфам

Минем биредәге вазыйфам турында 424 нче биттә[2] бераз әйтелгән иде инде. Килгәннән бирле, мин гел шул вазыйфам белән мәшгуль, бөтен эшләрем шуңа юнәлдерелгән. Тик башта максатны аңлатып бирергә кирәк әле, ә аның өчен тиешле кешеләрне эзләп табарга туры килә. Хәл шундый: кытайларның японнарга карата бигрәк тә дошманлык күрсәтүләрен сизеп торам. Бөтен җирдә япон малларына каршы бойкотлар игълан ителә. Шундый вакытта ничек итеп максатны аңлатасың? Кемгә сөйләп аңлата аласың? Менә шуларга чара эзләп, атналар үтте. Ниһаять, тагын да шул ук без җаһил, яраксыз дип кимсеткән муллаларның ярдәме белән, һәр атна мәчетләрдә вәгазьләр сөйли-сөйли, эшне бераз юлга сала алдык. Моннан тыш, Пекинда иң могтабәр «Ай-Ку-Бав» газетасында «Шәрык – шәрык кешеләре өчен» дигән бер мәкалә дә бастырдым. Бу мәкаләнең тәэсире искиткеч зур булды. Биредә хөрмәтле укучыларымның игътибарына әлеге мәкаләнең кыскача эчтәлеген тәкъдим итәргә телим.

Шәрык – шәрык кешеләре өчен

«Элек-электән кешеләргә дә, гомумән алганда, хайваннарга да хас булган бер табигать кануны яшәп килә: һәр җан иясе үз оясында үзен һәм гаиләсен яшәтә. Адәм угылларының намус әһеле булганнары бар да үзенең һәм гаиләсенең ризыгын үз йортында булдыра. Намус әһеле һичбер вакыт күршесенең йортына кул сузмый. Бөтен дөньядагы хокук һәм канун галимнәренең уртак фикеренчә, һәркем үз гаиләсен үз йортында тәрбия кылырга тиеш. Берәүнең дә хокукына, намусына, гыйффәтенә кул сузмаска тиеш. Кем генә булса да, әгәр берәр кеше башка кешенең малына кул суза, көндезме, төнләме, башка берәүнең чик сызыгына һөҗүм итә икән, шул мизгелдә үк бөтен җиһан кануны ул кеше турын-

[2] Бу – китапның госманлы-төрек телендә басылган басмасындагы бит саны *(тәрж.иск.)*.

да «карак» дигән хөкем чыгара, җәзасын да билгели. Бу – гаделлек кануны һәм төп канун һичбер вакыт үзгәрмәячәк. Әгәр бөтен дөнья галимнәре карашында могтабәр саналып кабул ителгән бер канун булса, ул менә шушы канун инде. Карак һәр җирдә, һәркайда карак булып санала.

Инде килеп, бүген һәркем күзләрен ачып, бик игътибар белән тирә-юненә караса, хәйран калачак. Бүгенге көндә безнең Шәрык йортыбыз Аурупа халыкларының һөҗүменә дучар булган хәлдә. Караклар йортыбызга басып кергәннәр, малыбызны шудыралар, ә безнең хәбәребез юк. Инде йөзләрчә ел буе үз яшәешләрен, кәеф-сафаларын гел безнең мәмләкәтләребездән тәэмин итәләр. Болар дөньяда никадәр эшкә ярамаган, буш, файдасыз нәрсә булса, барысын да үз мәмләкәтләреннән безгә китерәләр, безнең җаһиллегебездән, гафләтебездән, көчсезлегебездән файдаланып, кулларыбызга тоттыралар. Аннары, мал-мөлкәтебезнең, җитештергән нәрсәләребезнең кайсысына күзләре төшсә, шуны алып китәләр. Ул гына да җитми, гаскәр белән, туп, мылтык белән килеп, аталар, ваталар, җимерәләр, яндыралар. Йөз меңнәрчә Ватан баласын ал каннарга батыралар да, без сезне җиңдек, дип, сугыш компенсациясе таләп итәләр. Әйтерсең, без аларны чакырып китергән. Алар белән без сугышкан кебек итеп хөкем чыгаралар да, безне Кыямәткә кадәр түләп бетергесез бурычларга күмеп куялар. Мәмләкәтебезне талыйлар, бар нәрсәбезне сыпырып алып китәләр. Безгә үз йортыбызда үзебез өчен табыш алу мөмкинлеген дә калдырмыйлар. Бөтен Азиядәге милләтләрне инде йөзләрчә еллар буе канлы яшь түгәргә, Кыямәт көненә кадәр әсирлектә яшәргә мәҗбүр итәләр.

Бүген Һиндстан нинди хәлдә, Төркестан нинди хәлдә? Боларны игътибарга алып, бөтен Шәрыкнең киләчәген күз алдына китерергә теләсәк, дөрес фикер йөртергә һәм шуны белергә тиешбез: шундый бер көн киләчәк ки, бөтен Көнчыгыш милләтләре Көнбатыш милләтләренә әсир төшеп изеләчәк, безнең яшәешебез бары тик аларның кәеф-сафасы һәм рәхәте өчен булачак. Бүген руслар Төркестанны йоттылар, аннары Монголияне йотачаклар, Кытай Төркестаны – русларның бердәнбер максаты. Тибетны инглизләр басып алачак, Тонкин[3] исә французларга мал булачак. Болар инде бар да карталар өстендә бүлгәләнеп беткән. Якын Көнчыгыш һәм Иран да бүлгәләнгән. Боларның барысы буенча да инде фикри карар кабул ителгән, тормышка ашыру өчен форсат кына көтәләр.

Көнбатыш сәясәтенең бөтен максаты – Көнчыгыш халыкларын кулланып, үз хәят чишмәләрен җанлы тоту. Болар башта һәр мәмләкәттә гаделлек дип сүз куерталар, аннары безнең Шәрык халыкларын мәҗбүрилиләр, максатларына ирешеп, әсирлеккә төшерә алсалар, гаделлек турында авыз ачып сүз әйтмәс булалар, кешелеклелек дигәннең үзе түгел, исеме дә калмый. 1900 елда Благовещенскида гөнаһсыз кытайларны Амур елгасына батырдылар, кыз һәм ир балаларны, хәтта корсагындагы балалары белән авырлы хатыннарны, күкрәкләренә кыскан имчәк балалары белән бергә яшь аналарны, төркем-төркем Амур елгасына ташладылар. Амур елгасында өч километрлык ара мәетләрдән күпер хәленә килгән иде. Боларны үз күзләребез белән күрдек һәм, һичшиксез, әле тагын мондый вәхшәтләрне күрәчәкбез. Без күрмәсәк, балаларыбыз күрәчәк. Без хәзердән үк боларны яхшы белергә, мондый һәлакәтләрдән саклану чараларын уйлап табарга тиеш. Бер көн килеп, сары ыруның көлен күккә очырулары мөмкин. Боларның планнары күптән төзелгән. Аз гына булса да фикерләүгә ия

[3] Тонкин – Вьетнамның төньяк районнарына Аурупа халыклары биргән атама; 1884-1945 нче еллар арасында француз протекторатының атамасы *(тәрҗ.иск.)*.

булганнар бу хакта уйлансалар, күзләре белән күргәндәй аңлап шаһит булырлар иде. Шулай булгач, бөтен Көнчыгыш милләтләре – без – үз яшәешебезне үзебез генә саклый алачакбыз. Көнбатыш халыклары безгә бервакытта да мәрхәмәт күрсәтмәячәк, бары тик без үзебез генә мәрхәмәт күрсәтә алачакбыз. Мәнфәгатебез өчен кирәкле чараларны да янә без үзебез таба алачакбыз, ул бердәнбер чара – безнең үз кулыбызда. Бу – дошманнарыбыз безгә каршы кулланган чаралардан гыйбарәт. Дошманнарыбыз безгә каршы берләшкәннәр: Көнчыгышта берәр хәл килеп чыкса, шунда ук бергәләшеп эш йөртә башлыйлар. Бер йодрык булып берләшәләр. Безгә дә, һичьюгы, дошманнарыбыз кадәр генә булса да берләшергә, хокукларыбызны яклый алырлык бердәмлек килешүе төзергә кирәк. Безнең яшәешебез өчен бердәнбер чара бу, башка чара юк. Шәрыкнең яшәеше Шәрык милләтләренең бердәмлеге белән генә тәэмин ителә ала, башкача була алмый.

Бүген Көнчыгыштан туган кояш – Нихон (япон) милләте – моннан илле еллар элек, 300дән артык әмирлек хәлендә яшәп ятканда, аңа Корея халкы тарафыннан куркыныч яный иде. Кулга-кул тотынышып берләшкәннән соң исә, японнар, дөньяның иң зур дәүләтләренең берсе булган Русияне җиңеп, Кореяда, Маньчжуриядә ныгыдылар, үз мәмләкәтләрен чит дәүләтләрнең борчып торуыннан коткардылар. Бу хәл кечкенә генә милләтнең үзара бердәм хәрәкәт итүе аркасында гына барлыкка килде. Японнар Көнчыгышның иң кечкенә кавеме булган кебек, иң кечкенә бер өлеше дә.

Көнчыгышның бердәмлеге мәсьәләсе, Көнчыгышның яшәеше өчен генә түгел, Көнбатышның яшәеше өчен дә бик мөһим. Ник дигәндә, әгәр Көнбатышның бүгенге кебек ташланулары дәвам итсә, бер көн килеп, бу хәл бөтен Көнчыгышны аякка бастырачак. Ә моның нәтиҗәсенең «Кызыл тәре» вакыйгасыннан[4] да куркынычрак булуы мөмкин. Шулай булгач, Көнчыгышның бердәмлеге Көнбатышның яшәешен дә тәэмин итәчәк, чөнки Көнбатышның һөҗүмнәре өчен урын калдырмаячак.

Көнчыгыш милләтләренең берләшүенең канунын һәм планын вакыт үзе хәзерләячәк».

Менә шундый мәкалә «Ай-Ку-Бав» газетасының 12 июль санында басылып чыкты. Мин биредә, хөрмәтле укучыларым, мәкаләнең кыскача эчтәлеген бирдем. Барысын да бирсәк, язма артык озын булачак, чөнки мәкаләдә берләшүнең планы да бар иде. Бу мәкаләнең тәэсире бары тик кытайлар белән генә чикләнеп калмады. Агентлыклар да активлык күрсәтте, мәкалә хакында хәбәр итеп, телеграммалар җибәргән булып чыктылар. Шул рәвешле, мәкалә Аурупа җәмгыятьләрендә дә яңгыраш тапты.

Бу вакыйга турында Пекиннан Токиога да кытай телендә бер телеграмма җибәрелгән. Аның эчтәлеге мондый:

«Русияле хөрриятпәрвәр Ибраһим бу көннәрдә Пекинда. Бүген «Ай-Ку-Бав» газетасында бер мәкалә бастырды. Бөтен Көнчыгыш милләтләрен берләшергә чакыра. Русия баш илчесенең бу мәкаләгә бик хәтере калган. Петербургка да хәбәр җибәрелгән».

Бу телеграмма Токио газеталарының барысында да басылган. Иртәгәсе көнне миңа Токиодан кисәтү эчтәлекле бер телеграмма килде, анда: *«Сак булыгыз, күзәтү астына алыначаксыз икән»,* – кебек сүзләр язылган иде.

[4] Бу атаманың биредә XI-XIII гасырларда булган Тәре сәфәрләре (походлары) мәгънәсендә ялгыш кулланылган булуы мөмкин *(тәрҗ.иск.).*

Тик мин, әлхәмдүлилләһ, вазыйфамны башкардым, бер дә исем китмәде, гел йөреп тордым, Пекинда булганда, шәхси дәресләр бирү белән дә шөгыльләндем.

Пекинда Һиндстан мөселманы

Беркөнне Пекинда Нуҗе мәдрәсәсендә утыра идем. Җомга көн. Янымда берничә шәкерт тә бар иде. Аурупача киенгән бер кеше килеп керде. Сәламүнгаләйкүмнән соң: *«Һәл фикум мән йагләму лисанел-араб [Арагызда гарәпчә сөйләшүче бармы?]»,* – диде. Карыйм, гади генә бер кеше, янында кытай милләтеннән бер хезмәтчесе дә бар. Танышканнан соң, арабызда якынлык хасил булды. Бу әфәнденең, башта гыйлем әһеле булып, ул юлны ташлаганнан соң, сәүдә эшенә кереп киткән бер мөхтәрәм шәхес булуы аңлашылды. Исеме Мөхәммәд Ханиф икән. Бераз хәл-әхвәл сорашканнан соң, җомга намазы кылырга дип, бергә мәчеткә кердек.

Гадәттә, Кытай мәчетләрендә шәкертләр, бер түгәрәккә җыелып, намаз алдыннан «Кәһф» сүрәсен[5] укыйлар. Бу юлы да, без килгәндә, «Кәһф» сүрәсен укыйлар иде. Мөхәммәд Ханиф әфәнденең Кытай мәчетенә беренче керүе икән. Бик аптырап тыңлап торганнан соң, миннән:

– Әйтегезче, болар нәрсә укыйлар? – дип сорады.

– «Кәһф» сүрәсе, – дидем.

– Булмас, мин «Кәһф» сүрәсен яттан беләм. Монда мин бер сүзне дә аңламадым, – дисә дә, мин дәшми каласы иттем.

Намаз кылганнан соң, Мөхәммәд Ханиф әфәнде кабат минем бүлмәмә килде һәм миңа һөҗүм иткәндәй:

– Аллаһыны танысаң, бу нинди хөтбә бу? Бу нинди «Кәһф» сүрәсе? Бу нинди Коръән уку? Аллаһ сакласын, Сез биредә нәрсәгә? Боларны күрә торып ничек сабыр итәсез, түзәсез? – диде.

Бераз дәшми торгач, мин болай дип җавап бирдем:

– Туганым, мине кем дип уйладыгыз? Мин дә Сезнең кебек үк бер юлаучы. Чит-ят берәүнең кулыннан ни килсен? Гомумән алганда да, безнең мөселманнар исламияттән һаман да ерагая баралар. Тик һәрберебез, үз кимчелек-хатабызны күрмибез дә, алдыбызда торган дус-ишкә һөҗүм итәбез. Шәригатьнең ысул һәм кагыйдәләрен дә белмибез. Сез бу аурупалылар киемен ник кидегез? Һиндстан голәмәсе шундый кием киямени? – дип, мин дә аңа бераз һөҗүм итеп алдым. Шул рәвешле, мөнәсәбәтебездә тагын да самимилек хасил булды. Соңыннан бу кеше миңа күптәнге дус булып күренә башлады. Мөхәммәд Ханиф әфәнденең энесе дә Пекинда инглизләр илчелегендә баш тәрҗемәче булып хезмәт итә икән. Аның белән дә күрешеп, бераз мәгълүмат алдым. Мөхәммәд Рәфик Сахиб инде унике ел Пекинда яши икән. Инглиз мәктәпләрендә укыган, кытай телен дә гаҗәеп дәрәҗәдә яхшы белә, сәясәт өлкәсендә дә белемле иде.

Бу кеше ярдәмендә мин шактый кеше белән таныштым, күрешеп сөйләштем.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

[5] Коръән-е Кәримнең унсигезенче сүрәсе. «Әсхаб-е Кәһф» (мәгарәдә 300 ел йоклаган җиде җан иясе) кыйссасы турында сүз барганга шулай аталган *(тәрҗ.иск.)*.

2022 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1443-1444 ҺИҖРИ ЕЛЛАР

2 февраль – мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим (г.с.) пәйгамбәрнең, Гайсә (г.с.) пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

3 февраль – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

27 февраль – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете (көрсие) янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

17 март – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышларын билгели.

2 апрель – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә – Кадер кичәсе.

2, 3, 4 май – Гайдел-фитыр, Ураза бәйрәме.

21 май – Идел Болгарстанында ислам дине рәсми рәвештә кабул ителүгә 1100 ел (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

8 июль – Гарәфә көне.
Мөбарәк вә фазыйләтле 10 кичәнең ахыргы кичәсе.

Гарәфә кыяме яки хаҗиларның Гарәфә тавы тирә-юнендә торып гамәл-гыйбадәт башкару көне. Һәр фарыз намаздан соң Тәшрикъ тәкбирләре әйтеләчәк, иншәАллаһ.

9 июль – Мөбарәк Гыйд әл-Әдъхә яки Корбан гаете. Мөселманнарның иң зур бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

8, 9, 10, 11, 12 июль – Тәшрикъ көннәре. Әлеге көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап, махсус сүзләр әйтәләр.

30 июль – Һиҗри Яңа ел. **1444** һиҗри елның вә Мөхәррәм әл-Хәрам аеның беренче көне.

Яңа елыбызда дөнья вә ахыйрәт бәхет-сәгадәтенә алып бара, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кылырга насыйп булсын! Бу көнне Аллаһының ризалыгы өчен догалар, изге эш-гамәлләр кылып, хәер-садака биреп үткәрергә кирәк.

7 август – мөбарәк Гашура кичәсе.

8 август – мөбарәк Гашура көне. Мөхәррәм әл-хәрам аеның 10 нчы көнендә Гашура бәйрәме билгеләп үтелә. Бу көннең фазыйләтләре һәм хикмәтләре бихисап. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) болай дигән: «Ибраһим галәйһиссәлам Гашура көнендә тугандыр. Аллаһы Тәгалә аны Нәмрудның утыннан Гашура көнне коткаргандыр, юлның тугрысын да Гашура көнендә күрсәткәндер».

6 октябрь – Мәүлед-шәриф кичәсе.

7 октябрь – Мәүлед бәйрәме – пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган көн. Ул мөселман дөньясында зурлап билгеләп үтелә.

Төзүче-мөхәррир – хаҗи ***Абдулла Дубин*** ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

Тәтешнең вәкарьле ишаны

Ильяс Җиһаншин

Ишан бабай кабере

Сиддикия, нәкышбәндия, ясәвия...

Татарларда, мәгълүм булганча, нәкышбәндия тәрикате киң таралган булган. Аллаһының рәсүле пәйгамбәребез (с.г.в.): *«Аллаһы Тәгалә сезләрне тышкы кыяфәтегезгә яки мал-дәүләтегезгә түгел, бәлки, йөрәкләрегезгә вә эшләрегезгә карап бәялидер»,* – дип әйткән. Ошбу хәдис шәрифкә муафыйк булып, нәкышбәндия тәрикате йөрәкләрне пакьләүгә, кешеләрне камиллеккә җиткерүгә юнәлгәндер. Нәкышбәндия тәрикатенең силсиләсе хәзрәти

Әбү Бәкер Сиддыйк (р.г.) аркылы пәйгамбәребезгә (с.г.в.) барып тоташа. Шуңа элек ул «сиддикия» дип аталган. Соңра нәкышбәндия тәрикатенең мәшаехләреннән берсе булган хәзрәти Сәет Мөхәммәд Бәһауддин Нәкышбәнд Бохари (1318-1389) исеме белән «Нәкышбәндия тәрикате» дип атала башлый. Безнең төбәктәге ислам тарихы турыдан-туры суфичылык белән бәйле. Мөселманнар бер Аллаһыга булган ихлас иманнарын күп очракта пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) рухи дәвамчылары аша кабул иткән һәм саклап калган.

> **«Репрессия елларында ишан хәзрәтләрен кулга алырга килгәч, аларның могҗизалы рәвештә күз алдында юкка чыкканлыкларын әле дә риваять итеп сөйлиләр.**

Тәсаввуф, тәрикат әһелләренең Идел буенда бик күптәннән килгән тарихи үзенчәлекләре бар. Идел буе Болгар дәүләтендә суфичылыкның төгәл кайчан барлыкка килүе турында әйтүе кыен. Шунысы бәхәссез: XII гасырда болгарлар арасында ясәвия тәрикате (Хуҗа Әхмәд Ясәви) тарала башлый. Шуннан башлап суфилар татарлар арасында ислам динен таратуга зур өлеш керткән.

Могҗизалы рәвештә юкка чыгу

Тау ягы – Җәбәли төбәгендә дә тәрикат юнәлеше нигезле була. Суфичылык Кама Тамагы, Тәтеш, Кайбыч, Апас, Буа һәм Чүпрәле районнары авылларында киң тарала. Биредә изге кешеләр күп булган. 100-200 ел элек яшәгән мәшһүрләребездән Буа ишаннары Габделвахид хәзрәт Габдерахман, Габденнасыйр хәзрәт Мөхәммәтәмин, Нургали хәзрәт Хәсән, Габдулла хәзрәт Гобәйдуллин; Норлат имамы Фәхретдин ишан Мостаев; Үгез Куагы авылыннан хаҗи Мөхәммәд Габделкасыйм; Суыксу (Суксу) авылыннан Шәрәфетдин ишан Суксуви; Олы Тархан авылыннан Нуреддин ишан Мостаев; Карлыдан Гобәйдулла ишан Рәхмәтуллин; Толымбайдан Әхмәр ишан Юнысов һәм башкаларны әйтә алабыз.

Тәрикат тәрбиясе халкыбыз өчен гыйлем, камил әдәп-әхлак өчен гаять файдалы була. Россия империясе татарларга рухи басым ясаган вакытта, ишанлык системасы милләтне бердәм итеп туплап торган. Ишан хәзрәтләре белән рухи береккәнлек, аның күркәм шәхси үрнәген һәркөн күреп-тоеп яшәү һәм аның белән даими әңгәмә корып, аралышып тору халыкка бик зур мәгънәви тәэсир ясаган. Алар чын мәгънәсендә галим һәм остаз булган. Шул ук вакытта гади тормышта яшәгән ишаннар үзләренең мөридләренә, ягъни аңа ияручеләргә һәм тирә-як халкына «әүлия», изге кеше булып күренгәннәр. Андый затларның даны тиз арада еракларга таралган. Ишаннарның хәер-фатихасына ирешергә, алар җитәкчелегендә хезмәт кылырга, алардан тәрбия һәм гыйлем алырга теләп, күпсанлы шәкертләр килгән. Өшкертергә, дәва-шифасын алырга дип тә янына авыру-хасталар җыелган.

Халыкның шәех-ишаннарга мәхәббәт-хөрмәте XVIII гасыр-XX гасыр башы татар поэзиясендә, мәдхия һәм мәрсияләрдә чагылыш таба. Әбибабайларыбызның ишан хәзрәтләрдән өйрәнеп әйткән зикер-догалары, гыйбрәтле сүзләре балачактан ук колакка кереп калган. Репрессия елларында

ишан хәзрәтләрен кулга алырга килгәч, аларның могҗизалы рәвештә күз алдында юкка чыкканлыкларын әле дә риваять итеп сөйлиләр.

«Гыйлемнән ләззәтләнәдер иде»

Шундый могътабәр затларның берсе Тәтеш төбәге белән тыгыз бәйләнгән. Аның каберен төрле җирләрдән килеп зиярәт итәләр. Безнең мәдрәсә мөгаллиме Хәйдәр хәзрәт Койрыков, «хәзрәт бабай»ның кылган гыйбрәтле гамәлләрен Олы Тархан һәм тирә-як авыллары халкы әле дә олылап сөйли, ди. Сүзебез Нуреддин бине Мифтахеддин бине Мостай турында. Аның хакында Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин: *«Сембер нахиясе (өязе) Олуг Тархан авылында имам булып, 75 яшендә 1319 (1901) ел, 6 җөмадиел-ахирда (5 сентябрьдә) вафат булды вә шул көндә дәфен ителде (җирләнде). Җеназасын Буаның мөдәррисе Нургали бине Хәсән укыды.*

Асыл ватаны Тәтеш нахиясендәге Тутай карьясы (авылы) булып, мәзкүр карьяда 1246/1830 тарихында дөньяга килгән иде. Тарханда 39 ел имамлык хезмәтендә булды. Казанда Мөхәммәдкәрим хозурында укып, хәтме дәрес кылганнан соң, Саляхеддин бине Исхак дәресләренә кермәгән. Шиһабеддин бине Хисамеддин әл-Әснәдән тәрикаттә мәэзүн булып (ишанлыкка рөхсәт алган), мөрид тәрбия кылу берлә мәшгуль булган Шәрәфелислам исемле углы үз урынында имамдыр.

Көтепханәсендә китабы күп, үзе дә моталәгә (укуга) һәвәсле иде, ифадә (аңлату) вә истифадәдән (гыйлемнән файда күреп) ләззәтләнәдер иде, сабырлы вә вәкарьле бер зат иде», – дип яза.

Мәрҗани, Барудилар да тәрикат әһелләре

Хәзерге көндә суфичылык-ишанлык әкрен генә яңадан күтәрелеп килә. Элекке ишаннарга да хөрмәт вә игътибар артты. Мәшһүрләребез Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани, Галимҗан хәзрәт Барудиның тәрикат әһелләре *(суфи, ишан)* икәнлеге билгеле булды. Немец галиме Михаэль Кемпер Шиһабетдин Мәрҗани иҗазәтне *(ягъни ишан, суфи, тәрикат вәкиле булуга хокук кәгазен. – Ред.)* Ниязколый Төрекмәнинең улы Гобәйдулла бине Ниязколыйдан (1852 елда вафат) алганлыгын язып чыкты. Безнең 10 нчы мәхәллә мәчетебезнең икенче имамы Мөхәммәт хәзрәт Мортазин да иҗазәтне Бохарада Ниязколый Төрекмәнидән алган.

Бүгенге галимнәребез дә ишанлыкны бик югары бәяли. Әлеге изге затлар хакында китаплар языла, каберләрен даими зиярәт итәбез. Ульяновск өлкәсенең Кулаткы районында, Чистайда, Буа районының Толымбай авылында, Түбән Новгород өлкәсендә һәм татарлар яшәгән башка төбәкләрдә аларга багышланган укулар уздырыла. Татар суфиларының силсиләләрен, ягъни силсиләнамәне – тәрикатнең рухи шәҗәрәсен тасвирлап биргән тарихи әсәрләрне өйрәнү эше башланды. Милләттәшләребез яшәгән һәр төбәктә шундый шәхесләрне ачыклау, аларның хезмәтләрен барлау күп көч һәм хәзерлекле галимнәрне сорый. Раббыбыз бу эшләрдә безгә уңайлык, зиһен ачкычлары бирсен иде! ■

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре*

Әхмәдвәли Рәхими

7

Габдулла бине Гомәр разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Олуг гөнаһлар: Аллаһка ширек кылу (тиңдәш тоту), ата-ананы рәнҗетү, кеше үтерү, белә торып ялганга ант итү (шаһитлык бирү)».

Укы һәм исеңдә калдыр!

8

Әбү Һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Монафыйкның галәмәте (сыйфаты) өчтер: ялган сөйләү, вәгъдәдә тормау, әманәткә хыянәт итү».

Укы һәм исеңдә калдыр!

9

Әнәс разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Шайтан адәмгә каны йөргән кебек белдерми вәсвәсә кылыр».

Укы һәм исеңдә калдыр!

10

Гайшә анабыз разыйаллаһу ганһә риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Кем безнең дини әмеребезгә диндә булмаганны кертсә, ул нәрсә кире кагылачак».

Укы һәм исеңдә калдыр!

11

Ибн Габбас разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Аллаһы Тәгалә өч кешегә бик ачулы: әл-Харамда гөнаһ кылучы; исламда җаһилият (мәҗүсилек) гадәтен торгызучы; мөселман канын хаксыз урында (җирдә) түгәргә таләп итүче».

Укы һәм исеңдә калдыр!

12

Әбү Һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Җәннәткә керүдән тартынган кешедән кала, бөтен өммәтем җәннәткә керер. Кем миңа буйсынды, җәннәткә керер. Кем миңа буйсынмады, шиксез, ул (җәннәткә керүдән) тартынды». ■

*Текстны басмага **Айсылу Вәлиева** әзерләде.* ■

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

*Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Җиденче дәрес

Кыямәт көне. Хәшер (җыелу) вә бәгыс (терелү). Җәннәт. Җәһәннәм

Мөгаллим: Без үлгәч тәннәребез нишли дигән идек?
Шәкерт: Череп туфрак була, дигән идек.
Мөгаллим: Ә җаннарыбыз нишли дигән идек?
Шәкерт: Җаннарыбыз бер дә бетми, мәңге кала, дигән идек.
Мөгаллим: Шулай шул. Җан ул мәңге кала, бер дә бетми. Әмма безнең җаннарыбыз да гомер буе шул көенчә калмый. Бервакыт ул әүвәлдәгечә үзебезнең тәннәребезгә килеп керә һәм без яңадан әүвәлге кебек адәмнәр булып китәбез. Беләсезме, ул эш кайчан булачак?
Шәкерт: Кайчан?
Мөгаллим: Әлбәттә, белмисез. Мин сезгә хәзер шул хакта сөйлим. Бу дөнья мәңге калмаячак. Аллаһы Тәгалә аны бервакыт харап кылачак. Шулвакыт җир вә күкләрдәге безгә күренгән вә күренмәгән бөтен мәхлуклар һәлак булачаклар, үләчәкләр. Җирләр, күкләр тар-мар кылыначак. Таулар йон кебек тетелеп бетәчәк. Нәтиҗәдә, дөнья бөтенләй бер хәрабәгә әйләнәчәк, һичбер җан иясе калмаячак. Ялгыз Аллаһы Тәгалә генә калачак. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә бөтенләй икенче бер галәм торгызып, җан ияләренең барысын да яңадан терелтәчәк. Без дә шулвакыт әүвәлдәге, дөньядагыча кешеләр булачакбыз. Әнә шул хәзерге дөнья җимерелеп, харап булып, икенче бер галәм торгызылуга Кыямәт көне (Ахирәт көне) диләр. Дөнья харап булган чакта үлгән һәм аннан әллә ничә мең еллар элек вафат булган кешеләрнең җаннары яңадан тәннәренә кайтуга, ягъни терелеп әүвәлдәгечә кеше булуларына «бәгыс» диләр. Димәк, «бәгыс» үлгәннән соң яңадан терелү дигән сүз була икән.

Кыямәт көне гаять дәрәҗәдә куркыныч, дәһшәтле көн була. Ул вакытта һәркем куркуда, тетрәүдә, һәркемнең исендә үзенең киләчәге булачак. Һәркем: «Йә, Раббым, миңа ни булыр икән?!» – дип, кайгы-хәсрәттә, уй вә фикердә, һәркемнең үз кайгысы кайгы булачак. Ата-ана, угыл-кыз, дус-иш ул көндә бөтенләй хәтерләрдән чыгачак. Ул вакытта ялгыз үз башыңны гына кайгыртачаксың.

Менә шуннан соң халыкларның дөньяда вакытта эшләнгән (кылынган) эшләрен тикшерү булачак. Алар Аллаһы Тәгалә кушканча яшәгәннәрме, Аның боерыгыннан чыкмаганнармы? Изге гамәл кылганнармы? Әллә Аллаһы Тәгаләнең боерыгыннан чыгып, гөнаһка батканнармы? Ул көндә инде һәркемнең ни кылганлыклары – барысы да билгеле була. Аларның барысы да синең күз алдыңа килә. Ул вакытта инде бернәрсәне дә яшереп булмый. Шул хисап көненнән соң, халыклар төрле сыйныфларга аерылачаклар. Дөньяда изге гамәл кылган кешеләргә Аллаһы Тәгалә әҗер

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

Тәтештәге рус-татар мәктәбе укучылары. 1907-1908 нче еллар

вә савап бирәчәк. Алар мәңгегә рәхәттә калачаклар. Аллаһы Тәгалә аларны җәннәт (оҗмах) дип аталган урынга урнаштырачак. Анда сиңа ни кирәк – барысы да табылачак, ни телисең – барысы да хазир булачак.

Ә дөньяда явызлык, гөнаһ кылган кешеләр мәңге авырлыкта, мәңге кыенлыкта калачаклар. Аллаһы Тәгалә аларны газапка дучар итәчәк, ут газабы, икенче төрле әйтсәк, җәһәннәм газабы белән газаплаячак. Әлеге иблис вә шайтаннар да тәкәбберләнеп Аллаһы Тәгаләгә каршы килүләренең, гөнаһка батуларының җәзасын шулвакыт кичерәчәк. Җәһәннәм газабы гаять дәрәҗәдә каты булачак. Анда «аһ-ваһ» тавышлары яңгырап торачак.

Менә, шәкертләр, әле сез бик кечкенә балаларсыз, сез бервакыт, үсеп, егет, аннары ир уртасы булачаксыз, картаячаксыз. Сезгә һәрвакыт шул Аллаһы Тәгалә кушканча йөрергә, Аның боерганыннан чыкмаска тырышырга кирәк. Әлеге куркынычлы Кыямәт көнендә йөзләребез ак, күңелләребез шат булсын өчен хәзердән үк тырышлык кую сорала. Җәннәт әһеленнән, җәннәт рәхәтенә тап булырга, җәннәт затлары, җәннәт нигъмә тләре белән нигъмәтләнергә тырышырга кирәк. Ахирәт көнендә йөзләребез кара, күңелләребез боек, кайгылы-хәсрәтле, җәһәннәм газабына дучар булудан бик нык саклану тиеш. Шулайдыр бит, балалар?

Шәкертләр: Шулай, мөгаллим әфәнде, шулай.

Мөгаллим: Менә сезнең ата-аналарыгыз, мөгаллимнәрегез сезне гел яхшылыкка өндиләр. Алар сезне хәзердән үк яхшы юлга салып, киләчәктә дә, үскәч тә шулай яхшы юлдан баруыгызны өмет итәләр. Шулай итеп, сезнең Ахирәт көнендә дә бәхетле-сәгадәтле, җәннәтле булуыгызны телиләр. Алар хәзердән карышып, яман юлга кереп, үскәч тә шулай булып китүегездән куркалар. Ахирәт көнендә җәһәннәм газабына дучар булмасын иде бу дип тырышалар.

Текстны басмага ***Мәдинә Әбделганиева*** *әзерләде* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТАТАР КИТАБЫ

Совет Русиясендә кунакта[1]

Хәсән Хәмидулла

Хәсән Хәмидулла

Ахыры. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

[1] «Милли юл» журналы (Берлин. – 1929. – №9-11. – 13 б.; – №10. – 10-12 б., 11-13 б.).

Совет Русиясенә барып килү өчен хәзерге заманда виза алу гаять читен булганга, төрек паспортыма транзит визасы алыб, төнге экспресс поезды берлә Һелсингфорсдан (Хельсинкидан. – Х.М.) Ленинградка хәрәкәт итдем. Утырган вагоным турыдан-туры Ленинградка кадәр барганга, күченү кебек эшләр юк иде. Иртә торыб, киенеб каһвә эчкәч дә, әллә нинди сагышларга батыб, куркуымдан калтыранырга вә өшергә тотындым. Чөнки ходудка (чиккә. – Х.М.) ике сәгать ярымлар гына совет хөкүмәтен үтеп китү өчен генә ясалган виза берлә анда берничә көнләр калып, кире рахәт-рахәт Финляндиягә кайта белү, әлбәттә, бервакытта да мөмкин түгел бер эш иде. Ләкин башыма нинди генә бәла килсә дә, фикеремдән дүнмәскә катгый рәвештә карар кылыб, Райойукига (ходудка) килеб йитдек. Поездымыз аннан ары инде китмәгәнгә, ярым сәгатьдән соңра гына минем вагоным илә тагы 3 нче «кеше вагоны» тагылыб, безне совет йиренә, совет адәмләренә тапшырырга булганга, янган йөрәкне бастырыб актыкыгы мәртәбә финнең тәмле каһвәсен эчеб калыйм диб, пешеб-пешеб каһвә эчтем дә янә вагоныма кайтыб, дивана кеше шикелле читдән-читкә йөренә башладым. 7-8 юлчы арасында бер балалы, данияле (укымышлы; зыялы. – Х.М.) бер яшь кенә хатын илә бер рус хатыны бар иде. Ләкин аларның да агызларындан кара болыт кеби өстле-өстле чыккан тәмәке төтенләре куркуларын бик яхшы аңлата, бик ачык сиздерә иде. Поездымыз кузгалыб китде. Китүе илә безнең барыбызның да тынларыбыз китде. Юлдашларым да башларын аска салганлар, бер-беренә бер дә эндәшмиләр иде. Менә без ходудта. Тар гына агымсу. Тар гына, кыска гына күпер. Күпернең бер башында фин байрагы – ак өстендә күк тәре; ары башында совет байрагы – кызыл өстендә урак берлә чүкеч. Күпернең яртысы – фин ягы – акка буялган, яртысы – советныкы – кызылга сырланган. Поездымыз акрын гына күпергә керде. Ләкин керү илә үк туктады. Фин мәэмүрләре (хезмәткәрләре, таможня тикшерүчеләре. – Х.М.) кереб, паспортларымызны кулларымызга биреб чыгыб киттеләр. Поездымыз янә кузгалып биш адым кадәр йир китүе илә тагын туктады. Без күпернең кызыл сырлы тарафында үзебезне күреб чак кына акылдан язмадык. Шул вакыттагы калтырануларыбызны, өшүләрне, куркынуларымны каләм тәгъриф итәргә (аңлатырга. – Х.М.) мөмкин түгел. Рус юлчылар… җырлаб йибәрделәр. Поездымыз туктаб өлгерә дә алмады, вагоныбызның һәр ике очындан совет мәэмүрләре кереб… озын чикмәнләре илә идәндәге тузанларны туздыра-туздыра, паспортларымызны җыя йөрделәр. Шулар артындан ук әллә нинди күз күрмәгән шинельләр, әллә нинди күн өстендә кызыл капалы совет түрәләре, әллә нинди күк фуражкалы гөмрүк (таможня) түрәләре кереб, әйберләрне бага башладылар. Чират минем әйберләргә йитде. Совет хөкүмәтенә советның үз акчасын чыгарырга катгыян ярамаганга, иң беренче эшләре минем кесәләремне тентү, рус акчасы эзләү булды. Ләкин андый нәрсәләрне миндә таба алмагач, әйберләремне тетдереб, бу кадәр әйберләр берлә минем ни өчен Русиягә баруымны сорый башладылар. Минем җаваб, әлбәттә, яхшы иде: «Төркиягә транзит китәм», – диб аңлаткач, СССРга бу кадәр әйберләр берлә керергә ярамавын, шул сәбәбле минем әйберләремне кулымдан алыб, кургаш берлә пичәтләб, үзләре Одессага кадәр озатачакларын, минем фәкать Одессага пароходка кергәндә генә үз әйберләремә хуҗа булачагымны сөйләделәр. Минем аш-чемодандан башкасын барын да алыб чыгыб кидтеләр. Мин исә, артларындан чыгыб, үземнең Одесса юлы берлә Төркиягә китмәвемне аңлатыб, Польша яхуд Латвия үтә китәм, фәлән, диб,

әйберләремнең мең бәла берлә Ленинградка озатырга муафикъ булдым. Багажларны инде мин анда ничек кенә булса да үз кулыма алачагыма ышаныб, куана-куана Ленинградка килеб йитдек. Әүвәлге таза вә җанлы Финляндия вокзалы хәзер андан-мондан җимерелгән; керләнгән платформалары кешесез вә җансыз. Анда-монда гына иске зибинлы (киемле. – Х.М.) руслар, шәл ябынган сәләмә, карт марҗалар, начар киенгән рус кызлары күренгәлиләр. Аш-су чемоданымны тотыб, вокзалдан тышка чыкдым. Урам тын, йортлары искергән, кайдадыр корым исе борынга керә, анда-монда котсыз, сәләмә хатын-кызлар, ямалып беткән иске киемнәрдән – ямьсез, котсыз (ир-атлар), озын шинельле солдатлар, фуражкаларына кызыл кайма таккан коммунистлар, ертык-пыртык урам балалары очрый. Җимерек, иске автомобильләр, каралып-керләнеп беткән трамвайлар анда-санда күренәләр. Як-ягыма караныб, извозчиклар эзләдем. Бер русның әйтүе буенча, вокзалның арт очына китдем. Анда алты извозчикны күрдем. Шулкадәр фәкыйрь вә сәләмә иделәр ки, тәгъриф (сөйләү, аңлату. – Х.М.) мөмкин түгел. Атлары исә коры җанлары гына булып, җоннары коелыб, түшләре тишелеб беткәнләр. Арбалары тузып эшдән чыгыб беткән. Утыргычларының өстләре әллә ничәшәр йирдән ямау салыныб, эчләрендәге саламлары, тузаннары очыб, борынга, күзгә, агызга тулалар. Көпчәкләре исә тышка ташыб, җимерелергә торалар. Чарасыз, шуларның берсенә утырырга разый булыб, барачак йиремә күпме алачакларын сорадым. «5 сум», – диде. Башкалары аны ишетеб, берсендән-берсе бәһаны азайтыб, ахырда бер сумга кадәр төшергәч, көпчәкләре тазарак берсен сайлаб, утырыб китдем. Юлыбыз байтак кына озын булганга, аты да ишәкдән дә үзсүзлерәк булганга, суган сатучылар кебек атлатып бара-бара, миңа күп-күп эшләр, күп кенә күренешләр күрергә туры килде. Минем өст-башыма вә кулымдагы чемоданга кызыгыб туктаб караб калучы сәләмә халыклардан битәр, мин үзем кулларына озын-озын китаплар тоткан, озын вә күб, кыйммәтле, кызыл фуражкалы түрәләрнең мине дикъкать берлә карауларындан курка башладым. Сәгать ярымлаб барыб, урамына җиткәч кенә мин җанланыб китдем, чөнки барачак йирем дә шунда иде. Кардәшләремдә озак кына чәй эчкәч, дуст-иш арасында кичкә кадәр утыргач, куну мәсьәләсе читенләшеб китде. Мин боларның берсен дә бәлагә китермәс өчен, хөкүмәтнең үз отеле «Аурупа»га барыб куну ягында идем. Дуст-ишнең бергә сөйләшеб кич үткәрәселәре килә иде.

Иртәгәсе көн җомга иде. Мин паспортымны яздырырга китдем. Анда баргач, мине яман күз берлә каршы алдылар. «Синең төшәргә дә, кунарга да хакың юк иде. Ни өчен кундың?» – диб сораштыра башладылар. «Багажларым килмәде, аны көтеп кунарга мәҗбүр булдым», – дисәм дә, большевик кануны бик нечкә вә бик кызу йөртелгәнгә, миңа 3 сәгать эчендә Ленинградтан чыгып китәргә әмер булды. Ашыга-пошыга мәсҗедкә йөгердек. Тәмам җомга вакыты иде. Дивана кеше шикелле анда-монда бәрелеб, тәһарәтнең шартларын да йиренә йиткермичә тәһарәтләнеб, намазга керештем. Ләкин мулла, озын-озын итдереп татарча әһәмиятсез мәсьәләләрдән вәгазь сөйләп, гарәпчә хотбә укыганда да ярты юлда адашыб, ярым сәгать кадәр туктаб, теле тотлыгыб эшен алып бара алмады. Минем кебек соң гомерләренә баскан, янган йөрәкләргә күтәрә алмаслык агыр тоелса да, чарасыздан көтәргә туры килде. Намаз укылыб бетде. Халыкның сикерешеб торыр заманнарында араларындан кызыл якган фуражкалы бер та-

тар коммунисты сикереб торыб, рус телендә: «Садитель!» – диб кычкырыб, аңсыздан өркетелгән халыкның йөрәген ярды. Моның кеби фуражкалы татар коммунистларының сыйфатларын күреб дә куркудан җаннары бугазларына килгән динле кешеләр бу юлы да: «Тагын нинди бәлагә эләкдек икән», – диб, куркудан утырганы – утырганларына, торганы – торганларына (карап. – Х.М.) катыб калдылар. Фуражкалы малай, максадын аңлатыр өчен, арага берәр татарча сүз дә кыстырыб, мин аңламаган әллә нинди кыска галәмәтле рус телендә халыкны әллә нинди бер кружокка, әллә нинди собраниегә, тагын да әллә нинди бер татарской кладбище вопросын хәл кылырга собрание итүләрен әйтеб сүзенең очына чыкты. Бәла-фәлән булмаганлыкдан халыкның күңелләре урынларына урынлашып, фуражкалыга: «Спасибо», – әйтеп тарала башладылар.

Мин байтак кына Ленинградның атаклырак адәмләре берлә күрешеб чыгыб, эшемнең начарлыгын, өч сәгать эчендә Ленинградны ташлаб чыгу тиеш булуын, шул чакда миңа бер-бер ярдәм итүләрен үтендем. Ләкин бу эшкә берсенең дә акыллары ирешмәгәнгә: «Бер-бер бәлагә эләкмик», – диб, барысы да качыб бетделәр. Бер әфәнде минем тиз генә вакытда Финляндиягә чыгыб котылуымны киңәш итде. Кардәш ыругларым да шул әфәнденең фикерен куәтләделәр. Мин төрле азаблар берлә барыб да аягымны басар-басмас ук бер көн эчендә кире кайтуны һич теләмим. Багажларымны да большевикларга калдырыб китүне уйлаб да карамый идем. Башка юл булмаганга, мин, җиңелеб, кире Финляндиягә кайтырга баш идем. Фин визасын алыр өчен, фин консулына китдем. Фин консулы, табигый инде, минем үз кешем кебек. Аңарга башдан үткән вакыйгаларны сөйләб бирдем. Кире кайтыб китүемне алар да куәтләделәр. Хәтта кичке поездда ук китүемне мәгъкул күрделәр. Фин консулының әйтүе буенча, минем рус визам транзит булмаганга, миңа транзит юлы берлә генә совет хөкүмәтендән чыгарга мөмкин вә ул канунга буйсыну өчен Эстония үтә дә кайтып китәргә мөмкин булганын аңлаб, Эстония консулына китдем. Ләкин сәгать ике булганга, консулият ябылган. Ни эшләргә белми катыб вә абдыраб торсам да, хәзер инде соң иде. Хәзер инде мин советның авыр хөкеменә мәхкум бер кеше идем.

***

Бераз хәл туплаб, җәһәннәмдә янарга күнгән кебек, бер җиргә дә китмим, кунам, хәтта иртәгә дә кунам, диб кычкырыб йибәрдем. Минем бу сүзем дустларымны каушатса да, чарасыздан алар да бу хөкемгә разый булмыйча хальләре юк иде. Акрын гына, кайгыра-кайгыра, өйгә китдем. Иртә берлән беренче эшемез Эстония консульствосына китү булды. Анда баргач, консул: «Парпортыңызда француз пичәте юк. Мин бу пичәтләрне танымыйм», – диб кызды һәм безне куыб чыгара башлады; барысы да безнең йөрәкне яндырды. Ахырда иманга килеб, виза басса да, мин инде бу скандаллардан туйган идем. Бу көн янә монда куныб, иртәгәсен кичке экспресс берлә Мәскәүгә китәргә карар биргән идем. Консулдан чыгыб туры багажлар артындан Ходовиски (Ходайски. – Х.М.) дигән утрауга таможня йортына китдек. Багажлар килгән иде. Мең бәла берлә багажларны каратырга муафикъ булсак да, берсен кулымызга бирмичә, кире Финляндиягә кайтарырга булдылар. Куаныч берлә калган багажның хөкеменә разый булыб, өйгә кайтдык. Иртәгәсе көн торыб чәй эчкәч, кичә генә килгән «Красин» пароходын карарга китдек. Без

барганда пароход тирәсендә чиксез күб халык җыелган иде. Шулай да безнең урыныбыз бик якшы туры килде. Пароходны башданаяк караб чыкдык.

Андан соң шәһәрне карарга китдек. Әүвәлге Невский, Садовое, Гороховой кебек атаклы урамнарның исемнәре дә үзгәргән. Әллә нинди Октябрь 25, Октябрь 26, Ленин, Декабрь кебек исемнәр берлә исемләнеб беткәнләр. Бу көн якшәмбе көн булу сәбәбле, мин халыкның өстке-башын бигрәк дә җентекләб карадым: ефәк ак урынына моданы тотар өчен нечкә йиб (?) оеклар, Парижның мода журналына караб, алар кебек кыланыр өчен, ефәк пальто урынына ялтыравыклы кара сатин пальтолар киенгән хатын-кызлар, иске заманда эшләтелеб калган вә мең мәртәбә үтүк йөртелгән, ялтыравыклы, иске вә майлы муенбаулы (галстуклы. – Х.М.) ирләр: иске заманда эшләнеб хәзергәчә кадәр йонлары коелыб, якалары кыршылыб беткән «сак»лы (?) баринлар – барысы да фәкыйрьлекнең чигендә идекләрен белгертәләр вә кызганычлы сурәтдә ярлылык, юклык берлә тартышуларын аб-ачык аңлаталар иде. Урамлар әүвәлге кебек пакь вә тәмиз (чиста. – Х.М.) булса да, һәр урамга ташлар тезелеп торылса да, өйләр искергән, каралган булсалар да, тышкы вә эчке күренешләре берлә гаять каралган вә керләнгән иделәр. Трамвайларга кереб билет алганда да кануннары бар иде. Мәсәлән: 1) бер стансада 5-6лаб тукталыш йир бар; 2) трамвайга утыру өчен беренче туктый торган йиргә кадәр генә барса да, бер стансага кадәр түләргә тиешле; 3) бер стансага билет алыб, яңлышлык берлә генә булса да шул стансаны узыб киткән булса, бер сум штраф түләячәк.

Йөри-йөри Гостинный двор, Александровский рынок, Сенной вә Апраскин кебек әүвәлдә Петербургның мәшһүр сәүдә урамнарын үтеб, караб чыкдык. Магазиннарның тәрәзәләре пленка берлә кадакланмаган, анда-монда җимерелгән, тузанланган, чалшайган, пыялалары ватылыб ташландык бер хәлгә килгәннәр иде.

«Бүтән көнләрдә бу Пассажларда һичбер сәүдә итүче адәм юкмы?» – диб соравыма каршы: «Әүвәлдәгегә караганда 2 процент булыр, ләкин аларның маллары тәрәзә төпләрендә генә, эчдә кулга алырлык бернәрсәләре дә юк», – диб җаваб бирделәр.

Юлыбыз Невскийга борылды. Анда да шулай ук искелек вә сәләмәлек иде. Якындагы бер кибет тәрәзәсендә хатынларга махсус сатмак ефәк күлмәк күреб шашыб китдем. Шашарлык та бар иде: ефәк күлмәк бит! Якынрак барыб карасам, ефәк түгел, ялтыравыклы нечкә сатин икән. Анда инде бу иң кыйммәтле күлмәк, имеш, чөнки өстенә языб куелган хакы да 120 сум иде. Тәрәзә төпләрендә күзгә күренгән байтак кына кулга алырлык маллар күренсә дә, хаклары да мәңге сатылмаслык бәһале иде. Тәрәзәләргә карый-карый байтак кына вакыт үткәреб, янымдагыларның урамның теге ягында мине көтеб торуларын күрдем. Турыдан булсын, диб, мин аларга таба урамны кыйгач кисеб чыкдым. Аларның кулларын бутавыннан мин бернәрсә дә аңламасам да, яннарына килгәч, минем башка вакыт болай кыйгач йөрмәвемне үтенделәр. Чөнки урамны шәм кебек туры итдереб кисеп чыкмаган кешегә милиция шундук, тотыб, 3 сум штраф түләтә икән. Озак та үтмәде, әллә кайдан музыка тавышы ишетелде. Туктаб, килгәнләрен көтдек. Ләкин музыкачылар янә берничә сыбызгы уйнаучылардан гына гыйбарәт иде. Артларында үлек алыб баралар иде. «Поплары кайда соң?» – диб соравыма каршы: «Хәзер бит инде динсезләр заманасы, поп урынына музыкантлар яллый. Менә бу үлек тә ярлы булганы өчен музыкантлары да сыбызгычылар гына», – диб җаваб бирделәр.

Байтак барасы юлымыз бер тар урамга керде. Ләкин бөтен урамында берничә генә өй калыб, урамның һәр ике ягы ачык вә алан иде. «Мондагы өйләр кайда китеб беткәнләр?» – диб сорадым. «Совет хөкүмәте искергән өйләрне төзәттерми, аларны сүтдереб, берничә өйнең яраклырак ташларындан әллә кайларга, кырларга эшчеләр өчен казармалар салалар. Тузган өй урынлары буш кала», – диделәр. Соңра Исакский вә Казанский исемле Ленинградның иң мәшһүр чиркәүләре яныннан үтеб китдек. Болар бар да мокаммәл сурәтдә, ару, пакь вә шома иде. Чиркәүләрнең бу кадәр пакьлыгындан гаҗәбләнеб: «Боларның һичкемгә кирәге юкмыни, керле кул да тимәгән, керле аяк берлә тапталмаган, әллә (чиркәүләргә. – Х.М.) йөрергә рөхсәт ителми?» – дисәм дә, миңа каршы, көлеб: «Русларга болар һәрвакыт кирәк инде. Үткән ел боларны әллә нинди зур суммаларга төзәтдереб бетерсәләр дә, Исакский чиркәвен искедән дә яхшырак чыгарыр өчен ничә ел инде төзәтдереб маташсалар да, бүген дә әле очына чыгыб җитә алганлары юк», – диделәр. Мин: «Соң чиркәүләрне бетермиләрме?» – диб тәкърар сорадым. «Дөрест, бик искергән кечкенә чиркәүләрне сүтеб ташлыйлар, ә зур чиркәүләрне Совет хөкүмәте патша заманындагыннан да артык карый. Ләкин шунысы кызык: безнең Ленинградтагы мәсҗедемезне хөкүмәт үзе дә төзәттерми, үз кулымызга да бирми. Мең бәла берлә намаз укырга рөхсәт бирелсә дә, эчендәге җиһазлар, келәмләр[2] – барысы да хөкүмәт кулында булу сәбәбле, һәркайсына контроль биреб келәмләрне карый вә шулар өчен түләү түләтеб тора. Хәтта келәмләрне бөтенләй алыб, арендага да бирмәү ихтималы бик якындыр», – диделәр.

Юрий Большой проспектына килеб чыкдык. Мин ...извозчикларның азлыгыннан гаҗәбләнеб: «Кайда китеб бетделәр?» – диб сорадым. «Алар бит инде хосусый кешеләр кулында түгел; күренгәнләре бар да хөкүмәтнеке. Хөкүмәтнең аларны гына уйлаб торырга вакыты да юк. Хосусый кешеләр дә булгалаб караса да, салымдан йөдәб, бөтен автомобильләрен дә, атарбаларын да ташлаб качарга мәҗбүр булдылар. Хәзер инде һәркем курка», – диб җаваб бирделәр.

Кич булды. Мәскәүгә китәргә вакыт йитде. Трамвай берлә Октябрьский (Николайски) вокзалга поездга китдек. Чөнки сәгать унларга якын булу сәбәбле, миңа ярты сәгать чамасында гына вакыт калган иде. Совет хөкүмәтендә 1, 2, 3 нче класслар, каты урын, йомшак урын диб йөртеләләр. Бик иртә барыб алган билетым берлә йомшак урынлы, ятаклы вагонга кереб, Мәскәүгә таба хәрәкәт итдем.

P.S.: «Милли юл» журналының 9-10 нчы саннарында (1929 ел) басылган сәфәрнамә шул урында өзелә. Журналның башка саннары да кулга керсә, дәвамын укучыларга тәкъдим итәрбез. – Х.М.

Текстны басмага филология фәннәре докторы
***Хатыйп Миңнегулов** әзерләде.* ■

[2] Боларның иң зурысы сугышдан соңнан бишенче Мөхәммәд биргән бүләге гапять кыйммәтледер.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМНЕҢ «АКМУЛЛА АРБАСЫ» ПОЭМАСЫ ЯЗЫЛУГА – 40,
МӘГЪРИФӘТЧЕ-ШАГЫЙРЬ АКМУЛЛАНЫҢ ТУУЫНА 190 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Арба гына димә...

Тәлгат Галиуллин, филология фәннәре докторы

Мифтахетдин Акмулла.
Эрот Зарипов рәсеме

Мөдәррис Әгъләмов. 1966 ел

Тарихи чыганаклардан, язма истәлекләрдән мәгълүм булганча, иң борынгы чорлардан алып гасырлар дәвамында төрки һәм, гомумән, күчмә халыкларның терәге, таянычы һәм яшәү чыганагы атлар һәм атлы арбалар булган. Алар белән бәйле хатирәләр һаман да күңелләрдә. Кыпчак-хәзәр-угыз-болгар-татар бабаларыбыз атларда, атлы арбаларда Алтайдан алып Кара диңгезгә чаклы җирләрне үтеп, дөнья куласасын кулларында тотканнар, кавемне саклап, нәселләрен безнең көннәргә китереп җиткергәннәр. Шул ук ат-арба кем өчендер туракны да, йортны да алыштырган, матди вә рухи чыганак та булган. Бу образ-сын Мөдәррис Әгъләмнең мәгърифәтче, чичән-акын шагыйрь Акмулла намена, тормышына, эшчәнлегенә багышланган «Акмулла арбасы» поэмасы белән татар сүз сәнгатендә дә үзенең лаеклы урынын тапты. XIX гасырның 1831-1895 нче елларында яшәгән Мифтахетдин Камалетдин угълы – тугры сүзле булганы өчен Акмулла тәхәллүсенә лаек булган татар шагыйре «...яктылык илткән даладагы халыкларга, кара елларда».

Оренбург губернасының Бәләбәй өязендәге Туксанбай авылында дини гаиләдә туып-үскән егет төрле һөнәрләргә сәләтле, бигрәк тә тапкыр сүзгә, җырга маһир була. Ул тирә-юньдә танылган Эстәрлебаш мәдрәсәсенә укырга керә. Әлеге уку йортын «Урал, Урта Азия һәм Идел буйларында «Кече Бохара» дип йөртәләр» («Мәдәни җомга». – 2021. – 6 август). Татар әдәбиятының якты йолдызлары, күренекле шәхесләр – Габдерәхим Утыз-Имәни, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин (сукыр) Зәки, Гали Чокрый, Мифтахетдин Акмулла һ.б.дини һәм заманча белемнәрне шул мәдрәсәдә алалар.

Кайбер чыганаклар буенча, укуын Троицкида дәвам иттергәннән соң, Мифтахетдин татар авылларында мөгаллимлек итә, башкорт сахраларында, казакъ далаларында яшәгән кавемнәргә аң-белем биреп, барчасын мәгърифәт юлына алып чыгу өчен җан атып яши һәм, халык иҗаты кыйммәтләренә, дәрвиш суфый шагыйрьләр мирасына таянып, үзе дә сатирик, лирик жанрларга караган, мәкаль-әйтемнәргә якын хикмәтле робагыйларын иҗат итә. Алар үзе исән чакта ук телдән-телгә йөреп, кулдан язылган истәлекләрдә, бигрәк тә шәкертләр дәфтәрләрендә сакланып калалар.

Акмулланың хәзергә мәгълүм әдәби мирасы күләм ягыннан зур булмаса да, жанрлар төрлелеге, сәнгатьчә эшләнеше, тәэсир көче ягыннан XIX гасыр татар шигъриятенең үзенчәлекле хәзинәсен тәшкил итә. Ул – төгәлләнгән кыска гыйбарәләр, көтелмәгән көлкеле, кинаяле җөмләләр белән шигъри сурәт тудыру сәләтенә ия шагыйрь. Халык иҗаты белгече буларак, кистереп әйтә алам, аның каләменнән төшкән көйле «Хатимә» мөнәҗәте Тукайның «Ана догасы», «Таян Аллага», «Уянмас йокы» кебек шул жанрга караган иҗади очышлары кебек үк җитлеккән әсәр.

Акмулланың көндәлек яшәеш, көнкүреш мәшәкатьләре, авыр, борчулы тормыш турында бәян иткән парчаларының нигезендә дә җан газабы, әрнүсызлану кебек фәлсәфи сыгынтылар ятуын сиземләве кыен түгел. Ул халыкларны гомернең кыскалыгын, кабатланмаслыгын аңлап, дус-тату һәм ярдәмләшеп яшәргә чакыра, шул теләкләрен васыяте итеп калдыра.

Язганнарын матбугатка тәкъдим итеп, бастырып чыгару турында кайгыртмаган (арба бара бирә, теленнән төшкән җыр-көйләре «сибелә» тора) Акмулла, үзе исән чакта, бердәнбер китабын 1892 елда Казанда нәшер итәргә өлгерә. Ул – XIX гасырның якты йолдызы булган мәшһүр тарихчыга, дин реформаторына багышланган «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» исемле ода-поэма.

Автор Аллаһ өйрәтүләренең, Мөхәммәд (с.г.в.) хәдисләренең хаклыгына инанган акыл иясе Мәрҗанинең эчке дөньясы байлыгын, туган халкына изгелек теләвен җете буяуларда тасвирлый.

М.Әгъләм «Акмулла арбасы» поэмасында татар зыялыларының Мифтахетдин Акмулланың үзен дә онытмауларын, ихтирам итүләрен билгеләп үтә: «Риза Казый, Мәрҗаниләр белә, Әйе, белә Казандагылар…»

Татар халкы үзенең иҗатка һәвәс, акыллы сүзләре белән күңелләрне юаткан улларын онытмый, аларга җырларын, мөнәҗәтләрен, бәетләрен юллый. Фольклорыбызда фаҗигале язмышлы олуг затларыбызны зурлаган тарихи җырлар, бәетләр күп булса да, әдәбият, дөресрәге, шигърият әһелләреннән бары тик ике генә шәхескә – Акмулла белән Тукайга багышланган фаҗигаи тезмәләр генә сакланган.

Бәетләрнең сәнгатьчә үзенчәлеген хискә бирелүчәнлек, кайгы-хәсрәтне тыңлаучының күңелендә калырлык итеп, натуралистик ваклыкларга әһәмият биреп сурәтләү тәшкил итә. Акмулланың тормыш юлы нәкъ шундый гонсырлардан тора: гаилә бәхетеннән мәхрүм булуы гына җитмәгән, ул, көнчеләр, керән кебек ачы теленнән котылу җаен эзләгән байбичәләр «булышлыгы» белән, зинданда да утырып чыга.

«Төрмәләргә кергән…(Ул чакта да Таш капчыкка җырлар сыймаган)», – дип яза М.Әгъләм бу хакта поэмасында.

Икешәр юллы, 15-15 иҗекле 16 бәеттән торган, татар халык иҗатының энҗеләреннән саналырга лаеклы «Акмулла бәете»нең үзәк өлешен, фәнчә әйтсәк, кульминациясен Мифтахетдин мелланы юлда куып җитеп үтерүләре тәшкил итә. «Акмулла тикле намне ничек үтермәк кирәк», «Акмулланы үтергәннәр күренмәгән мал өчен» кебек юлларда билгесез авторның (бәлки, алар берничә булгандыр, һәркайсы үз сагышын өстәгәндер) ачу катыш үпкәсе бәгыреннән кайнап чыкканлыгы сизелеп тора. «Акмулланың китапларын өеп кенә яндырган» дигән юллардан мөсафирны мал-мөлкәте өчен түгел, ачы телле, тәнкыйди рухлы шигырьләре, хәзергечә әйтсәк, сатирик эпиграммалары өчен үтерүләренә басым ясала. Аның бар байлыгы кулындагы «өч тәңкәлек йөзеге», «сиксән тәңкә акчасы», «яшел хәтфә» эшләпәсе белән комганы гына булуы ачыклана. Булмаган байлыкка кызыгып юлчыны куып җитеп үтерүләре өчен «Дәүләтша дуңгыз»ны, аның яклаучысы «пүнәтәй Мөхәммәтлатыйф»ны бәетче каһәрли һәм исемнәрен «тарих тактасы»на кадаклый.

Автор, шул аяныч хәлнең шаһиты булгандай, Мифтахетдинның тиз генә бирешмәвен, «көрәшүен» искәртү алымын таба: «Дәүләтшаның сакалы Акмуллада кайткандыр».

«Акмулла бәете»нә игътибарны юнәлтүемнең сере шунда: шагыйрь «Акмулланың арбасын буяганнар дан өчен», «Саф алтынны нәҗескә буяу илән нәҗес китәр, алтынның заты китмәс» кебек юллама-эпиграфларына нигезөлгене бәеттән, Акмулланың үз иҗатыннан алуын һәм алардагы мәгънәви эчтәлекне, экзистенциаль сагышны, югалту өчен үкенечне шул чыганаклардан алып, гомуми мәгънәви-сәнгати юнәлешне саклавын искәртеп бара. Шул ук вакытта ул татар халкының асыл заты Акмулланың гомерен өзгән «Дәүләтша дуңгыз»ны, аның иярченнәрен сурәткә кертүне эпик киндер өчен түбәнлек санап, җинаятьчеләрне телгә дә алмый. Чөнки алар илдә хакимлек иткән «караңгылык патшалыгы»ның мескен «шөрепләре» генә.

Аның каравы, Акмулланың эш-хәрәкәте, рухи һәм аны чолгап алган матди дөньясы XX гасыр ахыры шагыйренә якын һәм газиз. Тормыш-көнкүреш

күренешләренә, детальләргә таянып, ул Акмулланы милли рухлы, инсафлы, үз көнен хәләл көче белән күрә белгән гаяр шәхес итеп сурәтләп, аның җанлы образын тудыра:

«…Үз арбасы, юл арбасы булган,
Өч бүлектән торган ул арба.
Кайсы якка гына юл алмасын,
Кайсы якка гына бармасын,
Күтеп алган халык Акмулланың
Өч бүлектән торган арбасын».

Акмулла бер бүлектә «балта, пычкы, ышкы…» кебек эш коралларын йөртсә, икенчесен «татар китаплары», үзенең кульязмалары бизи, өченчесендә үзе утырып йөри. Акмулланың тормышына һәм иҗатына бәйле һәр шәй М.Әгъләмнең күңел түрендә, димәк ки, поэмасының үзәгендә. «Әдипләребез» библиографик белешмәлегендә язылганча, «Кечкенә генә поэтик деталь аша ул туган ил, милләт язмышы, аның үткәне, бүгенге хәле, киләчәге турында укучыны тетрәндерерлек гомумиләштерүләр ясау осталыгына ия» (2009, 68 бит).

Акмулланың тормыш юлын, иҗатын күзәтү аша поэмада ясалган сагышлы да, үкенечле дә уйланулар каты бәгырьле кешеләрне дә битараф калдыра алмагандыр дип ышанам:

«Гомер-сәфәр. Соңгы сәфәре дә
Кереп калган бәет-җырларга.
Ерак киткән арбасының даны,
Ә үзенең даны елларга».

М.Әгъләм, лирик шигырьләрендә хыялына тулы ирек биреп, бизәкләү чараларын куллануда дилбегәне аңлы рәвештә «кулдан ычкындырса» да, «Акмулла арбасы» поэмасында төгәл һәм эзлекле сюжет төзү, вакыйга, кичереш агышын максатлы юнәлештә үстерүгә өстенлек бирә. «Мөдәррис Әгъләмов күләмле әсәрләрне бик аз яза. Аның озын-озак итеп язарга вакыты юк… Тукай кебек. Шулай да аның поэмалары бар: «Акмулла арбасы», «Тукайдан хатлар» (М.Әгъләмов. «Иман тәрәз шакый», 1996, 9 бит), – дип искәртә Р.Зәйдулла кереш мәкаләсендә.

XIX гасыр акыны Мифтахетдин белән 20 нче йөз ахыры шагыйре Мөдәррисне үзләре яшәгән замана сулышын, туган халыкларының йөрәк тибешләрен югары сәнгатьлелек чаралары белән сурәтләү сәләтләре генә түгел, ә киләчәккә романтикларча ышаныч-өмет белән яшәүләре, ахыр чиктә дәрвишлекләре якынлаштыра.

Кайбер язмаларда төркиләрнең уртак шагыйре буларак аталса да, Акмулла, хәзерге көннәрдәге бериш «акыллы башлар» шикелле, халыкларны берберсенә каршы куюны, төрле ыру-кавемнәргә бүлгәләүне кабул итмичә, дуслык һәм татулык җырчысы буларак алга килеп басса, М.Әгъләм, шул ук фикерләргә таянып, кайчан булса да гамәлгә ашырга тиешле хыялын калкытып куя:

«Үз дәүләте, үз китабы булыр,
Ник булмасын, булгач үз теле».

Әдәби әсәр аерым бер шәхес образын үзәккә алып, аның эшчәнлеген сурәтләүгә багышланган булса да, милләтен, каләмдәшләрен, гомумән, үз чорын борчыган мәүзугъларны да читләтеп үтә алмый. «Акмулла арбасы» поэмасының хронотобын өч вакыт бердәмлеге билгели: үткән, бүгенге һәм киләчәк. Ошбу юлларда поэма язылган һәм безнең көннәрнең дә «кара тамгасы»н тануы кыен түгел:

«Егерменче гасыр бусагасын
Таптап төшерергә торганда,
Бүлмәләргә кереп бикләнгәнбез,
Ишекләргә тишек тишкәнбез».

Алдагы шигъри тасвирламада рәдиф-алрифма буларак кабатлана килгән гыйбарә гадилеге белән гали: «Ишек шакый кемдер» безнең хәзерге яшәешебездәге сәер дә, шомлы да халәтне күз алдына китереп бастыра. Градация алымы вакыйгалар агышын, кичереш үсешен тәгаенләргә мөмкинлек бирә. Беренче очракта ишеккә шигърияткә гашыйк фанат шакыса, икенчесе Тукайның туган көне якынлашуын искә төшерсә, өченчесе язганнарына, мәдхияви үк булмаса да, җылы сүз ишетү нияте белән килсә, кайсыдыр Акмулла яисә Тукай булу хыялына «ияреп», «ишекләргә шакып» йөри. Бар «дәгъвачылар»га уртак җавапны М.Әгъләм бер куплетка сыйдыра:

«Шигырь язып Тукай булмакчылар,
Акмулла ул, әйе, тикмәгә
Үзе белән йорт салырга – корал,
Сабак өчен китап йөртмәгән».

Соңгы юлларның төртмәле сүз сөрешеннән шигырь сырлап кына Тукай биеклегенә күтәрелә алмаячагыңны аңлап, тамак туйдыруның Акмулла күрсәткән башка юллары да булуга кинаяне төсмерләве кыен түгел.

Үрнәк мисал эзләп җир шарының башка кыйтгасына барасы да юк икән. «Акын-чичәннәрне уздырып» җыр чыгарып, аны үзе үк көйләп бирү сәләтенә ия Акмулла «Йортын салса салган сокланырлык, Чат ябышып яткан нигрәләр». Уңганлыгы-булганлыгы өчен аны һәр төбәктә «Кунак булып түгел, үз булып» көтеп алганнар дип искә төшерә поэма авторы.

Акмулла белән Мөдәррис тавышлары поэмага полифоник яңгыраш биреп, берсен-берсе «тулыландырып» киләләр. Ә инде ат-арбаның дилбегәсе тулысынча М.Әгъләм кулына «эләгүгә» сурәтнең офыгы киңәеп, татар галәменең үткәнен иңләү аша халкыбызның иркле тормыш, азат яшәеш турындагы хыялларын алгы нәүбәткә чыгарырга мөмкинлек бирә. Хәтта хәтер алышыныбрак алгандай серле мизгелдә ат-арбада М.Әгъләм үзе утырып баргандай тоела.

Чынлыкта Мөдәррис дилбегәне «кулына бәйләп», үз серле арбасында «дөнья гизә» имди:

«Безнең дә бар, шөкер, үз арбабыз,
Калма төшеп безнең арбадан».

Әлеге арбаның реалистик шартлылык җимеше икәнен акылың белән бәяләгән очракта да канатлы шигъри сүзнең кодрәтенә буйсынасың!

Нәкъ менә шул мизгелдә: «Мәгърифәтче шагыйрь Акмулла иҗаты фәндә, матбугатта тиешле бәясен алдымы?» – дигәнрәк сорауның калкуы да табигый.

Әйе, Мифтахетдин Акмулланың тууына 150 ел тулган 1981 елның көзге айларында, Казанда, киң җәмәгатьчелек, язучылар, галимнәр катнашында, зур фәнни-гамәли конференция уздырыла, материаллары басылып та чыга. Бу урында юбилей тантанасында төп докладны ясаган һәм, гомумән, Акмулла мирасын яратып, бирелеп өйрәнгән, әсәрләрен текстологик басмага әзерләп, кереш сүз, искәрмәләр белән шул ук елда Татарстан китап нәшриятында әлегә иң тулы җыентыгын бастырып чыгарган (1981. – 271 б. – 3500 данә) галим-тарихчы, академик, язучы Миркасыйм Госмановның рухына үзем һәм укучыларыбыз исеменнән дога юллыйм. Авыр туфрагы җиңел, урыны җәннәттә булсын мәрхүмнең.

Шунысына да игътибар итү ләзим: Акмулла иҗатына багышланган конференциягә чакыру алуга дип уйлыйм, Башкортстан галимнәре, эшмәкәр-милләтчеләре тиз арада оешып, бар әсәрләрен тәрҗемә итеп, Ә.Вилдановны төзүче итеп куеп, 1981 елда ук Акмулланың шигырьләр китабын («кысмыр» татар нәширләренең «борыннарына чиертеп») Өфедә ун мең тираж белән бастырып тараталар. Хакыйкать өчен шуны да искәртергә кирәк: Акмулла, тезмәләрендә гарәп-фарсы лөгатьләреннән, казакъ теленнән алынмаларны кулланса да, башкорт халкын ихтирам итсә дә, әлеге шивәдә бер шигырь дә язмаган.

Ул елларда әдәбият тарихы дәреслекләрендә, энциклопедияләрдә Акмулла иҗатын яктырткан мәкаләләр күренгәләсә дә, бер гасыр элек яшәп иҗат иткән каләмдәшенең якты истәлегенә, рухына иң олы бүләкне «Акмулла арбасы» исемле лиро-эпик әсәре белән XX гасыр азагы сүз остасы Мөдәррис Әгъләм ясады: һәдия итеп, шигъри һәйкәл куеп, аның образын яңа чорга якынайтты.

Төрле кавемнәр яшәгән юллардан күчәрен шыгырдатып барган арбадан: «Әйдәгез әле, малкайларым, адымнарны тизләтик», – дип, Мифтахетдин хәзрәтнең карлыкканрак тавышын ишеттергәндәй тоела.

«Тик бер гасыр үткән. Ишетелә
Келтер-келтер һаман барганы».

Арба игътибарсыз гына үтеп китә алмый, дәвамчылары аны онытмыйлар:

«Йөзләп шагыйрь чыккан өч урынлы
Шул арбага яулык болгарга!»

Поэмадан Акмулланың арбасын озатып калырга чыккан шагыйрьләрне хуплаган Мөдәррис Әгъләмнең тавышы «ишетелә»: *«Мактап җырлыйк Акмулланың өч бүлектән торган арбасын».*

Нәтиҗә ясап әйткәндә: «Акмулла арбасы» поэмасында М.Әгъләм төрки-татар кавемнәре мәнфәгатьләре белән яшәгән көчле рухлы, сәләтле, мәгәр фаҗигале язмышлы булса да, сынмаган-сыгылмаган, үзендә татар милләтенең куәсен, аң үсеше дәрәҗәсен туплаган шәхесне сәнгатьчә югарылыкта тасвирлауга ирешә. Исән булса, шагыйрьгә: «Афәрин, Мөдәррис кордаш, юкка яшәмәгәнсең!» – дип олылап эндәшер идек... ■

Тарихтан ишарәләр

Ркаил Зәйдулла



Мисырдагы борынгы Александрия каласының атаклы китапханәсе һәм аның урынында 2002 елның 16 октябрендә ачылган, бүгенге көндә дөньяда иң зурдан саналган, фондында 7,5 миллион китап сакланган (шуның 500 меңе – укучы хозурында) «Александрина» китапханәсе

Таңбага

«Кульъязмалар янмый» дигән гыйбарә бар. Хакмы-түгелме, күңелдә ниндидер өмет уята ул. Янган очракта да алар бөтенләй юкка чыкмый, сәмави архивларда сакланып каладыр, бәлки. Ләкин безгә бу фани дөньяда аннан ни мәгънә? Кульъязмалар яна, юкка чыга. Бу бигрәк тә аяусыз сугышларда җиңелеп дәүләтен җуйган халыкларның мирасына хас фаҗига. Аларның рухи байлыгын йә тәмам юк итәләр, йә үзләштерәләр.

Әлбәттә, Тукай: «Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады», – диюе белән хаклы. Ләкин «халык шигырьләре»н Гайнетдиннәр, Гөлҗамаллар кич утырган арада җыйнаулашып чыгармаган, аларны аерым кешеләр – үз заманының шагыйрьләре, аһәңсазлары иҗат иткән. Тик аларның исемнәре безгә килеп җитмәгән, онытылган: «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь Онытылу дигән үзәндә». Исемең онытылып та, ике юл гына булса да шигырең «халыкныкы» булып гасырлар кичсә, шагыйрь өчен моңардан да зур мәртәбә бармы?!

Шигырьләре гасыр җилләрендә таралып, исемнәре тарихта сакланган шагыйрьләр дә бар. Мисыр галиме Әмир әл-Холи китабында («Связи между Нилом и Волгой в XIII-XIV вв. – М., 1962, с.32) шуларның берсе – кыпчак шагыйре Галәветдин Таңбага телгә алына. Алтын Урдадан Мисырга мөһаҗирлеккә китеп, 1343 елда вафат булган бу шагыйрьнең тулы исеме – Галәветдин ибне Гатаулла әл-Җуали әт-Таңбага. Әл-Холи шул замандагы кыпчак әдибе Тәңребирденең (монысы хакында кайсыбыз хәбәрдар?) сүзләрен күчерә: «Ул (Таңбага) – төрк шагыйрьләренең иң бөекләреннән берсе. Кабиләсендәге (ягъни кыпчаклар арасында) ир-егетләрдән ялкынлы шигырьләр иҗат итүдә аның белән чагыштыра алырлык кешене мин белмим».

Бәлки, Таңбаганың шигырьләре кайсыдыр Мисыр китапханәсендә тузан җыеп ятадыр. Аны кем эзләгән? «Кульязмалар янмый», – диләр бит...

Пески

Мәхмүт Галәүнең Тукай турындагы истәлекләрендә (шактый кыскартылганга охшаган – тексттагы күпнокталар <...> шул хакта сөйли, аннары язма үзе дә «Г.Тукай турындагы истәлекләрдән бер кисәк» дип атала) авторның шагыйрь белән төн уртасында каядыр барулары бәян ителә: «Төн уртасы якынлашкач, баскыч астындагы «закусочная»га төшеп, бераз тамак ялгап алдык та извозчиклар торган почмакка килдек:

– «Пески»гә күпме аласың?

Извозчик илле тиен сорады. Мин, кыйммәтсенеп, сатулаша башладым.

– Сатулашма, Мәрҗән! – диде Тукай. – «Өйләнгән» елны егетләр юмарт була <...>

Истәлек шулай өзелә. «Пески» нинди урын ул? Нигә Тукай сатулашмаска кушканда «өйләнүне» сәбәп итә?

Бу сорауларга җавапны мин Гадел Хәировның «Суконкин сын» әсәреннән таптым. Гадел – Казанда туып-үскән егет, башкалабыз тарихын яхшы белә. Һәм әсәрләрендә шул белемен бик урынлы файдалана да. Нишлисең, шәһәр малае буларак, Гадел дә русча яза. Пескигә кагылышлы өлешенең татарчасы мондый: «Казанда иң гөнаһлы урам Пески дип аталган. Соңрак аны Дегтярная дип үзгәрткәннәр. «Спартак» аяк киеме фабрикасыннан зоопарк ягына юнәлсәң, нәкъ шул урамга килеп чыгарга мөмкин. Казан губернасында ул чакта (XX гасыр башында. – Р.З.) 23 фәхешханә (дома терпимости) исәпләнгән, аларда 149 хатын-кыз хезмәт күрсәткән. Казанның үзендә андый йортлар 17 була, фәхешханәләр саны буенча Казаннан Т.Новгород, Пермь, Самара һәм хәтта Киев та калыша. Рәсми теркәлгән 330 фахишәнең 282се – рус, 29ы – поляк, 19ы – немец, 2се – яһүд, 1се татар хатын-кызы була».

Бу белешмәне укыгач, безнең татар хатын-кызларына фахишәлек хас булмаган дип горурланырга булыр иде дә... Бүгенге хәлебезне белгәнгә, үткәннәр белән горурланудан ни файда? Аннары татар бистәләрендә дә берничә «тәтәйләр йорты» булганлыгы билгеле. Күрәсең, алардагы фахишәләр рәсми теркәлмәгәндер.

Фәхешханәләрнең иң арзанлысына 20 тиенгә керергә мөмкин булган. М.Галәүдән извозчик сораган 50 тиенне исәпкә алсаң, бөтенләй бушка диярлек! Әлбәттә, бу номерларда триппер ише авыру эләктерү мөмкинлеген дә онытырга ярамый. Ә уртача кимәлдәге фәхешханәдә бер сумнан ике сумга кадәр түләргә туры килгән. Идел пароходчылыгының капитаны ул чакта айга 73 сумга кадәр эш хакы алса, гади матросныкы исә 18 сумны тәшкил иткән.

Фәхешханәләр ачыктан-ачык эшләгән, казнага салым түләгән, алар өчен рәсми кагыйдәләр дә булган. Бүген кайбер эшлеклеләр төрле ялган исемнәр астында эшләүче фәхешханәләрне рәсмиләштермәкче була. Шулар өчен әлеге кагыйдәдән бер өзек тәкъдим итәм. Кагыйдә, әлбәттә, урысча язылган булган (бер татар фахишәсе өчен татарча язып тормаслар бит инде!): *«Кровати должны быть отделены или легкими перегородками или, при невозможности, ширмами. Содержательница должна следить, чтобы женщины блюли опрятность постели и своего белья, а также обмывали теплой водой известные части тела, и в особенности, чтобы девки употребляемые не переходили тотчас же к другим посетителям, не омывшись и не передохнув. Чтобы имеющие месячные очищения отнюдь не допускались к занятию промыслом»*.

Нинди өслүп! Безнең чиновникларга бу кимәлдә язар өчен өйрәнергә дә өйрәнергә әле.

Каз аягы эзләре

Гаяз Исхакыйның язуын тану авыр була. Наширләр, хәреф җыючылар танымаганга, аның әсәрләрен, акча түләп, махсус кешеләрдән күчерткәннәр. Зариф Бәшири үзенең истәлекләрендә «бер язучы» дип, һичшиксез, Гаяз Исхакый турында яза. «Гасыр көтепханәсе»нең тапшыруы буенча, ул да бөек язучының бер әсәрен күчереп чыга: «Сүз төзелешләре матур, җайлы; вакыйгалар, җепкә тезелгәндәй, бер-берсенә тигез, шома булып бәйләнеп баралар. Ләкин язу мәсьәләсенә килгәндә, иреклe-ирексез, бер гарәп шагыйренең: «Яр буендагы каз аягы эзләренә охшаган хатыгызны алдым. Ләкин укыр өчен үзегезне чакырырга кирәк булыр», – дигән сүзләрен хәтерләргә туры килә».

З.Бәшири «бер язучы» турында Галимҗан Ибраһимовның сөйләгәннәрен дә теркәп калдырган: «Хәтта аның язылган кәгазь кисәкләре дә төрлесе төрле җирдә чәчелеп, буталып беткән була. Ул аларны соңыннан көч-хәл белән җыеп алып тәртипкә сала. Бу нидән шулай? Чөнки ул, үзенең бөтен күңелен, уен,

Атаклы әдип Гаяз Исхакый (1878-1954)

дикъкатен салып, артык бирелеп язганлыктан, күп вакытта каләмен, кара савытына манам дип, шап иттереп өстәлгә китереп тә кадый яисә кара савытын төртеп аударып та җибәрә. Каләмен чамалап мануга игътибар итмәгәнлектән, каләмгә артык күп салынган кара өстәл өстенә дә тама. Яза торгач, шулчаклы мавыгып, кызып китә ки, язылып тулган кәгазьне бер кырыйга этеп кенә җибәрә дә тиз генә икенче кәгазьне – нинди туры килсә, шуны эләктереп – тартып ала, ә теге этеп җибәргән кәгазь бер читкә очып китә. Бервакыт шундый бер хәл була: ул бер журнал өчен мәкалә яза һәм язып бетергәч тә, аны яңадан карап, укып-нитеп тормастан, редакциягә җибәрә, аннан язма типографиягә китә. Типографиядә җыелып, корректурасын укый башлагач, корректорлар мәкаләнең урта бер җирендә аптырап калалар: сүзләр дә, җөмләләр дә, әйтергә теләгән фикерләр дә бер-берсенә ябышмый. Аптырагач, редакторга күтәреп китәләр. Ул да укып карый: «Юк, ябышмый, бернәрсә дә аңлашылмый!» – ди. Иң азагында язучының үзенә баралар. Ул үзе дә, укып карагач, хәйран була: «Арадан берәр кәгазь кайда да булса төшеп калгандыр яисә берәр җирдә буталып ятадыр, – ди ул. – Эзләргә, табарга кирәк!» Эзлиләр, редакциядән дә, типографиядән дә, язучының үз өстәл өстендәге кәгазьләр арасыннан да эзлиләр, ләкин табылмый. Шуннан күпмедер вакыт үткәч, теге әдип язу өстәленә җәелгән кәгазь урынына башка бер кәгазь җәеп куярга була. Шул чагында аның күзләре өстәлгә җәелгән кәгаздәге язуларга төшә. Йа Хода, үз язуы икән! Әлеге мәкаләне язган чагында, ул, һичнәрсәгә игътибар итмәстән, кызып китеп, өстәлдәге кәгазьгә яза биргән...»

Шушы вакыйганы сөйләгәннән соң, Г.Ибраһимов нәтиҗә ясап болай дигән: «Ул, артык бирелеп китеп, тирән уйлап язуы аркасында, башына килгән фикерләрне, күз алдында җанланган сурәтләрне тасвир итүгә чумып, язуының матурлыгына булган игътибарны да югалта».

Миңа калса, Г.Исхакый өслүбендәге чатаклыклар да шул ашыгып язу белән аңлатылса кирәк.

Беренче әдәби кичә

Узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларында Тукай клубында (Бауман ур., 19 нчы йорт) әдәби кичәләр шаулап үтә иде. Еш кына залда басып торырга урын булмый. Шигырь сөйләүчеләр арасында берәр мәшһүр җырчы яисә билгесезе җырлап алыр иде. Күрәсең, тамашачыларның шактые шул җырчыларны тыңларга да йөргәндер. Хәзер дә «шигырь кичәсе» дип белдерү элсәләр, анда, әлбәттә, халыкка танылган берничә җырчының исеме арага ябышкан булыр. Оештыручыларның уенча, мөгаен, җырлаучы булмаса, тамашачының шигырь кичәсенә бөтенләй килмәве дә ихтимал. Болай уйларга да нигез бар.

Язучы, мәгърифәтче
һәм нашир Исмәгыйль Гаспралы
(1851-1914)

Бөек мәгърифәтче Исмәгыйль бәк Гаспралы Казан татарларының (хәер, бар татарның да!) әлеге үзенчәлеген белмәгән, күрәсең. Ул исә Казанда иң беренче әдәби кичә оештырган кеше. Гаспралы болай яза (урысчадан тәрҗемә): «1882 елда, Казанда булган чагымда, татарлар өчен әдәби кичә оештырырга ниятләдем. Рөхсәтне зур кыенлык белән алдым, шәһәрнең татарлар яшәгән өлешендә афишалар ябыштырылды, Воскресение урамындагы беренче класслы кунакханәнең зур залына күпсанлы урындыклар һәм оратор өчен кафедра куелды. Билгеләнгән сәгать тугыздан соң мин тагын ике сәгать көттем, әмма килүчеләр өчәү генә иде, алар да казаннар түгел, читтәгеләр: берсе – Кавказдан Аллаһияр бәй, ә икесе – Оренбургтан, булачак «Вакыт» газетасы наширләре берадәр Шакир һәм Закир Рәмиевләр».

Казанда беренче әдәби кичәнең язмышы шундый. Әмма безнең тарих өчен әһәмияте искиткеч. Биредә ике бөек татар – Гаспралы белән Дәрдемәнд беренче тапкыр очраша.

Кичәгә килүче кунаклар Гаспралының чыгымнарын (аренда, афишалар) үз өсләренә алалар, үзен зурлап бай мәҗлес коралар. Төн авышканда гына тәмамланган бу мәҗлестә Казан татарлары турында нинди фикерләр әйтелде икән? Чамалавы кыен түгел.

«Шәрык клубы» ачылырга әле егерме елдан да артык вакыт кирәк булачак.

Гаспралы исә Казанга бу тәүге килүендә Казан татарлары арасында үз мәсләген хуплаган, аны газета нәшер итәргә рухландырган бер генә кешегә юлыга. Ул кешене Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани дип атаганнар. Тарих алдында йөз кызартмас өчен бу да аз түгел.

Грот-букет

Кырымда Исмәгыйль бәк Гаспралы нәшер иткән «Тәрҗеман» газетасының 20 еллык юбилеен да, 10 еллыгы кебек үк, зурлап билгеләп үтәләр (1903 елның 10 апреле). Котлау телеграммалары ява, бүләкләр килә. Дөя дә бүләк, төймә дә бүләк… Дөя, әлбәттә, күзгә ныграк ташлана.

Бүләкләр хакында язганда Исмәгыйль бәк үзе берсен аерып куя (урысчадан тәрҗемә): «Мин алган бүләкләр арасында алтынчы берадәр Рәмиевләр җибәргән, Уралда чыгарыла торган асылташлардан ясалган грот-букет һәркемнең игътибарын җәлеп итә. Әлеге бер пот авырлыктагы кыйммәтле нәфис коллекция алтын, яшма, александрит, зөбәрҗәт, аметист, топаз, хризомит, тау бәллүре кебек 82 төрдәге саф асылташ һәм мәгъдәннән гыйбарәт».

Гаспралының варислары бу затлы бүләкне Төркиягә алып чыга алдылармы икән? Әллә ул, чекистлар кулына эләгеп, берәр яһүднең коллекциясен баетканмы?

Югыйсә бу сәнгать әсәре Гаспралының яисә Дәрдемәнднең музейларын бизәп тора алыр иде. Хәер, кайда ул музейлар? Бу бит әле бик якын тарих. Күпме затлы нәрсәләр таралып беткән, татар мирасы буларак юкка чыккан.

Канкардәшлек

– Бер һәвәскәр тарихчы мәкалә җибәргән, – диде Газинур Морат. – Безнең яктагы шәҗәрәләрне тикшерә. Минем нәселнең очы Ишморатов байларга тоташа, имеш… – Ул, тәкәллефсез генә, мәкаләне өстәлгә ташлады, тик күзендә кабынган горурлык чаткылары шул килеш калды.

Заманнар үзгә шул... Әле кайчан гына язучылар бихисап анкеталарга социаль чыгышын язганда йә крәстияннән, йә эшчедән, дип язалар иде. Хәзер күбесенең нәсел башында морзалар, һичьюгы, муллалар пәйда булды. Мәрхүм Марат Мөлеков – Татар иҗтимагый үзәгенең беренче рәисе – пирәшләп утырганда, үзен хәтта Күчем хан токымы, дип мактанган иде.

Әллә ни мактанырлык ерак бабаң булмаса, затлы нәсел белән туганлашу да горурлык хисе уята. Егерменче гасыр башында атаклы дин галиме Галимҗан хәзрәт Баруди җае чыкканда хатынының Касыйм шәһәрендәге Шаһкол сәедләр (Шакуловлар) нәселеннән булуы белән мактанып алырга яраткан. Ә сәедләр, мәгълүм ки, шәҗәрәләрен пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәламнән башлый.

Бер мәҗлестә янәдән шул турыда сүз чыккач, шунда утыручы Гаяз Исхакый әйтеп куя:

– Алайса, пәйгамбәребез дә мишәр булган икән...

Кызының язуынча, уләренә берничә көн калгач та Исхакый шул вакыйганы искә төшереп, көлеп алган.

Шунысы кызык: математикларның исәпләве буенча, шәҗәрәдә тамырларга таба ун-унике буын төшеп, һәр буынны икегә тапкырласаң, Францияише уртача Аурупа иленең барлык кешесе үзара туган-тумача булып чыга икән.

Димәк, биш-алты гына (бәлки?!) миллион калган татарлар үзара тагын да якынрак кардәш! Бәс, шулай икән, һәр татар үзен йә хан токымы, йә, һичьюгы, мишәр дип саный ала. ■

Редакциядән:

*Татарстанның халык шагыйре, прозаик һәм драматург, ТРның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты **Ркаил Зәйдулла**га (Ркаил Рафаил улы Зәйдуллинга) 23 гыйнварда 60 яшь тула. Каләмдәшебезне юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!*

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022



Зөлфәт
(1947-2007)

Юл өзеге

Рәдиф Гаташка – шагыйрьгә, укытучыма

Без өметле идек ул елларда...
Яндым, гашыйк булдым, саташтым –
Безнең адашкан тын, кара якта
Шигырьләрен тыңлап Гаташның.

Әйтте хәлфә: кара түгел бу як,
Шушында бит телнең оясы –
Кара булмый теле бай төбәк:
Сезнең кайбер сүзләр
Казаннарның
Ун сүзеннән хәтта көчлерәк!

Татарның мәшһүр шагыйре Зөлфәт каләмдәшләре һәм дуслары (сулдан уңга) – Рәдиф Гаташ, Роберт Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләм һәм Халисә Мөдәррисова белән

Аксакал да иде безнең хәлфә
Һәм егет тә – кызлар сөйде ул:
Сезнең өчен Рәдиф Гаташ булса,
Безнең өчен хәлфә иде ул –
Төнен әйбәт шигырь яза алса,
Хәлфә түгел, хәтфә иде ул!

...Соңнан күпме үткелләрне кичтек! –
Кемнәр кайда? Дөнья ни хәлдә?
Син әйткәнчә, бөек идеаллар
Одеалга калды бит, хәлфә!

Уразмәтнең ак буранлы төне...
Кем йокысыз йөри төн ката:
– Торыгыз! Тор! Йоклар чакмыни?! – дип,
Шагыйрь безне кереп уята.

Уята да... Мөслим түрендәге
Адашкан бер төнге авылда
Кар давылы дулый шигырь булып,
Әврелә шигырь давылга.

Бар иде бит безнең җанда өмет!
Алда гел яз сыман тоелды –
Ниләргә соң өзелделәр юллар,
Каршыбызда упкын убылды.

Кая гына барып чыктык, хәлфәм,
Инде кая барыйк, илдәшләр?
Без барасы юллар юкка чыкты –
Юл өзеге безнең бу яшәү.

Без өметсез кара чорга кердек –
Дулый буран, ләкин ак түгел!
Инде үзем үрсәләнәм бүген:
– Торыгыз, тор! Йоклар чак түгел!

Әйт, мөгаллим, ник чор чорсызланды?
Кара карлар ява күңелгә –
Аксакал һәм егет була белгән
Чын ир җитми бугай бу илгә...

Хәер, ник шагыйрьдән җавап сорыйм?
Болай да бит сыкрый пакь күңел.
...Уяныгыз, адәм балалары!
Торыгыз, тор! Йоклар чак түгел!

1991 ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

Шиһабетдин Мәрҗани
(1818-1889)

Шиһабетдин Мәрҗани. 1860-1870 нче еллар

Габдеррахман бине Исмәгыйль бине Гомәр әл-Хаҗитархани (Габдерахман Гомәри)[1] хатирәсе нигезендә әзерләнеп, «Безнең мирас» журналында дөнья күргән «Мәрҗани хәзрәтнең вафаты» (№5, 2020, Б.86-87) исемле мәкалә күренекле дин эшлеклесе, мәгърифәтче, тарихчы, этнограф, археограф Шиһабетдин Баһаветдин улы әл-Казани әл-Мәрҗанинең бакыйлыкка кичүе турында тәфсилле мәгълүмат бирә.

Бу юлы, бая телгә алынган мәкаләне тулыландыру йөзеннән, нигездә, «Җыен» нәшрияты чыгарган «Мәрҗани»[2] фәнни-популяр җыентыгына таянып, тагын берничә истәлек тәкъдим итәбез.

---

[1] Гомәри Габдерахман Исмәгыйль улы (1867-1933) – дин эшлеклесе, нашир, Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте. Тарихи һәм дин гыйлеменә караган әсәрләр, уку әсбаплары авторы.
[2] Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык («Шәхесләребез» сериясе). – Казан: Җыен, 2010. – 704 б.

Галимҗан Баруди[3] болай дип язып калдырган: «Мәрҗани хәзрәтләренә дә башлыча ашау-эчүдә чамасыз булудан һәм аеруча чәй яратучы адәмнәргә ирешә торган ашказаны шеше (рагы) иреште. Акрынлап ашавы азайды, ике-өч айдан соң урын өстенә ятып, васыятьләрен тәмам итеп, 1306 елның 28 шәгъбан аенда, милади белән 1889 елның 17 апрелендә ястү намазы алдыннан вафат булды. Җитмеш өч яшьлек ислам динендә картайган кеше иде. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун. (Дөреслектә, без Аллаһныкы һәм Аңа гына әйләнеп кайтабыз.) Шул сәгатьтә мәчеттә[4] ястү укыганыбыздан соң, Әбү Садыйк Сафа бине Галикәй[5] үлем турында хәбәр иткәндә, «мәүтүл-галими – мәүтү әл-галәми» сүзен искә алып, бик кайгыга төштем. Вакыйгага туры килгән «Галим үлгәндә галәм дә үлә» дигән фаҗигале җөмләне бу очракка муафыйк дип игътибар иттем. Шәгъбан аенда күздән югалып, 29 көнендә җеназасын зур төркем белән улы Борһанеддин Мөхәммәд әфәнде укып, Казанның Яңа зиратында үзе әзерләгән ихата эчендә күмелде. Рухы белән дә, җисеме белән дә җир йөзеннән юкка чыкты. Аллаһы Тәгалә аңа мәрхәмәтле булсын»[6].

Хәбибеннәҗар Үтәки[7] истәлеге: «Остаз мөхтәрәм Мәрҗани хәзрәтләре үлем хасталыгы вакытында 1889 ел апрелендә безне йортына чакырдылар. Остазның чакыруын уңыш дип белеп, тиз генә йөгереп бардым. Сәламнән соң ишарә ителгән урынга утырып, хәленнән аңлатып бирүне үтендем. «Хәлебез авыр, хастабыз бик куәтләнде, тормыштан өмет киселде», – диделәр. Гаять ябыккан, ястыкта көч-хәл белән ятар иде. Янындагы өстәлдә ике китап һәм кара савыт вә каләм бар иде. «Сезләр шул китапларны тотыгыз, бераз язачак сүзләрем калган. Хәзер язарга үземнең кодрәтем бетте», – диде. Әйтелгән китапны ачсам, «Мөстәфадел-әхбар»ның икенче томы булып, үз каләме белән язылган нөсхәсе иде. «Кәче Габделвәли мулланың биографиясе язылмый калган, миннән соңгылар аны йә язарлар, йә юк. Язылмаса, гомумән, дөньяга килмәгән кебек булыр, мин хатирәмдәге әхвален әйтеп торырмын, сез языгыз», – диде. Остазым әйткәнчә язып тәмам иттем.


الفصل الرابع میت لارنی یازار او چون

Шиһабетдин Мәрҗанинең вафаты турындагы язма (өстән беренче). Беренче җәмигъ (хәзерге Мәрҗани) мәчете метрикасы. 1889 ел

[3] Баруди (Галиев) Галимҗан Мөхәммәтҗан улы (1857-1921) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Җәдидчелек хәрәкәте идеологларыннан берсе.
[4] Галимҗан Баруди бу вакытта Бишенче җәмигъ (хәзерге Галиев) мәчете имам-хатыйбы.
[5] Мәгълүмат табылмады. Шиһабетдин Мәрҗани шәкертләреннән берсе булуы ихтимал.
[6] Шунда ук. – Б.397.
[7] Үтәки Хәбибеннәҗар Мөхәммәткяфи улы (1860-1921) – дин белгече, Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте. Уфа губернасының Эстәрлетамак өязендәге Үтәк авылы мөдәррисе. Хезмәтләре исламиятнең төрле өлкәләренә карый.



Шиһабетдин Мәрҗани кабере. 2017 елга кадәр

Шиһабетдин Мәрҗани кабере. 2017 елдан соң

Ләкин вафаты датасы хәтеренә килмәде. Яткан көенчә язуымны алып карады, яхшы булган икән, дип, язуыма канәгать хасил иттеләр. Шулай ук бер кечкенә рисалә биреп: «Бу рисалә Сими [Семипалат] шәһәренең әхвален бәян итеп, әлеге шәһәрнең абруйлы кешеләреннән Вәлиәхмәт ахун үземнең соравыма нигезләнеп язып җибәргән иде. Сез бу рисаләне алып кайтыгыз һәм шушы русча китапны да алып кайтыгыз. Мин «Мөстәфадел әхбар...»да әхвальне ислам тарихына муафыйк иттем. Бу рисаләдә милади белән язылган. Сез исә елларны һиҗригә кайтарыгыз. Бу рисаләнең эчтәлеген дә минем «Мөстәфадел-әхбар...»ым стиленә муафыйк итеп языгыз. Ләкин сезгә елларны һиҗригә күчерү авыр булыр, әнә шул рәвешчә китаптан карасагыз, сезгә күчерү җиңел булыр һәм дә Сими (Семипалат) әхваленең ахырына Каргалы әхвален языгыз. Аңа әзерлек миндә юк, аны Гомәр хәлфәдән сорап алырсыз, гомуми сурәттә булса да язылсын. (Гомәр хәлфә Дәүләтьяровны күз алдында тота, чөнки Гомәр хәлфә Мәрҗани хәзрәтләренә юлыгып, уңай мөнәсәбәтен белдергән иде.) Мин дигәнчә язып, тәмам иткәннән соң, рисаләгезгә «Мөстәгадәте тәммәтил-лимөстәфад» диеп исем биреп һәм мин язарга кушканны китапның баш тарафына язып, «Мөстәфадел-әхбар...»ның ахырына өстәп куеп бастырырсыз», – диделәр. Мин исә Сими әхвален тизлек белән язып тәмам итсәм дә, Каргалының әхваленнән мәгълүмат алынмаганлыктан, рисалә тәмам итү һаман кичекте. Ул вакытларда «Мөстәфадел-әхбар...» басылып, минем бу рисаләм керми калды. Мөхтәрәм остаз ошбу вакыйгадан ике көннән соң якшәмбе көн, кояш баткан вакытта вафат булып, рухны Аллаһыга тәслим әйләделәр. Рәхимәһуллаһү. [Аллаһы Тәгалә аңа мәрхәмәтле булсын!]»[8].

[8] Шунда ук. – Б.485-487.

Шәһер Шәрәф[9] язмасыннан: «Мәрҗани хәзрәтләре җитмеш яшьләренә кадәр укыту, китап язу вә халыкка хезмәт итү илә мәшгуль булды. Олуг тәвәккәллек вә ныклык иясе булган ошбу мөхтәрәм зат, һәртөрле киртәләргә карамыйча, хезмәтендә дәвам итеп, ошбу вакытка ирешкәндә, байтак картайган, нервларына да табигый хәлсезлек килә башлаган иде. Болар өстенә, аерым бер вакыйганың да тәэсире булды. Үзенең иң сөйгәне вә яхшы алмаш булуына өмет иткән Мәхмүд исемле галим бер улы вафат булды. Бу вакыйга ошбу мөхтәрәм галимебезне зур кайгыга дучар итте. Гомеренең соңгы ике-өч елында, табигатенә байтак үзгәрү вә зәгыйфьлек килеп, күбрәк Коръән укып, фарсыча шигырь җыентыкларын укып вакытын уздыра башлаган иде. Соңгы елында, ашказанына зәгыйфьлек килеп, ашау-эчүе азаеп, хәлсезләнеп, табибларга еш мөрәҗәгать итә башлаган иде. Фәкать никадәр хәлсезләнсә дә, һаман китап карап вә язып та утыра, вафатына алты ай кала элек «Мөстәфадел-әхбар» китабының икенче өлешен язып тәмамлаган иде.

Бу вакытлардан соң ашау-эчүе көннән-көн азаеп, үзе дә гомеренең ахыры якын булганын сизә башлаган иде. Вафатына өч ай кала язган бер хатында ошбу сүзләрне яза: «Бисмилләһир-рәхмәәнир-рахиим. Газиз, кадерле вә мөхтәрәм шәкертебез Хаҗ әл-Хәрәмәйн әш-Шәрифин мелла Гобәйдулла[10]… Мин бик картайдым. Саулыгым да юк. Яшем җитмеш бишкә кереп җитә. Көннән-көн зәгыйфьләнәм. Бернәрсә ашый алмыйм. Моннан ары хат яза алуым да мәгълүм түгел. Хуш, сәламәт булыгыз. Безгә хәер-дога кылыгыз. *Улсәм, каберемә бер таш яздырып куй. Бик кечкенә, бер-ике кеше генә күтәреп китәрлек булмасын һәм рус сүзе, рус елы куелмасын. Вәссәләм.* Шимбә көн, 23 җөмадел-әүвәл, 1306 (25 гыйнвар, 1889)». Бу вакытларда никадәрле начарга таба барса да, һаман эшендә дәвам итә, мәдрәсәсенә барып дәрес укыта иде. Вафатына ай ярым калганда, авыруы тагын да куәтләнеп, өеннән чыга алмаслык хәлгә килсә дә, дәрестән тукталмады. Шәкертләрне өенә чакыртып дәрес укытты. Бу вакытларда төрле табиблар килеп, хәлне тикшереп торганда, дәваларның бераз тәэсире булса да, хәле көннән-көн начарлануда, ашавы азаюда иде. Ләкин хәле никадәр авыр булса да, акылы таза булып, хасталыгы китап укудан туктатмый, үзенең хәлен белергә килүчеләр илә җитди вә мөһим мәсьәләләрдә сөйләшер иде. <…>

Мәрҗани хәзрәтләре гомеренең ахыр минутларына кадәр гыйлем һәм хакыйкать кайгысында булган. Вафат булачак көнендә хәл белергә кергән бер төркем укымышлыларга тәфсир китаплары хакындагы фикерләрен әйткән.

Мәрҗани хәзрәтләре вафат көннәре, вафат сәгатьләре якынлашканда үзе күп Коръән укый, тәкбир әйтә һәм: *«Коръән мәгънәләре җиңеллек бирә»,* – дип, янында Коръән укыта иде. Ниһаять, 1306 ел, 29 шәгъбан/1889 ел, апрель 18дә вафат булып, Казан зиратына җирләнде. Үлгәндә иң соң сүзләре дә *«Аллаһ Раббәна вә Раббилгаләмин»* һәм *«Бәл лилләһиләмри җәмигуһа»* аяте Кәримәләре булган.

Мәрҗани хәзрәтләренең вафаты сәбәпле халкыбызга зур кайгы килгән. Һәркем аның вафаты илә гыйлеменә, кичерешенә, аңына яраклы рәвештә кайгыга дучар булган»[11].

Шиһабетдин Мәрҗанинең кабер өстенә, үз васыяте буенча, зур, матур таш куелган. Туган һәм үлгән даталары һиҗридә бирелгән. Галим Айдар Гайнетди-

[9] Шәрәф Шәһреддин (1877-1938) – җәмәгать һәм дин эшлеклесе, язучы, педагог. 1899-1919 нчы елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә мөгаллим. Хезмәтләре Ш.Мәрҗани иҗатына, гарәп шигырьләре төзелешенә карый.

[10] Мәгълүмат табылмады.

[11] Шунда ук. – Б.191-193.

нов укыганча[12], гарәп имласы белән татар һәм гарәп телләрендә мондый сүзләр язылган:

Алгы як:

1) «Мәрхүм Шиһабеддин бине Баһаэддин
2) Мәрҗани
3) хәзрәтләринең җәмегъ итдеге асаре
4) фазыл вә кәмалинә борһан катыйгдыр бәлдәи Казанда
5) кырык сәнә микъдары ләвазиме имамәт вә нәшре голүм идеб
6) 1306 сәнә һиҗрийиә шәгъбан мөбарәкнең ахыр йәүмендә
7) 73 синнендә иртихаль даре бәка әйләде рахимәһүллааһү Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ».

(Мәрхүм Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани хәзрәтләренең әсәрләре – аның фазыйләтенә (дан-дәрәҗәсенә) һәм камиллегенә дәлил. Казанда кырык ел буе имам булып торды һәм гыйлем таратты. Һиҗри 1306 елда мөбарәк шәгъбан аеның соңгы көнендә 73 яшендә бакыйлыкка күчте. Аллаһы Тәгалә аны киң рәхмәте белән ярлыкасын.)

Уң як:

1) «Нәзым
2) әл-мәүтү фииһи күллүн-нәәси йәштәрикүү
3) вә ләә сүүкатүн йәбкаа вә ләә мәлик».

(Шигырь. Үлем алдында һәркем тигез: гади халык та, мәликләр (патшалар) дә.)

Сул як:

1) «Нәзым
2) ә-ләә иннәмәәд-дүнйәә кә-зыйлли сәхәәбәтин
3) әзалләткә йәүмән сүммә ганкә идъмәхалләт
4) фә-ләә тәккә фәрхәәнән биһәә хиинә әкъбәләт
5) вә ләә тәккә җәзәгаанән ләһәә хиинә вәлләт».

(Шигырь. Хактан да, бу дөнья болыт күләгәсенә бәрабәр: бүген ул сине күләгәсендә тота, аннары юкка чыга. Ул килгәнгә куанма һәм ул киткәнгә сагышланма.)

Арткы як:

1) «Мәшһәдүл-имәәми галләәмәтил-гаалими
2) саахибит-тәсаанииф-
3) -ил-фәәикати вәт-тәхкыйкаатир-рааикати Шиһабеддин бине
4) Баһаэддин әл-Мәрҗани иртәхәлә иләә рахмәти
5) Раббиһи тәгаммәдәһү Сүбхәәнәһү би-гафвиһи вә кәрамиһи гашийиәтә йәүмил-әхәди
6) ли-ләйләтин бәкыйиәтин мин шәгъбәәнин сәнәтә 1306
7) ситтә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәтин минәл-һиҗраһ».

[12] *https://zen.yandex.ru/media/id/5eeb7eb6e0d57b0e43ff4624/mogilnyi-pamiatnik-shmardjani-5f3ad002d5b95b33cf519fac.* – Мөрәҗәгать итү вакыты: 23.09.2021.

(Имам, күренекле галим, гүзәл язмалар һәм хезмәтләр авторы Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани кабере. Һиҗри 1306 елда, якшәмбе кич, шәгъбан ае бетәргә бер көн кала Яралтучысы хозурына иреште. Аллаһ аны кичерсен һәм бүләкләсен.)

Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең каберенә беренче ташны Гобәйдулла (алдарак телгә алынган Хаҗ әл-Хәрәмәйн әш-Шәрифин мелла Гобәйдулла) исемле шәкерте куйдырган.

«Мәрҗани» җыентыгында урын алган язмасында Борһан Шәрәф[13] болай дип искәртә: «Шиһаб ахунның кабер ташы берничә заманнар Казан зиратында иң гүзәл таш булып торган иде. Инде таш өстендәге тулы айның алтыны бетеп, бөтенләй кызганыч хәлдә калган. <…> Казан халкы Шиһаб ахун каберенә тиешенчә хатирә ясый алмыйлар. Аның ташын да төзәттермиләр. Мәрхүм үзе кабер ташларының кадерен бик белүче, аларны эзләп сәфәр чыгучы, һәммәсен дикъкатьләп билгеләүче булган»[14].

Шиһабетдин Мәрҗанине тулган ай белән чагыштыру бөек шагыйрь Габдулла Тукайда да бар:

«Кирәк булса, әйтеп бирәм: ул – шәп хәзрәт,
Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,
Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт».

Соңрак Шиһабетдин Мәрҗанинең кабер ташы берничә тапкыр реставрацияләнә. Нәүбәттәге яңарту эшләре 2017 елда башкарыла. Шунда ук, ни сәбәпледер, һәйкәл очындагы тулган ай ак һилалга алыштырыла.

Әдәбият:

1. *Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык («Шәхесләребез» сериясе). – Казан: Җыен, 2010. – 704 б.*

Текстны журналга
***Рүзәл Мөхәммәтшин** әзерләде.* ■

Шиһабетдин Мәрҗани һәйкәле. 2019 ел

[13] Шәрәф Борһан (1883-1942) – җәмәгать эшлеклесе, язучы, нашир, педагог. 1899-1905 нче елларда «Мөхәммәдия» (Казан) һәм 1909-1918 нче елларда «Хөсәения» (Оренбург) мәдрәсәләрендә мөгаллим.
[14] Шунда ук. – Б.571-572.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

МОРАТОВ САЛИХ (1896-1938)

Менделеевск районының Бондюг заводы бистәсендә туган. ТАССР прокуроры урынбасары, юрист, эшләрне татарча алып бару контроле буенча комиссия рәисенең урынбасары.

Салих Моратов – репрессия корбаны. Ул 1938 елның 9 маенда атып үтерелә, 1957 елда исеме аклана.

МОСТАФИН МӨСӘГЫЙТ (1909-1941)

Татар язучысы. 1909 елның 25 сентябрендә Татарстанның Баулы төбәгендәге Бәйрәкә авылында ярлы игенче гаиләсендә туган.

Ул 1941 елның 8 августында үзе теләп фронтка китә һәм шул ук елның 6 декабрендә батырларча һәлак була.

МӨСАННИФ ФӘЙЗИ (1904-1938)

Кырымтатар мөгаллиме. Кырым АССР наркомы. Кырымның Бакчасарай төбәгендәге Гөлембай авылында мөдәррис гаиләсендә туган.

1937 елның 14 июнендә кулга алына һәм 1938 елның 17 апрелендә атып үтерелә. Кабере билгесез. 1958 елның 25 ноябрендә исеме аклана.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

МӨСЛИМОВ ХӘМИТ (1916-1944)

Совет-Синцзян сәүдәгәрләр мәркәзе хезмәткәре. 1916 елның 17 декабрендә Кытайдагы Колҗа каласында татар сәүдәгәре гаиләсендә туган. Ул Уластай таулары арасында Кытай баскынчыларына каршы партизанлыкта була.

Хәмит Мөслимов 1944 елда Нылкы шәһәрчеге өчен барган сугышта һәлак була һәм Колҗада җирләнә.

МӨСЛИМОВ ФАТИХ (1905-1975)

Гаскәри. СССРда Кызыл Армиядә хезмәт итә. Кытайга күченеп килә. 1950 нче елларда Кытайдагы Нылкы өязенең башлыгы булып тора. 1970 елда Или төбәгенә күченә. Күрсәткән батырлыклары өчен Фатих Мөслимовка «Шәркый Төркестан Республикасының Халык Каһарманы» исеме бирелә.

Ләкин ул, рәхимсез режимнан качып, Казакъстанга чыгарга мәҗбүр була. Фатих Галим улы Мөслимов 1975 елда Алма-Атада вафат була. Алма-Атада аңа мәрмәр сын куелган.

МОРТАЗИН МӨХӘММӘТФАТИХ (1875-1938)

Журналист, мәгърифәтче, «Икътисад» газетасы (1908-1913) наширы һәм редакторы. Самара мәчетенең имам-хатибы. 1875 елда Сембер өязендәге Сөендек авылында туган.

Әләкчеләр, шымчылар язуына таянып, Мөхәммәтфатих хәзрәтне органнар өч тапкыр (1932, 1937, 1938 нче елларда) кулга алып, зинданга яба. Өченчесендә (1938 елның 14 мартында) Мөхәммәтфатих Шиһабетдин улы Мортазинны НКВД базында (подвалында) атып үтерәләр. 1956 елның 5 октябрендә исеме аклана.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

Колач киңлеге, ният ихласлыгы

Миркасыйм Госманов, Татарстанның Фәннәр Академиясе академигы

Беренче рәттә сулдан: Әбрар Кәримуллин, Мөхәммәт Мәһдиев; икенче рәттә: Нил Юзиев, Равил Фәйзуллин, Миркасыйм Госманов, Разил Вәлиев. 1991 ел

«Стиль – шәхес ул» дигән мәгълүм гыйбарә бар.

Әйе, кешенең, аерым шәхеснең, димәк, эшчәнлек алымнары белән иҗатның да эчтәлеген, үзенчәлеген, мәгънә һәм хасиятен чагылдыра ул стиль дигән нәрсәбез. Сүз монда, әлбәттә, «тел-стиль» дигән таррак, хосусый мәгънәдә генә түгел, бәлки, эш-гамәлнең нәтиҗәләре, сыйфаты хакында да бара. Моның шулай икәнлеген дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең, әдәбият вә сәнгать әһелләренең гамәлләре мисалларында күзәтергә, күрергә мөмкин.

Артык киң җәелмичә, бары әдипләребезнең иҗатларына, омтылган ниятләре белән тормышка ашырган гамәлләренә күз салсак та, тудырган әсәрләрендә (шул иҗат җимешләренең киң мәгънәдәге стильләрендә – эчтәлек белән гәүдәләнеш, яңгыраш белән интонация рәвешләрендә дә!) аларның һәрберсе үзенчә, үзләренә генә хас сыйфатларга ия икәнлеген күрәбез. Үз юлларын, үз йөзләрен тапканнары, димәк, мөстәкыйль фикергә ия булганнары бер-берсен кабатламый.

Моның шулай икәнлеген әдип һәм дәүләт эшлеклесе Разил Вәлиевнең гомум иҗтимагый-сәяси эшчәнлегендә һәм әдәби иҗатында күрергә мөмкин.

Разил хакында сүз чыкса, берәүләр аны – иң элек актив җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, икенчеләре – мәдәниятебез өлкәсендә күренекле җитәкчеләрнең берсе (әйтик, зур китапханә башлыгы), өченчеләре – роман һәм повестьлар, сәхнә әсәрләре язучы әдип, дүртенчеләре исә гел шагыйрь, ягъни әйбәт җыр текстлары авторы буларак күз алдына китерә. Үзенә билгеле сыйфатларына басым ясап, үз фикерен раслый. Мондый төрле фикердәгеләрнең һәрберсе үзенчә хаклы. Ләкин, аерым-аерым алсаң, фикерләре берьяклы.

Бер каләмдәшем белән сөйләшеп утырганда, ул Р.Вәлиев эшчәнлегенең, иҗатының күпкырлылыгына игътибар итте. Кайбер әдәби әсәрләрнең жанрын ачыклауда бетми торган бәхәсләр булган шикелле, бу иҗатның төп юнәлешен билгеләүдә дә тиз генә уртак тел табуы кыен икән. Әңгәмәдәшем кайбер башлап язучы, ягъни гел эзләнүче яшь авторларның гамәлләрен искә төшерде. Мин исә: «Аның эшчәнлек, иҗат юнәлешләренең кайсылары башкаларына караганда отышлырак, сыйфатлырак та, кайсылары кайтышрак, «пешеп җитмәгәнрәк?» – дигән сорау бирдем. Әңгәмәдәшем өзеп кенә җавап бирә алмады. Гәрчә «бәйләнерлек» моментлар булса да…

***

Разил Вәлиев турындагы беренче фикерләрне мин 70 нче еллар ахырында Аяз Гыйләҗевтән ишеткән идем. Ул, Чаллыга барып кайткач, анда Язучылар оешмасының бүлеге эшләве, аның җитәкчесенең оештыру эшләрен гаҗәп әйбәт алып баруы, Разил Вәлиевтән киләчәктә өметле җитәкче чыгу ихтималы хакында сөенеп, канатланып сөйләгән иде. Аяз әкәнең мавыгучан кеше икәнлеген белсәм дә, аның кешеләрдән кемнең кем икәнлеген аера белүен дә таный идем.

Әйе, Разилнең оештыру эшләренә сәләтле икәнлегенә тиздән үземә дә инанырга насыйп булды. (Аның Казанга килеп, җимерек хәлгә төшкән шәһәр китапханәсен төзәтә-төзәтә үстерү, яңа бүлекләр өстәлгән Милли китапханәгә әверелдерү процессын миңа, шул яңартылган китапханә киңәшчеләреннән берсе буларак, якыннан күзәтергә туры килгән иде.)

Депутат сыйфатында аның рухи-мәдәни мәнфәгатьләребез өчен ничек тырышуы, Дәүләт Советында катлаулы комитетларның берсенә җитәкчелек итүе хакында сөйләп тормыйм. Иҗтимагый тормышыбызга битараф булмаган кешеләр моны яхшы беләдер дип уйлыйм.

Разил үзенчә бер матур стиль белән эшли, ул кабаланмыйча, тавыш-мазар чыгармыйча, башкаларны да җайлы рәвештә эшләтә алу осталыгына ия. Милли китапханәдә оештырыла торган гыйльми конференцияләр һәм башка төрле чаралар «майлап куйган» кебек гармонияле, югары дәрәҗәдә уза иде.

Аның эш стиле, яңалыклар тудыра алу сәләте белән якыннанрак танышырга да туры килде. Разил Вәлиев һәм Дамир Сираҗиев белән бергә «Җыен» фондын оештырдык. Иң элек милли тарихка караган, мәгәр онытылырылган китапларны чыгару юлын сайладык. Разил монда да инициаторларның берсе булды. Аның идеясе белән Михаил Худяков, Карл Фукс, Һади Атласи һәм Исмәгыйль Гаспринскийларның китаплары яңадан дөньяга чыкты. Берничә мәртәбә авыр кризиска очраган фондыбыз хәзер дә яшәп килә. Илһам Шакировның 70 яшьлегенә багышланган мәгълүм китап та Разилнең тәкъдиме һәм якыннан катнашы белән дөньяга чыкты.

Кешеләрдә Р.Вәлиевкә карата ихтирам хисе уята торган бер сыйфат аның ярдәмчел булуыннан гыйбарәт. Ярдәмне ул ихлас күңелдән күрсәтә. Мондый ха-

сият, минем фикеремчә, аның гармонияле мөнәсәбәтләргә омтылуыннан булса кирәк.

Разил Вәлиевнең миңа иң ошаган тагын бер сыйфаты бар, ул – аның, нинди зур дәрәҗәләргә ирешсә дә, һаман үз йөзен саклап кала алуы, кеше, шәхес буларак мөгамәләләрдә үзгәрмәве. Бу сыйфат кайберәүләрнең югарырак үрмәләгән саен ваклана, кәрләләнә баруы фонында ачыграк күренә. Разил исә һаман шаяра-көлә һәм көлдерә белү сәләтен дә үзгәртмәде. Җор теллелеге, тапкырлыгы, җитди мәсьәләләрне дә көлкелерәк яктан күрә һәм күрсәтә алуы кайвакытта кыенрак эшләрне дә шактый җиңел юл белән хәл итүгә мөмкинлекләр тудыра. Мәсәлән, моннан берничә ел элек Дәүләт Советында бюджет мәсьәләләре карала. Мәгариф һәм мәдәният эшләре өчен акчаны елдан-ел азайтып, сыгыптамызып кына бирүне алга сөрә торган түрәләребез бу юлы да калдык-постык белән канәгатьләнергә кирәклеген белдерә. Бәхәснең соңгы өлешендә депутат Р.Вәлиев, якынлашып килүче зур дини бәйрәмне искә төшереп: «Ичмасам, ураза ае хөрмәтенә фитыр сәдакасы рәвешендә булса да, китапханәләргә бераз бирегез инде!» – дип инәлә. Зур җитәкчебез исә, хөкүмәт башлыгына карап: «Ярар, фитырын тизрәк бирегез! Юкса тагын әллә нәрсәләр сорый башлар», – дип көлә һәм мәсьәләне шулай уңай хәл кыла (күрәсең, ул зәкят кебек җаваплырак мәсьәлә турында сүз чыгу ихтималын исәпкә алгандыр…).

Ниһаять, аның тагын бер сыйфаты хакында әйтмичә кала алмыйм. Аның яратмаган кешеләре, каләмдәшләре бар. Әмма ул алар хакында бервакытта да «авыз чайкап», әләк оештырып йөрмәс. «Ярар, яши бирсеннәр әле шунда», – дигәндәй, өметсез рәвештә кул селтәү белән канәгатьләнер. Дөрес, аралашып та йөрмәс.

***

Разил Вәлиевнең эш-гамәл стиленә болай киң тукталуым һич тә очраклы түгел. Аның табигатенә хас бу сыйфаты – күпкырлылыгы – иҗатында да чагылыш таба.

«Иске сәгать дөрес йөри» дигән китапка кергән чәчмә әсәрләрдә, минемчә, бер зур мәсьәлә үзәктә тора. Мин аны шәхеснең һәм, гомумән, кешеләрнең тормыш гармониясенә омтылу мәсьәләсе дип, гомумиләштереп билгеләр идем. «Мин кыламын сигез, Ходай кыла тигез» дигән әйтемдәгечә, гармониягә (гади генә итеп әйтсәк, бәхеткә) һәркем үзенчә омтыла, ләкин уза алмаслык киртәләргә, каршылыкларга очрый. Чөнки эшләр син теләгән, омтылган рәвештә генә бармый икән.

Язучының беренче проза әсәре булган «Эт кояшы» повестенда ук әлеге катлаулы, чишелеше авыр мәсьәлә үзәккә куела. Гәрчә әсәр 1968 елда, социалистик реализм тәгълиматы ажгырып торган (аныңча бөтен катлаулы проблемаларны да билгеле көчләр «җитәкчелегендә» хәл кылып була дип, катгый рәвештә ышандырып килгән) чорда ук иҗат ителгән булса да, мәсьәлә көтелгәнчә (өйрәтелеп килгәнчә!) түгел, бәлки, башкача хәл ителә. Ягъни эшләр өстән төшерелгән кагыйдә, барлык кешеләр өчен дә «ярарлык» бер рецепт буенча түгел, ә гадәти тормыштагыча бара икән. Ирекнең гамәлләре әлеге соцреализм өйрәткәнчә башланса, Әминәнеке исә башкачарак очлана. Чөнки аерым кешене кызгану хисе генә мәсьәләне хәл итми. Нәтиҗә – катастрофа. Юкса бит һәр икесенең дә бәхеткә хаклары бар иде…

Кеше-шәхеснең тормыштагы урыны, аның үз урынын табу мәсьәләсе, гадирәк итеп әйткәндә, гармонияле көнкүрешкә, ягъни бәхеткә хокук темасы Р.Вәлиевнең икенче әсәрендә тагын да киңрәк, кискенрәк рәвештә яктыртыла. Әсәр үзәгендә шәһәрдә чакта ук үз ишләре, бергә укыган, төрлечә аптыраш хәленә төшкән са-

бакташ дуслары белән дә уртак тел, аңлашу таба алмаган, гел җыр-музыка иҗат итү уе белән хыялланып та, бернәрсә майтармаган, хәтта гаиләсе дә әллә ничек көтелмәгәндә таркалган музыкант Искәндәр образы тора («Иске сәгать дөрес йөри»). Аптыравы соңгы чиккә җиткәч, ул, кинәт поездга утырып, әллә кайларга, «соңгы станциягә кадәр» китеп бара.

Баксаң, бу тормышта үз урыннарын таба алмыйча интегүчеләр бер ул һәм аның сабакташлары гына түгел, купедагы төрле яшьләрдәге юлдашлары да шундый ук хәлдәге кешеләр икән. Шабашниклар хәлендәге әлеге алаканатларның берсе барасы җиренә өстерәлеп, үрмәләп кенә булса да җитү хакында өмет итсә, икенчесе («көндәлдәге бушлыкны тутырыр өчен» егылып эчүче Мотыйк исемлесе) барып баш саласы урынның да үзенеке икәнлегенә ышанмый.

Искәндәр дә телеграммадагы анык булмаган адрес буенча «Якты юл»га таба бара шикелле. Тик барып җитә алырмы икән ул?..

Әсәрдә исемнәре аталган Искәндәрнең дусларыннан бер Фидан гына, шәһәр читендә булса да, «әйбәт җиргә», азык-төлек складына мөдир булып урнашкан сыман. Аның янына килүчеләр, үзе горурланып әйткәнчә, башларын иеп керәләр дә, азык-төлектән бераз эләктергәч, бөгелә-сыгыла рәхмәтләр әйтеп китәләр икән (элекке чорның типик күренеше). Ишеге дә күп вакытта эчке яктан бикле була Фиданның. Тик барыбер аның да күңеле тыныч түгел, ОБХСС килү ихтималын белеп яши...

Дуслар белән Яңа ел каршылар өчен әйбәт эчемлек, затлы ризык эзли-эзли килеп чыккан Искәндәр бернәрсә дә алмыйча китеп бара. Әйе, кеше-инсан дигән һәм бөек, һәм бер үк вакытта бик кечкенә затның башына төшкән, гел төшеп тора торган проблемалар менә шундый, бер карауга әһәмиятсез булып тоелган чынбарлыктан, теләк-омтылышларның реаль киртәләргә бәрелүеннән гыйбарәт икән.

«Язучы тарафыннан үз геройларын шулай трагик рәвештәрәк сурәтләүгә нәрсә сәбәп булган?» – дигән сорау тууы ихтимал. Минемчә, сәбәп һәр ике повесть геройларының, реаль тормыш җирлегеннән аерылып, тормыш тәҗрибәсе белән традиция дигән нәрсәләрне санга сукмыйча яшәүләренә барып тоташа булса кирәк.

Тормышны бизәп-шомартып түгел, бәлки, реаль чынбарлыктагыча кырыс дөреслек белән яктыртырга теләгән авторның мондый уй-фикерләре, ышанычы, иманы «Мирас» романында да киң планда яктыртыла. Әсәр эчтәлеген, җыеп әйткәндә, нәкъ менә шул кеше, кешеләр һәм, гомумән, җәмгыять тормышында элек-электән килә торган яшәү үзенчәлеге, эш-хезмәт тәҗрибәсе, туган тел вә җырлар, гореф-гадәт мәсьәләләре һәм, ниһаять, туган-җиргә, үз кавеменә, халкына, аның узганы белән бүгенгесенә, киләчәгенә карата мөнәсәбәт мәсьәләләре тәшкил итә. Шул мәсьәләләр тирәсендә үзенчәлекле бирелешләр, конфликтлар туа, кайберләре азмы-күпме дәрәҗәдә җиңел чишелсә, икенчеләре шул килеш киләчәк буыннарга кала.

Бер карашка әсәрдә сүз узганнан калган күренешләрне, шул исәптән туган авылны, әби-бабайлар күмелгән зиратларны саклау-сакламау кебек мираска мөнәсәбәт хакында бара. Ләкин, минемчә, бүген безнең буыннар тудыра торган проблемаларның киләчәк буыннар өчен мирас булып калу мәсьәләсе дә күз уңында тотылган. Кыскасы, әсәрнең сюжеты да, эчтәлеге дә, күтәреп чыккан фикерләре дә катлаулы, әтрафлы һәм актуаль. Сүзне артык сузмас өчен, иллюстратив детальләргә генә игътибар итү белән чикләнәм.

Менә әллә ничә буын кешеләре яшәгән йортлар, урамнар, мәчетләр сүтелә, җимерелә; әнә әби-бабайлар, әти-әниләр күмелгән каберләр өстенә асфальт җәелә; менә кичә урам булган җирләр, су астында калып, сүтелмәгән капкалар күренеп тора; «урамнар»да исә аяк-куллары өзелгән курчаклар – элек гөрләп торган бала-чагалы гаиләләрнең символлары йөзеп йөри… Бер сүз белән әйткәндә, XX гасырның икенче яртысында күпчелегебез сокланып, горурланып кабул иткән үзгәрешләрнең, «зур казаныш» булган «гигант төзелешләр»нең серле көзгедәге кебек икенчерәк яктан чагылышы…

Әсәр үзәгендә өч буын вәкиле: җиткән егет (бала) Ихтыяр, атасы Тимерхан һәм бабасы Зыятдин. Өчесе өч чорга, хәтта өч иман-идеологиягә вәкаләтлек итә. Боларга авторның мөнәсәбәте дә үзенчәлекле. Элеккечә, соцреализм кушканча, гәрчә әсәр шул чорда ук (1983 елда) язылган булса да, автор аларның һәрберсенә карата «мәрхәмәтлелек күрсәтә», берсен күккә чөеп, икенчесен җиргә салып таптамый. Димәк, алар арасында багланыш эзлеклелеген күрергә тели, шул хакта уйлана. Укучыны да уйландыра. Нәтиҗәдә, билгеле бер карарлар, күрсәтмәләр өчен иллюстрацияләр әвәләүче фикерсез «йомышчы әдәби әсәр» кисәге түгел, бәлки, автор үзе дә нык уйланган, укучыны да уйландыра торган фикерле әдәби әсәр барлыкка килгән. Юкса бит ГЭСлар салыну, елгалар күтәрелү, «иске авыллар күченү», яңа йортлы «совет авыллары үсеп чыгу», күкрәккә суга-суга консерваторларны «фаш итеп», «яңа тормыш төзүчеләр»гә дан җырлау өчен менә дигән мөмкинлек бар иде.

Тик автор фикерле әдәбиятка таба борылган.

Әллә ни «мөгез» чыгармыйча, кырыс публицистик яки сатирик алымнарга бирелмичә язылган романда сүз, төптәнрәк уйласаң, узган чорлардан калган мирас хакында гына түгел, бәлки, киләчәккә бездән калачак мирасыбыз хакында да бара икән. Җилдән дә аласы энергияне җирдән эзләү, меңләгән гектар иң уңдырышлы җирләрне суга батыру, шулар нәтиҗәсендә күченү, тузыну һ.б. Ә киләчәктә әлеге уңдырышлы җирләрнең һәр кишәрлеге дә бибәһа булачак, тик табылмаячак. Тагын уйлана төшсәң…

***

Кырыс реализм алымнары, мәгәр чамалы сурәтләү чаралары белән язылган, ләкин кискен хөкемнәргә бирелмичә тудырылган чәчмә әсәрләрендә Р.Вәлиев менә шулай шактый күңелсез дип әйтерлек ситуацияләрне, манзараларны сурәтли. Бер сүз белән әйткәндә, үзен борчыган мәсьәләләр хакында укучыны да уйланырга мәҗбүр итә. Иҗатының бу сыйфаты белән безнең күз алдына җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев килеп баса. Узган чынбарлыктан тәмам аерылып җитмәгән, ләкин киләчәккә, зур үзгәрешләргә омтылган, аларның котылгысыз икәнлеген таныган сәясәтче Разил Вәлиев. Омтылыш-теләкләр белән реаль чынбарлык арасындагы кытыршылыкларны, дисгармонияне тоеп, белеп яшәгән, уйланган, фикер йөрткән каләм иясе…

Әмма, алдарак кат-кат әйтелгәнчә, Р.Вәлиевнең киң күңелле, ярдәмчел, җор телле, шаярырга яратучы көләч рухлы кеше икәнлеген дә беләбез. Аның бу сыйфаты, минемчә, җырларында ачык чагыла. Әгәр прозасында, шигырьләренең бер өлешендә тормыш-көнкүрешкә айнык (хәтта артык айнык) карашлы, күбрәк баш вә акыл өчен язучы әдипне күрсәк, сәхнә әсәрләре белән җырларында тормышның күңелле, кеше күңеленә якын якларын эзләүче, табучы, шулар өчен сөенүче шат рухлы замандашыбыз белән очрашабыз. Ул кешеләргә карата хәерхаһ, теләктәш.

Аларның һәрберсенең үз тормышларында лаеклы урыннарын табып, гармонияле шартларда яшәүләрен тели. Ихлас күңелдән тели. Шуңа күрә аның күпчелек җырлары җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителеп җырланды һәм әле дә җырланып килә. Кайчандыр иҗат ителгән «Дулкын»нан, «Бер алманы бишкә бүләек»тән алып Казанга багышланган көр күңелле соңгы вакытта язылган җырларына кадәр.

Разил Вәлиев җырларының уңышлы булуын төрлечә аңлатырга мөмкиндер. Мин исә мондый хасият аларның бик оста абстракцияләшкән булуыннан, шунысы белән гомумиләшеп, башкалар өчен дә уртак, димәк, һәр кеше өчен дә якын була алу сыйфатыннан киләдер дип уйлыйм. Ихтимал, Р.Вәлиев җырларының менә шундый үзенчәлеге, аларның якты романтизм рухындагы җылылык белән өретелгәнлеге (әйе, кырыс реалист прозаик Вәлиевтән җыр текстлары авторы Разил менә шул яктылыгы һәм җылылыгы, кешеләргә карата ихлас теләктәшлеге белән аерылып тора) аны бүгенге җыр текстлары язучыларның алгы сафына чыгаргандыр. Ул язган текстларның талантлы композиторлар тарафыннан көйгә салынуы да очраклы түгелдер. Матур халык көйләрен яңа текстлар белән актив репертуарга кайтару юлында да Разилнең уңышлары бәхәссездер.

Җыеп әйткәндә, Разил Вәлиев язган текстларның күпчелеге аның үз халкына биргән күңелле бүләкләреннән гыйбарәт булса, «Рухият» фонды тарафыннан нәшер ителгән, шагыйрьнең иң уңышлы, якты рухлы җырларын эченә алган «Ядкарь» китабын да җыр сөюче һәрбер кеше кадерле бүләк рәвешендә кабул итәчәк.

2007 ел ■

***Редакциядән:** Күренекле әдип, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе, журналыбызның редколлегия әгъзасы **Разил Исмәгыйль улы Вәлиев**кә 4 гыйнварда 75 яшь тулды. Каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!*

Ике хатирә

Айдар Хәлим

NEIN

Моны миңа Мостай Кәримнең сугыштан соңгы чордан җан дусты – драматург, атаклы «Тальян гармун» драмасының авторы Габдулла Әхмәтшин сөйләгән иде.

Габдулла агай сугышта Норвегия юнәлешендә штрафниклар взводы белән командалык итә. Аның ординарецы ике тапкыр хөкем ителгән, соңгы тапкыр хатынына кул яккан кешене сугып үтергән гаярь ир заты була. Габдулла агай ординарецын бер тапкыр увольнениегә җибәрә. Ике тәүлек уза, ә бу һаман кайтмый. «Ну, Әхмәтшин, моның өчен безнең үзебезне утыртачаклар», – ди комбат Немцов.

Ниһаять, ординарец, иңенә зур капчык күтәреп, блиндажга килеп керә. Аннан уймак кебек кечкенә буйлы, сары чәчле норвег кызын тартып чыгара. Бәләкәй генә булса да, атаклы снайпер иң мәргән атучылары икән. Хатын-кыз снайперлар батальонынннан. Иң оста, иң куркыныч снайпер булганы өчен ул «Медуза Горгона»[1] дигән исем йөрткән. Аларны һәр ун совет солдатын юк иткән саен күтәргәннәр, бүләкләгәннәр.

Снайпер кыздан сорау ала башлыйлар.

– Син кем?

– Nein[2].

– Сезнең частегыз кайда урнашкан? Частьта күпме хатын-кыз?

– Nein.

– Иптәш майор, рөхсәт итегез, мин аны хәзер Сезнең алдыгызда түшәккә салам! – ди ординарец.

– Юк, ярамый! – дип кычкырып җибәрә шулчак кыз саф урыс телендә. – Ярамый! Мин – кыз кеше!..

Аны ике автоматчы тылга озатырга чыккач, ул берсенең күзенә көл сибеп, икенчесен финка белән кадап үтерә. Ике арада атыш башлана. Шулай да ординарец аны ычкындырмый, «особист»ларга илтеп тапшыра. Кыз зур тәҗрибәле диверсант булып чыга. «Шушы батырлыгы өчен минем ординарецым Николай Васильевич Свибловка безнең дивизиядә беренче булып Советлар Союзы Герое исеме бирелде», – дип тәмамлады сүзен Габдулла агай Әхмәтшин.

1981

---

[1] Горгона — борынгы грек мифологиясендә чәч урынына елан үскән канатлы хатын-кызлар. Аларның карашыннан бар тере нәрсә таш булып каткан. Өч төрле горгоналар арасында бары тик Медуза гына үлемгә дучар. Башкалар үлемсез. Зевсның улы – каһарман Персей гына Медузаның башын чабып өзүгә ирешә.
[2] Юк (немец).

Чын милиционер

Шулай бер елны утыз тугызынчы бистәдә мәчет ачуда катнаштым. Җыелган кунаклар Татарстан Диния нәзарәтенең ул вакыттагы рәисе, мөфтие Госман хәзрәт, Чаллы мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт чапаннары эченә «тупланып», яңа мәчет бусагасы алдына менеп бастылар да, гүяки, ике өлешкә бүленеп, төзелешкә ярдәм күрсәткән өчен башта беренчеләре – икенчеләрен, аннан икенчеләре беренчеләрен мактап, бүләккә кәләпүшләр, кояшта ялтыр-йолтыр килгән шәһадәтнамәләр өләшә башладылар. Сүз боткасы шулкадәр куерды ки, хәтта җәмәгать үзенең ни өчен җыелганын да онытып җибәргән сыман тоелды. Бу эчпошыргыч манзара мондый бүләкләрне алырга тиешле бер милиция подполковнигына (фамилиясе Кәбиров бугай) килеп терәлгәч кенә туктады. Ул, бусагага атылган ядрә сыман очып менеп, кәләпүш белән елтыр кәгазьне кулына төшерде дә: «Мөселман халкына хезмәт итәм!» – дип честь бирде дә, башка бер сүз дә әйтмичә, шундый ук тизлек белән урынына басты.

Кояшта йокымсыраган җәмәгать бу фразаны исәпләп тә карамады. Әмма бу гыйбарә, вакыйган, шушы фраза гына минем хәтергә тантананың йөзек кашына тиң иң төпле чыгышы булып сеңеп калды.

Соңыннан чәй мәҗлесендә без подполковник белән янәшә туры килдек.

– Сез «Мөселман халкына хезмәт итәм!» дигән әйтемегез белән барча ораторларны гына түгел, татар язучыларының меңләгән китапларын сугып екттыгыз! Бу гениаль фраза. Рәхмәт! – дидем мин.

– Сез язучы мәллә? – диде ул, күзләрен шар ачып.

Инде күзләремне шар итеп ачарга чират минем үземә җиткән иде. Янәшәмдә китап укымый торган чын милиционер утыра икән.

– Әйе, – дидем мин, сер бирмичә. – Минем бер әсәремне дә укыганыгыз юкмы?

– Китапларыгыз да бармыни? Нәрсәләр өстендә эшлисез?

Нәрсәләр «өстендә» генә эшлим икән мин?!

Бу юлы инде мин көлеп җибәрмичә түзә алмадым. Хәзер ул аптырап карап торды. «Нәрсәләр өстендә эшләвемне» аңлату урынына мин аңа «Аргамак» журналында эшләгән чордан калган бер мәзәкне сөйләдем.

Шулай бер тапкыр без редакциядә яңа уен – иң тырыш китап укымаучылар ярышын үткәргәнбез икән. Анда китап укымау буенча беренче урынны – урындык, икенче урынны – укытучы, өченче урынны милиционер яулаган…

– Ә нигә алай? – ди бу, һич аптырамыйча.

– Урындык укый белмәгәнгә укымый. Укытучы, үзем дә күп беләм, дип укымый, ә милиционер, күп белгән кешене начальство яратмый, дип укымый…

– Менә монысы хак, малай! Менә монысы хак! – диде, ниһаять, подполковник. – Мин моны үземнән генә дә беләм. Үземнән күп сайраган подчиненныйларымны мин дә яратмыйм! Ә син миңа берәр китабыңны бирерсең әле. Укып карыйм. Ниләр майтарасың икән?..

2007

Редакциядән: *Күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе* ***Айдар Хәлим****гә (Борис Нәҗметдин улы Хәлимовка) 1 гыйнварда 80 яшь тулды. Аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!* ■

Истә, һаман да истә!

Шагыйрь Зөлфәтнең тууына 75 ел



Мәшһүр шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе (2000) һәм М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, 1973 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, 1998 елдан Халыкара ПЕН-клубның Татар-ПЕН үзәге әгъзасы Зөлфәт (Дөлфәт Госман улы Маликов) 1947 елның 3 гыйнварында Мөслим районының Иске Сәет авылында туган.

Төп басма китаплары: «Язмышлар ярында» (1971, кереш сүз авторы – Х.Туфан), «Утлы бозлар» (1978), «Адашкан болыт» (1990), «Ике урман арасы» (1995), «Йөрәгемне былбыл чакты» (1999), «Ходай сулышы» (2007).

Чын мәгънәсендә татар халык шагыйре булган Зөлфәт 2007 елның 15 маенда Казанда вафат булды.

Шагыйрь Разим Вәлиуллинның тууына 80 ел

Шагыйрь, композитор, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты (1995), 1997 елдан – Татарстан Композиторлар берлеге, 1999 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Разим Нәгыйм улы Вәлиуллин 1942 елның 3 гыйнварында ТАССРның Зәй районындагы Кәдек авылында туган.

Р.Вәлиуллин 1993-2003 нче елларда Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы сәркатибе вазыйфасын башкара. Унлап китап авторы.

Разим Вәлиуллин 2010 елның 27 сентябрендә Әлмәттә вафат булды һәм туган ягына алып кайтып җирләнде.

Актер Ирек Баһмановның тууына 90 ел

Актер, ТАССРның халык артисты (1982), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ирек Вәли улы Баһманов 1932 елның 6 гыйнварында Әлмәт авылында туган.

Ирек Баһманов гомеренең соңгы елларында «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев әсәре), «Арбалы хатыннар» (З.Зәйнуллин), «Ричард III» (У.Шекспир) спектакльләрендә уйнады.

И.Баһманов 2015 елның 23 ноябрендә Казанда вафат булды.

Рәссам Айдар Үтәгәновның тууына 75 ел

Рәссам, график, 1995 елдан Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге әгъзасы Айдар Мансур улы Үтәгәнов 1947 елның 11 гыйнварында Казанда туган.

1966 елда ул – Казан сәнгать училищесын, 1972 елда исә Мәскәү полиграфия институтын тәмамлый.

Шактый еллар матбугатта, аерым алганда, «Азат хатын» («Сөембикә»), «Ялкын» һәм «Салават күпере» журналларында эшли. Утызлап китапны бизәүдә катнаша.

А.Үтәгәнов 2005 елда Казанда вафат булды.

Публицист Хөсәен Ямашевның тууына 140 ел

Публицист, журналист, революцион хәрәкәт эшлеклесе Хөсәен Минһаҗетдин улы Ямашев 1882 елның 18 гыйнварында Казанда туган.

1905-1907 нче елларда ул Казандагы инкыйлаб вакыйгаларында катнаша. 1907 елда татарча беренче революцион мәсләкле рәсми «Урал» газетасын нәшер итә (рәсми мөхәррире – хатыны Хәдичә Ямашева). Газета тыелгач, ул 1907 елның маенда Казанга кайта.

Х.Ямашев 1912 елның мартында 30 яшендә кинәт вафат була.

Актер Зәйни Солтановның тууына 130 ел

Актер, режиссер, тәрҗемәче, ТАССРның халык (1939), РСФСРның атказанган артисты (1940), 1940 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Зәйни Солтанов (Зәйнелгабидин Гобәйдулла улы Сөләйманов) 1892 елның 30 гыйнварында Әстерхан шәһәрендә туган.

1914-1915 нче елларда ул – «Сәйяр» труппасы артисты.

Зәйни Солтанов 1918 елдан башлап даими рәвештә рус, совет һәм чит ил драматургиясенең иң яхшы үрнәкләрен татарчага тәрҗемә итә. Шулар арасында Н.Гогольнең «Ревизор» (1927), М.Горькийның «Тормыш төбендә» (1932), А.Чеховның «Юбилей» (1934) пьесалары бар.

З.Солтанов 1952 елның 5 маенда Казанда вафат була.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

«Кара карлыгач микән?» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Кара карлыгач микән?

(Татар халык җыры)

Сандугачым, әйт үземә,
Кайсы талга кунасың?
Күзем йомсам, күз алдымда
Торган кебек буласың.

Кушымта:
Кара карлыгач микән,
Сары сандугач микән
Аны үстергән әнкәсе? } *2 тапкыр*

Сандугачлар басып сайрап,
Сындырган гөлләремне;
Сынган гөлләргә охшатам
Аерылган көннәремне.
Кушымта.

Сандугачлар ияләшкән
Су эчәргә миләштән.
Кайгыларым бетәр иде,
Сине күреп сөйләшсәм.

Кушымта:
Кара карлыгач микән,
Сары сандугач микән
Аны үстергән әнкәсе? } *2 тапкыр*

Композитор Җәүдәт Фәйзи «Халык җәүһәрләре» китабында әлеге җыр турында кызыклы гына мәгълүматлар биргән. *«Мин бу җырны беренче мәртәбә 1925 елда Казанда ишеткән идем һәм ул «Наган көе» дип атала иде»,* –дип искә ала ул һәм аның бары утызынчы еллардан соң гына «Кара карлыгач микән?» дип атала башлавын әйтә. Аннары: *«Мин ишеткән беренче вариантында кушымта:*

Атма, бәгърем, наган,
Йөрәгем яна
Шул наганның тавышына, –

рәвешендә иде», – дип дәвам итә композитор. Ул *«Атма мылтык-наган, Куркам ла яман Шул наганның тавышына»* вариантын да китереп уза. Җәүдәт Фәйзи кушымта сүзләреннән чыгып, көйнең ниндидер бер фаҗига уңае белән чыгарылган булуына да басым ясый: *«Үзем бу турыда шуны ишеткән идем. Имеш, егерме өченче еллар тирәсендә бер егет Кабан күле буендагы ниндидер бер йортта туйда була. Шунда ул кызны да, кияүне дә атып үтерә. Икенче бер версия буенча, бу хәл Гражданнар сугышы вакытында булган, имеш. Бер хәрби кеше, үзенең сөйгәнен, көнләшүдән, атып үтерә».*

Композиторга өченче версияне революция ветераны Латыйф ага Гомәров сөйләгән була: *«1922-1923 нче еллар тирәсе. Мин Мамадыштан ат белән Казанга кайтам. Кучерым бик моңлы кеше булып чыкты. Гел җырлап кайта. «Наган көе»н мин беренче мәртәбә аңардан ишеттем. Көйнең тарихы турында да нәрсәдер сөйләде. Тулысынча хәтерләмим инде. Ниндидер бер начальник үзенең хатынынмы, сөйгәненме аткан, имеш».*

Җырчы, композитор, ТАССРның атказанган артисткасы (1939), ТАССРның халык артисткасы (1977), РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984), Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1990, үлгәннән соң) Сара Садыйкова (1906-1986)

«Бу җыр гади җыр түгел», – ди Җәүдәт Фәйзи. Аның ниндидер бер фаҗига уңае белән чыккан совет чоры бәете булырга тиешлеген, моны аның кушымтасы раславын, ягъни «Кара карлыгач микән, сары сандугач микән аны үстергән әнкәсе?» – юллары кушымта түгел, бәлки, бәетнең бер строфасыдыр диган фикерне әйтә. Көйдәге бер үк мотивның кабатлануы да «Кара карлыгач микән?»нең бәет булуын раслый, ди композитор һәм җырны совет чоры фольклорына кертә.

Әлеге җыр озак вакытлар халык җырчылары Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов репертуарында аерым бер урын алып торды. Бу җыр шулай ук җырчы сандугачыбыз Сара Садыйкова репертуарында да булган.

Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева) материалларына нигезләнеп, Ләбиб Лерон әзерләде. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

Көлке куа кила...

Гамил Афзал (1921-2003)

«Оланнар»

Кара эшне эшләмибез,
Безнең белем югары.
Чиста эштә эшләр өчен
Безнең һөнәр юк әле.

Бәбчегем, ди әни дә,
Оланым, ди әти дә;
Шулай булгач, нигә эшләп
Интегергә яшь көйгә?!

Без балалар бит әле,
Яшьлек көннәр бит әле;
Тәмәке тарта башладык –
Бу да һөнәр бит әле.

Гамил Афзал.
Зөлфәт Хәйруллин шаржы

Туфан Миңнуллин.
Илдус Әҗемов шаржы

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Зоологик хикәя

Иң соңгы булып ишеккә тагылган пассажирга трамвай йөртүче:

– Кая тыгыласың, сарык?! Миңа ишекне ябарга кирәк, – диде.

Арт чүмече трамвайга сыймыйча урам якта калган пассажир трамвай йөртүчегә:

– Нигә озак килми тордың, ишәк? Миңа эшкә барып җитәргә кирәк, – дип җавап бирде.

Трамвай эчендәге куяннар бу сөйләшүдән рәхәтләнеп көлделәр.

Гәрәй Рәхим
(1941-2021)

Без... саныйбыз
(Пародия)

Булат белән ятабыз,
Йолдызлы күккә карап.
Булат белән ятабыз,
Шул йолдызларны санап....
...Минеке йөздән артты,
Җиде йөздән, бер меңнән....
Бик күп лә бу йолдызлар,
Күпмелеген кем белгән?!

Роберт Миңнуллин

Булат белән ятабыз
Минем китапны карап.
Булат белән ятабыз
Шигырь юллары санап....

Җиде йөздән, бер меңнән...
Ике меңнән... Ун меңнән...
Бик күп лә шигырь юлы –
Гонорарын кем белгән?!



Гәрәй Рәхим.
Зөлфәт Хәйруллин шаржы

Тәлгат Нәҗмиев
(1950-2014)

«Расхудландык әле...»
(Саба мәзәге)

Театр билетлары сиксән тиен-бер сум, аракының шешәсе өч сум алтмыш тиен торган рәхәти вә ләззәти заманнарда берәү кысмыр гына күршесеннән сорый икән:

– Иртәгә спектакльгә барасызмы?

– Юк, бу арада бик расхудландык әле.

– Берәр зур әйбер алдыгызмы?

– Юк. Ике көн рәттән ике серияле индийский кинога бардык...

Роберт Миңнуллин.
Фәрит Вахитов шаржы

Роберт Миңнуллин
(1948-2020)

Чепуха китап

Роберт Миңнуллин китап кибетендә йөри. «Большая книга чепухи» дип аталган китап 647 сум тора.

Р.Миңнуллин уйлап куйган: «Бу китап чепуха булса да, бәясе чепуха түгел моның!»

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2022

Без барыбыз да – балачактан

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Рөстәм Мингалим (1937-2012)

Әтәч ни өчен өч вакыт кычкыра?

(Әкият)

Борын-борын заманда әтәчнең йон-каурыйлары бик тә зиннәтле, салават күпере кебек гүзәл булган. Аңа карап һәммәсенең күзе янган.

Ә тавис дигән кош ул чакта гади генә киенеп йөргән. Мактанчык әтәч аннан көлгән. Шуннан тавис бер хәйлә уйлаган һәм әтәч янына юл алган.

Тавис әтәчкә әйткән: «И җанарал әфәнде, и гүзәл әтәчкәй, ярдәм сорап килдем сиңа. Өйләнергә исәбем бар, киемеңне биреп торчы миңа. Әгәр анда озак торсам, таң атуга мине чакырырсың. Тавышың бик көчле һәм матур. «Китереп бир!» – дип кычкырырсың. Иртә белән кайтмасам, өйлә җиткәч кычкырырсың, өйлә җиткәч күренмәсәм, кич җиткәчтен кычкырырсың».

Тавис тәмле теле белән юмалап сораган. Әтәч киемнәрен салып биргән, каршы килә алмаган.

Иртәгәсен әтәч читән өстенә менеп кунган һәм: «Китереп бир! Китереп бир!» – дип кычкырган. Тавис китермәгән, күрәсең, ычкынган. Төш вакытында тагын кычкырган әтәч, тавис күренмәгән. Кич җиткәч тә кычкырган. Тавис юк та юк икән.

Шуннан бирле әтәч көн саен Тависка: «Китереп бир!» – дип кычкыра. Тавис килми дә килми.

Клара Булатова (1936)

Буран

Тышта буран котыра,
Әти өйдә утыра.
Әти өйдә, гаражда
Машинасы тик тора.

Әти:
– Кара буран, – ди, –
Шуңа күрә урамга
Чыга алмый торам, – ди.

Марс карый: урамда
Бөтен нәрсә ак кына...
– Әти белми... Бураннар
Кара булмый, ак була.

Читәнме, бүзме?

(Шаяру)

Сиздермичә генә арттан килеп, күзне каплыйлар да:

– Читәнме, бүзме? – дип сорыйлар.

Теге бала:

– Бүз, – дисә: «Бер чеметкәнгә түз!» – дип чеметәләр.

– Читән, – дисә: «Бер чеметәм дә китәм!» – дип, чеметеп китәләр.

Әдхәт Синугыл (1935-2004)

Балам, нигә җылыйсың?

(Бала юату)

Татлы ризык алларыңда,
Сайлап аша сыйлысын.
Балдан татлы бала чагың,
Балам, нигә җылыйсың?

Борчылырлык бернәрсә юк,
Хикәятләр тыңлыйсың...
Берәү сине кыерсытмый,
Нигә, балам, җылыйсың?..

Яннарыңда уенчыклар,
Алар белән уйныйсың...
Атаң-анаң – күз алдында,
Нигә, балам, җылыйсың?

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

ДЕКАБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Декабрьдә язучы, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты Локман Закирның «Мнение» дигән яңа китабы дөнья күрде.

● 3 декабрьдә «Казан утлары» журналы редакциясендә, язучылар һәм шагыйрьләр Марсель Галиев, Вакыйф Нуриев, Ләбиб Лерон, Айгөл Әхмәтгалиева, Ландыш Әбүдәрова, җәмәгать эшлеклесе һәм мөгаллимә Камәрия Хәмидуллина, редакция хезмәткәрләре һәм журналистлар катнашында, галим-математик-геометр, физика-математика фәннәре докторы (1997), Мәскәү дәүләт университеты профессоры, М.В.Ломоносов премиясе лауреаты (2021) Иҗат Хак улы Сабитов белән очрашу булып үтте.

Шул ук көнне Иҗат Хак улы Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә булып, әлеге мәдрәсәнең ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин белән очрашты. Очрашуда «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, җәмәгать эшлеклесе һәм мөгаллимә Камәрия Хәмидуллина да катнашты.

● 9 декабрьдә Питрәчтә «Питрәч районы һәм Мишә елгасы буйлары: үткәне-бүгенгесе» дигән темага төбәкне өйрәнүчеләр конференциясе узды. «Татмедиа» АҖ генераль директоры Ш.Садыйков, Питрәч муниципаль район хакимияте башлыгы И.Кашапов, «Татар төбәкчеләре оешмасы» рәисе, тарихчы галим А.Борһанов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон, күренекле галим Х.Миңнегулов, журналистлар С.Кашапова, Л.Гобәйдуллин һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләр катнашында узган әлеге чарада XII гасырда яшәгән суфи шагыйрь Мәүлә Колый иҗатын өйрәнү, исемен мәңгеләштерү, истәлегенә мемориал таш кую, Мишә буенда аның исемендәге парк ачу мәсьәләләре күтәрелде.

● 13 декабрьдә Казанның «Сәйдәш» мәдәни үзәгендә күренекле әдип, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Галиевкә 75 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә (режиссеры – Лима Кустабаева) булып үтте. Кичәне Зөлфия Вәлиева һәм Илдар Кыямов алып барды.

● 15 декабрьдә танылган журналист һәм язучы Земфира (Зимфира) Заһид кызы Гыйльметдинова вафат булды. Мәрхүмәнең җәсәде әнисенең туган авылында – Теләче районындагы Балыклы (Байкал) зиратында җирләнде.

● 15 декабрьдә Ш.Камалның мемориаль музей-фатирында (Татар китабы йорты) классик әдип Кави Нәҗминең (1901-1957) һәм аның хатыны – тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмованың (1901-1978) тууларына 120 ел тулу уңаеннан «Аларның сүнмәс уты...» дигән күргәзмә ачылды.

● 15 декабрьдә Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында танылган әдәби тәнкыйтьче, шагыйрь, журналист, нашир Фәиз Мәүлит улы Зөлкарнәйнең тууына 75 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә узды. Кичәдә әдипнең якыннары, туганнары, энесе Л.Зөлкарнәй, каләмдәш дуслары Р.Батулла, М.Галиев, Р.Зәйдулла, Н.Гыйматдинова, Г.Морат, Л.Лерон, Ш.Җиһангирова, Р.Сәгъди, Р.Аллабирде, нәкышьче-рәссам Н.Нәккаш, җырчылар А.Тимершәех, В.Бәйрәмов һәм театр көллияте шәкертләре катнашты. Кичәне сценарий авторы Марат Закир алып барды.

● 17 декабрьдә Казанның Бауман урамындагы 19 нчы йортта «Китап club» рестораны ачылды. « Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев: «Ресторан иҗат әһелләре һәм барлык татар дөньясы өчен җәлеп итү урыны булып торыр дип ышанам», – диде. Тантанада кунакларга шеф-пешекче Илдар Камалиевның китап формасында пешерелгән торты тәкъдим ителде.

● 17 декабрьдә Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе М.Ш.Шәймиев Әлмәт һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге «Адымнар» күптелле белем бирү комплексларының төзелеш объектларына кагылышлы киңәшмә үткәрде.

● 22 декабрьдә «Безнең мирас» журналының актив авторы, хезмәт ветераны, Чүпрәле районының Мунчәли авылы тумасы Фарук Арифулла улы Нәфиев 86 нчы яшендә кинәт вафат булды һәм Тәтеш зиратында җирләнде. ■

МИРАСВОРД

Дирижер ... Рахлин

Рәссам ... Хаҗиәхмәтов

Нурихан Фәттах романы / Сибгат Хәким поэмасы

Мираж (иск.)

Чор, заман

«...-Сок» бәете

... Камал (урта гасыр татар шагыйре)

Шагыйрь Әхмәт ...

Өндәү, чакыру авазы (иск.)

Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» повестендагы герой

Киндернең орлык бирә торган ана үсемлеге

Шагыйрь Ямаш ...

Кыйммәтле таш

Хо ... Мин

Мәчеттә азан әйтүче дин әһеле

Чәк-чәк / Пәйгамбәр

Борынгы Шәрык илләрендә күрәзәлек итүче дин башлыгы

Күптән түгел генә

Таҗ Махал белән дан тоткан һиндстан каласы

Соры корт (диал.)

... Шагыйрьҗан

Дошманнан саклану өчен кирмән тирәли казып ясалган ныгытма

... Зәйдулла / Җәлилче ... Хәсәнов

Монгол кылычы

... калтырау / Вертолет маркасы

Әйттем ... кайттым

... Форд

Френкель, Сибелиус

Кыргый кош яки җәнлек

Фольклорчы ... Надиров

Шекспирның «Отелло» трагедиясендәге персонаж

Кешеләргә мәрхәмәтле мифик зат

Марк ... (Америка язучысы)



Ана җенестәге хайван

Гарәп артикле

Фатих Кәрим поэмасы

«... юкаләре» (җыр)

Кыр кәҗәсе (диал.)

Рәис Габдулла төзеде.

12 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Зөлфәт, АИ, Нури, умиак, төен, күр, Вәли, Фәннур, аҗар, үтләү, Мом, сур, исә, юха, «Дуга», Рәми, әтраф, Ярмәки, Нияз, ярлык, онта, «Ана», Атум.
Өстән аска: но, Мифтахетдин, әл, ять, Зөлкарнәй, Рауза, күнү, дәф, Нил, Ку, сум, «Фауст», угия, «Яра», Туишева, Әмир, Нәҗми, лат, Лаос, «Юксыну», кирмән, кам.

«Безнең мирас»

елъязмасы / гыйнвар

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасы. XX гасыр башы. ***Фото tatarica.org сайтыннан алынды.***

410 ел элек (1612)

Лейпциг каласында беренче татарча басма китап дөнья күрә.

290 ел элек (1732)

Күренекле мәгърифәтче, педагог һәм тәрҗемәче Сәгыйть Хәсән улы Хәлфин (1732-1785) дөньяга килә.

140 ел элек (1882)

Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ачыла. Аңа Галимҗан Баруди нигез сала һәм җитәкчелек итә. Уку вакыты – 12 ел. 1905-1906 нчы елларда «Мөхәммәдия» ислах (үзгәртеп кору) хәрәкәте үзәгенә әверелә. Биредә әдәби һәм драматик түгәрәкләр эшли, кулъязма газеталар чыга. Бүгенге көндә «Мөхәммәдия» биналары комплексы – татар архитектурасы һәйкәле.

95 ел элек (1927)

Татарстан Гыйльми үзәге Җамал Вәлидигә татар теленең тулы сүзлеген эшләп чыгуны тапшыра.

85 ел элек (1937)

24 гыйнварда Муса Җәлилнең «Алтынчәч» операсының либреттосы укып тикшерелә.

75 ел элек (1947)

31 гыйнварда Татар дәүләт академия театры Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» әсәрен сәхнәләштерә.

60 ел элек (1962)

29 гыйнварда әдип Кәрим Әмири (1893-1962) вафат була.

50 ел элек (1972)

«Казан утлары» журналының гыйнвар санында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы басыла башлый.

Журналга ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Январь 2022

И останется в мире слово моё...: Зульфат.

Историческое наследие: «Татары – народ, у которого есть своё государство». И.Тагиров; «Переселение тетюшинцев». Э.Саляхова; «Некоторые факты из жизни татар в Тетюшах». Р.Шарафиева, Л.Губайдуллин; «Нужен ли Гомер химику?» Г.Камай; «И нам вилят жить по-новому». Л.Муртазина; «Страшный голод». Р.Шарафиева, Л.Губайдуллин.

Татарский мир: «Деревенский парень. Президент. Аксакал»; «Рамис Сафиуллов: «Музей – это красота! И это надо почувствовать...»; «На страже нации». Ф.Харисов.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Религиозные праздники и знаменательные даты в 2022 году». А.Дубин; «Многоуважаемый ишан Тетюшей». И.Зиганшин; «Хадисы пророка Мухаммада (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат.

Литературное наследие: «В гостях у советской России». Х.Хамидулла; «Не говорите, что только повозка...» Т.Галиуллин; «Жесты истории». Р.Зайдулла.

И вырвалось из мирской суеты...: «Шигабутдин Марджани (1818-1889)». Р.Мухаметшин.

В глубинах памяти: «Ширина духовного охвата». М.Гусманов; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Алхәбәр:

Умартачылыкта эшнең кызу чагы
(«Кандра-Кутуй умартачылык ширкәте: тарих һәм тәҗрибә». Ленар Гобәйдуллин)

• **Истанбул мәктүбләре. Фатих Кәрими**
• **Закир Рәмиевкә (Дәрдемәнд) нисбәтле яңа чыганаклар. Лилия Габдрафикова**
• **Кандра-Кутуй умартачылык ширкәте: тарих һәм тәҗрибә. Ленар Гобәйдуллин**
• **Заусайлов коллекциясе. Нурулла Гариф**
• **«Болай ук булыр дип уйламаган идем...» Фәрдия Сәфәргалиева**
• **Гәүһәр Камалова һәм Дэлюс Ильясов. Әхтәм Зарипов**

Шагыйрь Зөлфәт — фотоларда

Шагыйрь Зөлфәт якын туганнары белән. 1980 нче еллар ахыры

Зөлфәтнең уллары Азамат, Илһам, Фазыл һәм кызы Кадрия белән шахмат уйнаган чагы. 1980 нче еллар

Зөлфәт хатыны Фирая һәм кызы Кадрия белән

Студентлар белән очрашу вакытында: Зөлфәт (сулда), Рәдиф Гаташ, Мөхәммәт Мәһдиев, Ләбиб Лерон, Ркаил Зәйдулла (баскан). 1985 ел



Шагыйрь үзенең дәвамчылары – кадерле оныклары белән. 2000 нче еллар

**ИДЕЛ БИТ УЛ, ТИРӘН БИТ УЛ,
ТИРӘН БИТ УЛ, КИҢ БИТ УЛ...**



ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.